# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2024 3 (43)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

*Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында*
*ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»,*
*«Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне*
*саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында*
*2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр*
*һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча*
*федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы*
*таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе

► **РЕДКОЛЛЕГИЯ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
редколлегия рәисе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МИҢНЕХАНОВ Р.Н., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХАЛИКОВ И.И., филология фәннәре кандидаты (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ГЫЙНИЯТУЛЛИНА Л.М. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият),
ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т.,
СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Миңнуллин Б.К.* Гарәп язулы татар газета текстларында исем фигыль кулланылышының функциональ һәм семантик аспектлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Пименова М.В.* Рус, инглиз һәм төрки *душа, soul* һәм *җан* концептларының мотивлаштыра торган билгеләре . . . . . . . . 14
*Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасыр искетатар язма истәлекләрендә тотрыклы сүзтезмәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Юсупова Н.М.* Энциклопедик эшчәнлеккә ия галим *(танылган әдәбият белгече, академик Дания Заһидуллинаның юбилее уңаеннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
*Хасавнех А.А.* Татар фәнни әдәбиятында суфичылык: хатын-кыз мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Татар рухи мирасы буларак «Салсал» дастаны: М. Юмачиков һәм Г. Исмәгыйлев вариантлары . . . . . 59

## Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМ. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ ОЕШТЫРЫЛУГА 85 ЕЛ

*Заһидуллин И.К.* Сәлам Хатыйп улы Алишев – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әйдәп баручы тарихчысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
*Солтанов Ф.М.* Галим һәм җәмәгать эшлеклесе: Яхъя Абдуллин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
*Галләмова Ә.Г.* Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов: көрәшче, галим, әйдаман. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
*Хуҗин Ф.Ш.* Тел, әдәбият һәм тарих институтында Татарстан археологиясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
*Ямалтдинов И.И.* XX йөзнең 60 нчы елларында халык авыз иҗаты буенча тикшеренүләр . . . . . . . . . . . . 103

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Курбангельдыев Дж.Ш.* Сәлҗуклар дипломатиясендә җәя һәм ук символикасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

## СӘНГАТЬ

*Галимова Э.М.* Татар халык җырларын өйрәнү ысуллары эволюциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
*Калугина О.В.* Российянең хәзерге заман шәһәр скульптурасы: жанрын билгеләү мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131

**ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Фәйзуллина Ф.Г.* Пенза өлкәсендәге археографик табышлар турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Тябина Л.И.* Кем ул Камил Мотыйгый? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146

*Абзалина Р.Ә.* Габдулла Мөхәммәтгариф улы «Мотыйгия» мәдрәсәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

**ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР**

*Хәсәнова А.Н.* Фатыймаи-Фәридә Ваһапова-Нәүрузованың «Сибирия» газетасында басылган мәкаләләреннән . . . . . . . . 165

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Мотыйгуллина Ә.Р.* Заманча «Әлифба» (Туган тел (татар теле). Әлифба. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. – 128 б. китабына бәяләмә) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Миннуллин Б.К.* Функциональный и семантический аспекты употребления имени действия в татарских арабографических газетных текстах . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Пименова М.В.* Мотивирующие признаки русского, английского и тюркского концептов *душа, soul* и *жан* . . . . . . . . . . . . . 14

*Валиева М.З.* Устойчивые словосочетания в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII веков . . . . . . . . . . . 22

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Юсупова Н.М.* Учёный-энциклопедист *(к юбилею известного литературоведа, академика Дании Загидуллиной* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

*Хасавнех А.А.* Суфизм в татарской научной литературе: женский вопрос . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* Дастан «Салсал» как духовное сокровище татар: варианты М. Юмачикова и Г. Исмагилова. . . . . . . . . . 59

### 85 ЛЕТ ИНСТИТУТУ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА

*Загидуллин И.К.* С.Х. Алишев – ведущий историк Института языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова . . . . . . . . . 68

*Султанов Ф.М.* Ученый и общественный деятель: Яхъя Абдуллин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77

*Галлямова А.Г.* Мидхат Каримович Мухарямов: боец, ученый, лидер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

*Хузин Ф.Ш.* Татарстанская археология в Институте языка, литературы и истории . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92

*Ямалтдинов И.И.* Исследования татарского фольклора в 60-х годах XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103

### СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Курбангельдыев Дж.Ш.* Символика лука и стрелы в сельджукской дипломатии . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

### ИСКУССТВО

*Галимова Э.М.* Эволюция методов изучения татарских народных песен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121

*Калугина О.В.* Городская скульптура современной России: проблема жанровой идентификации . . . . . . . . . . . . . . . 131

## ПО СЛЕДАМ НАУЧНЫХ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Файзуллина Ф.Г.* Об археографических находках в Пензенской области . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138

## ПЕРСОНАЛИИ

*Тябина Л.И.* Камиль Мутыги – кто он? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146

*Абзалина Р.А.* Габдулла Тукай в медресе «Мутыгия» . . . . . . . 160

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Хасанова А.Н.* Из статей Фатимы-Фариды Вагаповой-Наурузовой, опубликованных в газете «Сибирия» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

## НОВЫЕ КНИГИ

*Мотигуллина А.Р.* Современная «Әлифба» (рец. на «Туган тел (татар теле). Әлифба. 1 нче сыйныф» (Казань, 2023. 128 с.)) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 81'37

*Б.К. Миңнуллин*

# ГАРӘП ЯЗУЛЫ ТАТАР ГАЗЕТА ТЕКСТЛАРЫНДА ИСЕМ ФИГЫЛЬ КУЛЛАНЫЛЫШЫНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ҺӘМ СЕМАНТИК АСПЕКТЛАРЫ

Настоящая статья посвящена научной разработке вопросов функционирования форм имени действия в текстах татароязычной арабографической периодической печати начала XX века. Актуальность темы исследования обусловлена необходимостью исследования грамматических норм языка татароязычной арабографической периодической печати начала XX века, выполнявшей в рассматриваемый период, наряду с художественными произведениями, роль определенной платформы для функционирования старотатарского письменного литературного языка и его дальнейшего преобразования в национальный литературный язык. Благодаря результатам такого исследования формируется возможность прослеживания этапов функционирования форм имени действия в диахронии. В результате проведённого научного анализа нами выявлено, что наряду с именем действия на *-и*, закрепившегося в литературном языке в межреволюционный период 1905–1917 гг. и являющегося основной формой имени действия в современном его состоянии, в текстах газет, в особенности на более ранних этапах, активно употреблялись и формы на *-maq* и *-ma*, характерные для огузских языков.

**Ключевые слова:** старотатарский литературный язык, татарская периодическая печать, язык газеты, грамматическая система, имя действия.

This article is devoted to the development of issues of the functioning of the forms of the action verbs in the texts of the Tatar-language Arabic periodical press of the early twentieth century. The relevance of the topic of the scientific article is due to the need to study the grammatical norms of the language of the Tatar periodical press of the early twentieth century, which in the period under review, along with literary works, played the role of a certain platform for the functioning of the Old Tatar written literary language and its further transformation into a national literary language. Thanks to the results of such a study it is possible to trace the stages of functioning of the forms of the action verbs in diachrony. As a result of our scientific analysis we have revealed that along with the -u action verbs, which was fixed in the literary language in the inter-revolutionary period 1905–1917 and is the main form of the action verbs in its current state more characteristic of the Oguz languages the *-maq* and *-ma* forms were actively used in newspaper texts especially at earlier stages.

**Keywords:** old Tatar literary language, Tatar periodical press, newspaper language, grammatical system, action verbs.

XX гасыр башы татар вакытлы матбугатында, аерым алганда Әстерханда чыккан «Борһане тәрәккый» (1906–1911), Оренбургта басылган «Вакыт» (1906–1918), Казанда нәшер ителгән «Кояш» (1912–1918) газеталары текстларында затланышсыз фигыль формаларының

бер категориясе булган, исем һәм фигыль сүз төркемнәренә хас үзенчәлекләрне үз эченә алган исем фигыльнең актив кулланылуы күзәтелә. Газета текстларында кулланылган исем фигыльләрнең төп семантик функциясе, нигездә, эш, халәт яки процессны белдерүдән гыйбарәт. Өйрәнелә торган материалларда исем фигыльләр, хәзерге татар әдәби телендәге кебек, махсус грамматик күрсәткечләр ярдәмендә барлыкка килә. Билгеле булганча, бүгенге көндә татар әдәби телендә кулланылышта булган төп исем фигыль формасы булып *-у* кушымчалы исем фигыль тора, сирәгрәк *-ыш* кушымчалы исем фигыльләр очрый [Татар грамматикасы, 2016, б. 255]. Фактик материаллардан күренгәнчә, беренче грамматик күрсәткеч XX гасыр башы татар газета текстларында еш очрый торган исем фигыль формасы булып тора. Ул гомумтөрки чорга барып тоташа һәм соңрак, фонетик закончалыкны истә тотып фикер йөрткәндә, уйгур һәм кыпчак группаларына караган телләрдә кулланылышта була. Шул ук вакытта өйрәнелә торган текстларда, татар әдәби теле тарихы күзлегеннән чыгып караганда, кызыксыну уяткан традицион язма форма буларак кабул ителә торган [Татар әдәби теле..., 2017, б. 804] *-maq* кушымчалы һәм исем фигыль функциясендә хәзерге төрек әдәби телендә актив кулланылган [Кононов, 1956, с. 457], татар әдәби теленең кайбер сөйләшләрендә очрый торган [Юсупов, 2004, с. 267] *-ma* кушымчалы исем фигыльләр игътибарны җәлеп итә.

Югарыда әйтеп кителгәнчә, хәзерге татар әдәби теле күзлегеннән караганда, *-maq* кушымчалы исем фигыль архаик форма буларак билгеләнә, ләкин татар теленең кайбер сөйләшләрендә әлеге форма күпмедер дәрәҗәдә инфинитив һәм исем фигыль функцияләрендә сакланып калган [Юсупов, 2004, с. 267]. Шул ук вакытта, *-maq* кушымчалы исем фигыль кайбер угыз телләрендә, шул исәптән төрек әдәби телендә, актив кулланылышта булса да [Кононов, 1956, с. 466], кыпчак группасына караган төрки телләр өчен хас түгел.

Фактик материаллар күрсәткәнчә, өйрәнелә торган газеталар арасында иртәрәк чыга башлаган «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында *-maq* кушымчалы исем фигыль ешрак очрый. «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында исә әлеге күрсәткечнең кулланылыш активлыгы сизелерлек дәрәҗәдә кими һәм, гадәттә, баш килештә яисә *-maq* кушымчалы исем фигыль һәм бәйлектән гыйбарәт булган грамматик конструкция кысаларында кулланыла. Мондый күренеш иң элек 1905–1917 еллардагы революцияара чорда әлеге күрсәткечнең иске татар әдәби теле кысаларында тотрыклы кулланылышка соңрак кереп киткән *-и* кушымчалы исем фигыль тарафыннан кысрыклана башлавы белән аңлатыла.

Газета текстларында өйрәнелә торган исем фигыль формасы, барлык килеш формаларын да ала торган *-и* кушымчалы исем фигыльдән аермалы буларак, килеш белән бик сирәк төрләнә. Гадәттә ул текстларда баш килештә кулланыла һәм теге яки бу эшнең, процессның исемен белдерә: *Milät* ***sävmäk****, xoquq* ***sävmäk****, wazyjfa* ***tanymaq****, üz*

*qyjmätene* ***belmäk*** *kebi syjfatlara malik ulmazmyjdyq?* [«Хәят сакламак», «Б.т.»[1], 1906, № 47]; *Kiräk üz qalonijäsendä kiräk ingliz wä fransuz qalonijäsendä bulsyn, muafäqyjät* ***qazanmaq*** *nimes öčen xämer ečü kebi ber ešder* [«Нимес рәкабәте», «К.»[2], 1914, № 577].

Шулай ук газета текстларында баш килештәге *-maq* кушымчалы исем фигыль изафә конструкцияләрендә кулланыла һәм атрибутив мәгънә ала. Бу очракта ачыкланып килә торган сүз, гадәттә, өченче зат тартым кушымчасы белән төрләнә: *Möselman awyllaryna kitabxanälär* ***ačmaq*** *fikerendä uldyğy bezlärne artyq ömed var idäder* [«Народный университет», «Б.т.», 1906, № 47]; *Bez any xäzräte Räsülneŋ tacy* ***ulmaq*** *syjfatyjlä... itixad itdek* [«Сыйфаһәт вә чалма», «В.»[3], 1909, № 433].

Моннан тыш, баш килештәге *-maq* кушымчалы исем фигыль *-dyr*/*-der* хәбәрлек кушымчасын алырга һәм предикатив мәгънәдә кулланылырга мөмкин: *Ul julda can fida idär däräcäsendä ulyb ğajrät itmäk* ***dimäkder*** [«Без ни хәлдә?», «Б.т.», 1907, № 80].

«Кояш» газетасы текстларында баш килештәге *-maq* кушымчалы исем фигыль предикатив мәгънәдә кулланганда, еш кына хәбәрлек кушымчасыннан башка килә: *Bu islaxatdan maqsud Irannyŋ daxili ešlären tärtibkä* ***qujmaq*** [«Иран эшләре», «К.», 1910, № 656]. Шуны ассызыкларга кирәк: хәзерге татар әдәби телендә хәбәрлек категориясенең кулланылышы – сирәк очрый торган күренеш [Татар грамматикасы, 2016, б. 57]. Аерым алганда, *-дыр*/*-дер, -тыр*/*-тер* өченче зат хәбәрлек күрсәткечләре бөтенләй диярлек очрамый. Шуңа күрә өйрәнелә торган газеталар арасында иң соң чыга башлаган «Кояш» газетасы текстларында *-maq* кушымчалы исем фигыльнең предикатив мәгънәдә хәбәрлек кушымчасыннан башка кулланылуын 1905–1917 еллардагы революцияара чорда язма әдәби телдә барган үзгәртеп кору процесслары һәм яңа тел нормаларына көчү белән бәйләп карау дөрес булыр.

Предикатив мәгънәдә кулланыла торган *-maq* кушымчалы исем фигыль шулай ук баш килештә *ide* ярдәмче фигыле белән килергә мөмкин: *Pravitelstvanyŋ bu eše jäğni vajenyj polevoj sudlar täškil itüwe revalutsijäne betereb, üzenä jarağan Dumany* ***cyjmaq ide*** [«Хаҗитархан сентябрь 24», «Б.т.», 1906, № 28].

Газета текстларында предикатив мәгънәдә кулланыла торган *-maq* кушымчалы исем фигыльнең баш килештә *imeš* ярдәмче фигыле белән кулланылу очраклары да билгеләнде: *Bu kitabny taratudan maqsud da xalyqnyŋ xosusa Italijäneŋ äfkaryn Germanijä tarafyna* ***audarmaq*** *imeš* [«Ак китаб», «К.», 1914, № 485].

Аерым очракларда *-maq* кушымчалы исем фигыль төшем килеше кушымчасын ала һәм затланышлы фигыль формасы белән белдерелгән эшнең турыдан-туры объектын белдерә: *Möxtäräm*

---

[1] «Борһане тәрәккый».

[2] «Кояш».

[3] «Вакыт».

*möštäriläremezdän adreslaryny ačyq häm dörest* ***jazmaqlaryny*** *rica idämez* [«Игълан», «Б.т.», 1906, № 39]; *Ošbu ütenečeme gazetaŋyznyŋ ber jerenä* ***darc qylmaqyŋyzy*** *insanijat namyna ütenämen* [«Идарәгә мәктүпләр», «В.», 1912, № 921].

«Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында еш кына *-maq* кушымчалы исем фигыльнең бәйлекләр белән бергә кулланылуы күзәтелә. Иң еш очрый торган бәйлекләрнең берсе – *ilä* бәйлеге һәм аның *ilän*, *belän*, *berlän*, *berlä*, *belä* фонетик вариантлары. Мондый төр грамматик конструкцияләр, гадәттә, объектив мөнәсәбәтләрне белдерә: *Orenburg okrugyndağy mäğarif mämurlary xäzer möselman mäktäblärenä 31 nče martda mäğarif ministry tarafyndan tasdyjq qylynmyš jaŋa pravilalarny* ***kertmäk*** *ilän mäšğüllär* [«Газеталардан», «Б.т.», 1906, № 42]; *Ägär dä üz kamitetymyz bulsa, ğajrät wä sädaqatemez zahir* ***ulmaq*** *ilä bärabär birgän sumamyznyŋ niqadär ikäne dä mäğlüm bulyr ide* [«Авылларда зур ихтыяҗ вә аларга ярдәм», «К.», 1914, № 485].

«Вакыт» газетасы битләрендә дөнья күргән кайбер текстларда угыз телләре өчен, аерым алганда XX гасыр башы госманлы төрекчәсе өчен хас грамматик һәм лексик үзенчәлекләрнең мул кулланылуын күрәбез. Иске татар әдәби теленең угызлашкан вариантында язылган мондый текстларда, мәсәлән, *-maq* кушымчалы исем фигыльнең хәзерге төрек әдәби телендә дә актив кулланылышта булган *üzärä* ‘өчен, максатында’ бәйлеге белән янәшә кулланылуы теркәлгән [Кононов, 1956, с. 318]. Бу грамматик конструкция хәрәкәтнең максатын белдереп килә: *Mäcles palitsijäneŋ röxsäte ilä Möxämädälräxim xaci Junysof öjendä ulyb äksäre ğoläma wä ğolämägä mänsüb kešelärdän* ***ulmaq*** *üzärä jözdän artyq keše xazir ulmyšlar ide* [«Казанның рәсем хаттын төзәтү хакында мөзакәрә мәҗлесе», «В.», 1909, № 433].

Өйрәнелә торган барлык газета текстларында да *-maq* кушымчалы исем фигыль һәм *xosusynda* ‘турында’ бәйлеге нигезендә төзелгән конструкция очрый. Хәзерге татар әдәби теле күзлегеннән чыгып караганда, бу бәйлек архаик форма буларак билгеләнә һәм сирәк кенә рәсми стильгә караган текстларда очрый. Башка функциональ һәм стилистик кырларда исә *хосусында* бәйлегенең заманчарак *турында* һәм *хакында* синонимнары кулланыла. Фактик материал кысаларында кулланылган мондый грамматик конструкция конкрет сөйләмнең предметын белдерә: *Ike ystipendijä* ***ačmaq*** *xosusynda Qazan učitelskij yškolasynyŋ idaräse ilä xäbärläšmäkdäder* [«Оренбург хәбәрләре», «В.», 1909, № 433].

Гомумән алганда, иске татар әдәби теле кысаларында яшәп килгән, бүгенге көн татар әдәби теле күзлегеннән чыгып караганда традицион тел берәмлеге буларак билгеләнгән һәм хәзерге төрек әдәби теле өчен хас *-maq* кушымчалы исем фигыль XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына караган барлык иске татар язма истәлекләрендә дә теркәлгән [Татар әдәби теле..., 2017, б. 821] һәм татар әдәби теле тарихы фәнендә функциональ һәм стилистик вариантлылыкның гамәл-

дә булуын раслый торган грамматик берәмлекләрнең берсе булып тора.

Өйрәнелә торган газета текстларында шулай ук *-ma* кушымчалы исем фигыльнең кулланылышы да теркәлде. Гомумән, әлеге форма *-u* һәм *-maq* кушымчалы исем фигыльләр белән чагыштырганда азрак таралыш алса да, ул угыз группасына караган телләр өчен, шул исәптән тикшерелә торган чорның госманлы төрекчәсе өчен хас булган грамматик һәм лексик элементлар белән сугарылган XX гасыр башы иске татар язма әдәби теленең угызлашкан вариантында язылган текстларда актив кулланыла.

Гомумән, *-ma* кушымчалы исем фигыль XIX гасыр ахыры – XX гасыр башына караган иске татар язма истәлекләренең барысында да чагылыш тапмый [Татар әдәби теле..., 2017, б. 804], ләкин *-maq* кушымчалы исем фигыль кебек үк иске татар язма әдәби телендәге функциональ һәм стилистик вариантлылыкның бер күрсәткече булып тора.

Хәзерге татар әдәби телендә *-ma* кушымчалы исем фигыль кулланылыштан төшеп калган грамматик берәмлекләр рәтендә тора, ә татар теленең диалектларында исә бу форма инфинитив функциясен үти. Аерым алганда, *-ma* кушымчалы инфинитив урта һәм мишәр диалектлары сөйләшләрендә активлык күрсәтә, ләкин татар теленең диалектлар системасының үзәк өлешенә кертеп каралмый һәм татар теле диалектларының классификацион билгесе булып тормый [Юсупов, 2004, с. 203, 207]. Шул ук вакытта, төрек әдәби телендә исем фигыль функциясендә *-ma* формасы иң актив күрсәткечләрнең берсе булып санала һәм тартым кушымчалары белән дә, килешләр белән дә төрләнә [Кононов, 1956, с. 454].

«Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында *-ma* формасы бары тик исем фигыль функциясендә генә очрый, ә аның кулланылыш мөмкинлекләре шактый чикләнгән. Гадәттә, газета текстларында *-ma* кушымчалы исем фигыль баш килештә генә килә һәм *-sy/-se* өченче зат берлек сан тартым кушымчасы белән төрләнә. Бу очракта функциональ яктан *-ma* формасы *-dyq* һәм *-ačaq* формалы сыйфат фигыльләргә якынлаша һәм хәбәрнең лексик мәгънәсе белән бәйле киләчәккә юнәлдерелгән ихтимал булган эшне белдерә: *Čyqarylan paranyŋ lazem järlärä* ***saryf idelmäse*** *julyny düšenälem* [«Кырым идарә руханиясендә мөһим мөшәвәрә мәҗлесе», «К.», 1916, № 928].

Газета текстларында шулай ук *-ma* кушымчалы исем фигыль һәм бәйлекләрдән торган конструкцияләр очрый. Алар, гадәттә, нинди дә булса киңәйтелгән хәлне белдерә. Мәсәлән, «Кояш» газетасы текстларында карала торган форманың *öčen* бәйлеге белән кулланылган очраклары теркәлде. Мондый конструкция максатның киңәйтелгән хәлен белдерә, ә бәйлек белдерелгән мәгънәне аныклап килә: *Bu mäcles jalŋyz mäktäb wä mädräsäläreŋ islaxy mäsäläse müzakäräse wä jäki program tärtib* ***idelmäse*** *öčen wäli cänabläreneŋ röxsätilä japylmyš*

*ber mäclesder* [«Кырым идарә руханиясендә мөһим мөшәвәрә мәҗлесе», «К.», 1916, № 928].

Газета текстларында *-ма* кушымчалы исем фигыльнең юклык формасы киң таралмаган һәм ул фигыльнең нигезенә *-ma/-mä* юклык кушымчасы ялгау юлы белән ясала: *...insan qalbene cäleb* ***itmämäse*** *qabil dägel ide* [«Бохара әхвалендән», «В.», 1910, № 595].

Хәзерге татар әдәби телендә сирәк кенә булса да исем фигыль функциясендә очрый торган *-ыш* кушымчалы исем фигыль газета текстларында теркәлмәде. Гомумән, *-yš* кушымчалы форма өйрәнелә торган газеталарда очраса да, әлеге күрсәткеч ярдәмендә төзелгән сүзләр конверсия ысулы белән барлыкка килгән исемнәр буларак билгеләнәләр (*suğyš*, *utyryš*, *cyjylyš* һ. б.).

Фактик материал күрсәткәнчә, исем фигыльләр, теге яки бу эшнең мәгънәсен белдереп, кайбер исем сүз төркемнәреннән һәм башка затланышсыз фигыль формаларыннан аермалы буларак, кулланылыш үзенчәлекләреннән чыгып караганда, аерым жанрларга гына бәйле булып калмыйча, теләсә нинди жанрга караган текстларда теркәләләр. Шул ук вакытта исем фигыльләрнең төрле формалары хәбәр, хисап, репортаж кебек мәгълүмати жанрларга, мәкалә, вакытлы матбугатка күзәтү кебек аналитик жанрларга һәм әдәби-публицистик жанрларга караган очерк текстларында күбрәк очрый.

Шулай итеп, «Борһане тәрәккый», «Вакыт» һәм «Кояш» газеталары текстларында берничә исем фигыль формасының кулланылуы билгеләнде. Иң актив кулланыла торганы – хәзерге татар әдәби телендә дә кулланылышта булган *-и* кушымчалы исем фигыль формасы. Шул ук вакытта һәр өйрәнелә торган газетаның конкрет санында басылган мәкалә 1905–1917 еллардагы революцияара чорда никадәр соңрак дөнья күргән булса, ул текстларда *-и* кушымчалы исем фигыльнең активлыгы шулкадәр югарырак була. Шул рәвешле, әлеге грамматик форма өйрәнелә торган газеталар арасында чагыштырмача соңрак чыга башлаган «Кояш» газетасы текстларында исем фигыль формаларының төп варианты буларак билгеләнсә, беренче татар газеталары рәтендә 1906 елда чыга башлаган «Борһане тәрәккый» газетасы текстларында исә *-и* кушымчалы исем фигыль урынына еш кына исем фигыльнең башка формалары кулланыла.

### Әдәбият


Авылларда зур ихтыяҗ вә аларга ярдәм // Кояш. 1914. № 485.

Ак китаб // Кояш. 1914. № 485.

Без ни хәлдә? // Борһане тәрәккый. 1907. № 80.

Бохара әхвалендән // Вакыт. 1910. № 595.

Газеталардан // Борһане тәрәккый. 1906. № 42.

Игълан // Борһане тәрәккый. 1906. № 39.

Идарәгә мәктүпләр // Вакыт. 1912. № 921.

Иран эшләре // Кояш. 1910. № 656.

Казанның рәсем хаттын төзәтү хакында мөзакәрә мәҗлесе // Вакыт. 1909. № 433.

Кырым идарә руханиясендә мөһим мөшәвәрә мәҗлесе // Кояш». 1916. № 928.

Народный университет // Борһане тәрәккый. 1906. № 47.

Нимес рәкабәте // Кояш. 1914. № 577.

Оренбург хәбәрләре // Вакыт. 1909. № 433.

Сыйфаһәт вә чалма // Вакыт. 1909. № 433.

Хаҗитархан сентябрь 24 // Борһане тәрәккый. 1906. № 28.

Хәят сакламак // Борһане тәрәккый. 1906. № 47.

*Кононов А.Н.* Грамматика современного турецкого литературного языка. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1956. 569 с.

Татар әдәби теле тарихы (XIII–XX йөз башы). Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык: 3 томда / фән. ред. Ф.М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. II. 888 б.

Татар грамматикасы: өч томда. Тулыландырылган 2 нче басма / проект җит. М.З. Зәкиев. Казан: ТӘһСИ, 2016. т. II. 432 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Морфология татарского диалектного языка. Категории глагола. Казань: Фэн, 2004. 592 с.

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 81`27

***М.В. Пименова***

# РУС, ИНГЛИЗ ҺӘМ ТӨРКИ *ДУША, SOUL* ҺӘМ *ҖАН* КОНЦЕПТЛАРЫНЫҢ МОТИВЛАШТЫРА ТОРГАН БИЛГЕЛӘРЕ

Цель исследования – определить набор мотивирующих признаков трёх концептов: *душа*, *soul* и *жан*. Для достижения цели было использовано 24 словаря. В итоге проведённого анализа этимологических, историко-этимологических и толковых словарей русского, английского и тюркских языков было выявлено по девять мотивирующих признаков у концептов *душа* и *soul*, одиннадцать мотивирующих признаков у концепта *жан*. Общей характеристикой мотивирующих признаков анализируемых концептов стала соотнесённость души в сравниваемых лингвокультурах со стихиями. Русская и тюркские языковые картины мира показали наличие сопоставимых мотивирующих признаков: у концепта *душа* – ‘дыхание’ и ‘ямочка над грудной клеткой’ и у концепта *жан* – ‘дышать’, ‘грудь’ (соответственно). Похожими у концептов *soul* и *жан* стали мотивирующие признаки ‘солнце’ и ‘гореть’.

**Ключевые слова:** концепт, структура концепта, мотивирующие признаки, языковая картина мира, лингвокультура, этимология.

The purpose of the study is to determine a set of motivating signs of three concepts: *душа* (soul), *soul* and *zhan* (soul). 24 dictionaries were used to achieve the goal. As a result of the analysis of the etymological, historical-etymological and explanatory dictionaries of the Russian, English and Turkic languages, nine motivating signs were identified for the concepts *душа* (soul), eleven motivating signs for the concept *zhan* (soul). The correlation of the soul in the compared linguocultures with the elements has become a common characteristic of the motivating signs of the analyzed concepts. The Russian and Turkic language pictures of the world showed the presence of comparable motivating signs: the concept of *душа* (soul) has ‘breath’ and ‘dimple above the chest’, and the concept of *zhan* has ‘breathe’, ‘breast’ (respectively). The motivating signs ‘sun’ and ‘burn’ have become similar in the concepts of *soul* and *zhan*.

**Keywords:** concept, concept structure, motivating signs, language picture of the world, linguaculture, etymology.

Эчке дөнья темасына мөрәҗәгать итү һәрвакыт актуаль булган. Әлеге мәкаләдә күтәрелгән җанны концептлаштыру темасы төрле структуралы рус, инглиз һәм төрки телләрдә аерым сүзләрнең этимологизациясе өлкәләрен колачлый. Генетик яктан төрле булуларына карамастан, аларның кайберләрендә тәңгәллекләр табарга мөмкин. Бу тикшеренүнең фәнни яңалыгы шунда ки, ул рус, инглиз һәм төрки телләрдәге *душа, soul* һәм *җан* концептларының мотивлаштыра торган билгеләрен чагыштыруда беренче тәҗрибә булып тора.

Әлеге тикшеренүдә түбәндәге чагыштырма-тарихи, тасвирлама, концептуаль методлар кулланылды. *Душа* (рус концепты репрезен-

таты) сүзенең этимологиясен ачыклау өчен ун этимологик, тарихи сүзлеккә һәм халык шәһәрләре сүзлегенә, *soul* сүзен тикшергәндә – сигез сүзлеккә, *җан* (төрки концепт репрезентанты) сүзен ачыклаганда – алты этимологик һәм тарихи сүзлеккә мөрәҗәгать иттек.

Лингвистик әдәбиятта бу мәкаләдә анализлана торган кайбер концептлар тикшерелгән хезмәтләр билгеләп үтелгән. *Душа* һәм *soul* концептлары структуралары М.В. Пименованың докторлык диссертациясендә һәм монографияләрендә чагыштырылган [Пименова, 1999; 2001; 2004]. Рус һәм әрмән дөнья тел картиналарында *душа* концептының чагыштырма анализы Н.К. Гаспарян тарафыннан ясалган [Гаспарян, 2017]. Рус лингвокультурасында *душа* концептын Е.А. Журавлева [Журавлева, 2007], инглиз, немец һәм рус дөнья фразеологик картинасында Г.И. Маринина [Маринина, с. 132–135] һ. б. тасвирлаган.

Куелган максатка ирешү өчен, төп ике бурычны хәл итәргә кирәк: 1) сүзләрнең – өйрәнелә торган концептлар репрезентантларының этимологиясе бирелгән этимологик, тарихи-этимологик һәм аңлатмалы сүзлекләрдә сүзлек мәкаләләрен анализларга; 2) табылган мәгълүматларны анализлау өчен алынган концептларның ачыкланган мотивлаштыра торган билгеләре буенча чагыштырырга.

*Душа* сүзенең этимологиясенә мөрәҗәгать итик. А.К. Шапошников билгеләп үткәнчә, *душа* сүзе «рус телендә XI–XVII гасырлардан» ук билгеле [Шапошников, с. 251]. *Душа* сүзенең гомумславян табигатенә М.Н. Свиридова, Г.П. Цыганенко, Н.М. Шанский сүзлекләре дә күрсәтә [Свиридова, с. 88; Цыганенко, с. 121; Шанский].

Күп кенә этимологик сүзлекләр *душа* сүзенең нигезен *дух* сүзенеке белән бәйлиләр, аларны уртак нигезле дип саныйлар [Горяев, с. 99; Преображенский, с. 204]. Г.А. Крылов *душа* сүзенең ясалышын болай аңлата: «Суффиксальное производное (суф. -j-) от той же основы, что и *духъ*: xj > ш» [Крылов, с. 123].

П.Я. Черных борынгы рус телендә *духъ* сүзенең «җан», «гакыл», «кәеф», «исеп кую», «җил», «парга әйләнү» кебек мәгънәләре булуга басым ясый [Черных, с. 276]. *Дух* сүзенең «душа» мәгънәсенә ия булуы турында А.К. Преображенский яза [Преображенский, с. 204].

Һәр сүзлек авторы *душа* сүзенең килеп чыгышын төрлечә аңлата. А.К. Шапошников аны праславян телендәге **душа*дан ясалган ди: «с суф. -йа от *духъ» [Шапошников, с. 251]. Г.А. Крылов түбәндәгечә ачыклык кертә: «Общеславянское слово, образованное от той же основы, что и *духъ*» [Крылов, с. 123]. Г.П. Цыганенко гомумславян *душа* *j* алдындагы *х* > *ш* үзгәрешеннән соң үз чиратында һинд-европа телләрендәге *dhusi̯a «рух, сулыш» сүзеннән барлыкка килгән праславян *duxja «душа» сүзеннән килеп чыккан, дип билгели [Цыганенко, с. 121]. М.Н. Свиридова борынгы рус телендә *духъ* сүзенең «җан, акыл, җил» мәгънәләре булган, дип өсти [Свиридова, с. 88]. Һинд-европа телләрендә махсус *dhousjā «һава, өрәкләр» сүзенең дә булуы фараз ителә [Шапошников, с. 251].

*Душа* сүзенең иң тулы этимологиясен О.Н. Трубачев редакциясендәге «Славян телләренең этимологик сүзлеге»ндә («Этимологический словарь славянских языков») табабыз: «кешенең психик дөньясы», «асылы, чын мәгънәсе» мәгънәләренә ия булган рус сүзе *душа duša* сүзенә барып тоташа, диалекталь мәгънәләре: ‘күкрәк, күкрәк куышлыгы’ (пск., енис.), ‘йөрәк’ (петерб., смол.), ‘тән’ (смол.), ‘күбәләк, вак күбәләк’ (калуга); укр. *душа*ның өч мәгънәсе бар: «җан», «тамак төбендәге урын», «муендагы шеш» [Этимологический словарь славянских..., с. 164]. Н.М. Шанский болай дип өсти: «исконно *душа* «ямочка над грудной клеткой» (*у него за душой ничего нет*), ни души «никого», *обращение моя душенька* и т. д.» [Шанский]. Концепт репрезентантларының этимологик анализы мөһим закончалыкка күрсәтә: рус һәм төрки дөнья картиналарында тән метонимик рәвештә җан урнашкан урынга тәңгәлләшә.

Сүзләргә этимологик анализ ясаганда аларның мифологик компоненты зур роль уйный. Рус фольклорында *күбәләк* сүзе, «ата-баба җанының гәүдәләнеше» буларак, вак күбәләк турындагы күзаллауга бәйле; чаг.: яросл. *ду́шичка* – күбәләк, вак күбәләк. «Словарь русских народных говоров» хезмәтендә билгеләп үтелгәнчә, *душа́* ‘күбәләк’ (калуга), *ду́шечка* ‘шулай ук’ (яросл.)» [Словарь русских народных…, с. 283].

Инглиз концепты *soul* сүзнең – репрезентантның этимологиясе аспектында рус концепты *душа*дан шактый аерыла. *Soul* сүзе этимологиясенең берничә варианты бар: *soul* сүзенең килеп чыгышы билгесез [Online Etymology…]. Этимологиянең тагын бер варианты: башта *soul* сүзе «диңгездән килгән яки диңгезнеке» дигәнне аңлаткан, чөнки ул туар алдыннан яки үлгәннән соң җан тукталган урын дип уйланылган. Башка вариант: протогерман *saiwaz (чаг. *see* «диңгез») сүзеннән: субварианты «күлдән», монда күл борынгы Төньяк Европада җаннар яши торган урын дип аңлатыла [Online Etymology…].

*Soul* сүзенең «үлгән кешенең җаны» дигән мәгънәсе борынгы инглиз телендә 971 елда ук теркәлгән. «Dictionary.com» сүзлеге *soul* сүзенең беренче мәртәбә тагын да иртәрәк – 900 елга кадәр язып алынганлыгын раслый [Dictionary.com].

Төрле сүзлекләрдә инглиз телендәге *soul* сүзенең этимологиясе охшаш. «Etymologeek.com» онлайн-сүзлегендә түбәндәге этимологиясе күрсәтелгән: «Английское слово *soul* “душа” происходит от протогерманского *saiwalō (душа, жизненная сила)» [Etymologeek.com]. Борынгы инглиз телендә (чама белән 450–1100 еллар) sāwl формасы кулланылган. Бу вакытта сүзнең дини һәм фольклористик мәгънәләре барлыкка килә: кешенең рухы яки асылы, гадәттә ул аның фикерләрен һәм шәхесен колачлый. Алар кеше үлгәннән соң да яшәвен дәвам итә, дигән фикер дә бар [шунда ук]. Синоним буларак, «кеше, индивидуум, кеше» мәгънәсендә *soul* сүзе XIV гасыр башы белән билгеләнә [Online Etymology…].

Сүзлекләрдә инглиз телендәге *soul* сүзенең тарихи тәңгәллекләре күрсәтелә: борынгы ингл. *saiwol «кешенең рухи һәм эмоциональ өлеше, җанлы яшәү; тормыш, тере зат» протогерман телендәге *saiwalō сүзеннән (шулай ук түбәндәгеләр чыганак булып тора: борынгы саксон sēola, борынгы скандинав sāla, sāl, борынгы фриз sēle, урта голланд siele, голланд ziel, борынгы югары немец sēula, немец Seele, гот saiwala) [Chamber's Etymological…, p. 481; Collins English…; Collins Concise…; Online Etymology…; Partridge, p. 3139–3140], иске инглиз sāwl, sāwol [26].

М.М. Маковский, җанның локальләшүенә мөнәсәбәтле, «Инглиз теленең тарихи-этимологик сүзлегендә» («Историко-этимологический словарь английского языка») болай дип яза: «Согласно широко распространенной мифопоэтической традиции, души умерших пребывают в деревьях и в горах, а также в море (или вообще в воде). Ср. англ. soul, нем. Seele "душа", но тох. A sul "гора". … С другой стороны, англ. soul "душа" соотносится с лат. *silva* "лес"; ср. также греч. *ξυλον* "дерево", но англ. soul "душа"» [Маковский, с. 343–344]. Инглиз дөнья тел картинасының үзенчәлеге шунда: җан-микрокосмос – Галәм-макрокосмос, герман телләрендә кояш белән ассоциацияләнә: «С англ. soul "душа" следует сопоставить еще следующие слова: литовск. pa-saulis "Вселенная"; гот. sauil "солнце"; и.-е. *sul- "жидкость" (души умерших пребывают в море, в реке: ср. др.-сев. siolo þ "море"» [Маковский, с. 344].

Төрки дөнья тел картинасына мөрәҗәгать итик. Төрки телләр сүзлекләрендә *җан* сүзенең этимологиясе һәрвакытта да аңлаешлы түгел. К. Сейдакматов «Кыргыз тилинин кыскача этимологиялык сөздүгү»ндә («Краткий этимологический словарь кыргызского языка») турыдан-туры *җан* сүзенең Иран тамырларына күрсәтә [Сейдакматов, с. 88].

В.С. Расторгуева һәм Дж.И. Эдельман «Иран телләренең этимологик сүзлеге»ндә *an* сүзе гомумарий телендәге «суларга, өрергә» сүзенә барып тоташа, дип язалар [Расторгуева, Эдельман, с. 153–154]. Бу сүз «суларга» (*ániti*) мәгънәсендәге борынгы һинд телендәге *an* белән охшаш [шунда ук]. Юлиус Покорный *an-* сүзенең һинд-европа телләрендәге *an* «суларга, өрергә» фигыле белән бәйләнешен күрсәтә [Pokorny, s. 40–41]. *An* тамыры латинча *animus* «җан», «рух», *anima* «исеп кую, сулыш, рух», тохарча *Banäsk* «суларга» сүзләрендә очрый. Башка телләрдәге җанны белдергән сүзләр һава хәрәкәте мәгънәсенә туры килә: «эвенк, elbu, olbu-n 'душа умершего; тень', засвидетельствованное только в западных диалектах эвенкийского; скорее всего, это слово … заимствовано из кет. ul-bef' / ut-vef "вихрь; душа, тень" (букв, "вихрь" + "ветер")» [Дыбо, с. 207].

«Древнетюркский словарь» хезмәтендә беренчел jandī «ут янды» фигыле китерелеп, *jan* сүзен «янарга» мәгънәсе бирелә [Древнетюркский словарь, с. 231]. Башка сүзлекләр дә шул ук этимологияне күрсәтә. *Йан* «янарга» сүзе үзбәк, кыргыз һәм

казакъ телләрендәге *жан*га туры килә [Этимологический словарь тюркских..., с. 112].

Җанның локальләшүе мәсьәләсендә төрки сүзлекләрдә берничә тәңгәллек билгеләнә. А.В. Дыбо түбәндәгеләрне ассызыклый: «кирг. курсак ‘брюхо, утроба, чрево’; метоним. «душа» (*курсагым оорун турат* «мне (его, тебя и т. д.) [3, IX: 107]; «ПАлт. *ŏ́ŕí ‘середина, внутренность, внутренности («внутренний» живот)’: ПМ *öre ‘внутренность; брюшная полость’: ср.-монг. оre ‘сердце’, ого ‘брюшная полость’, Houa-yi örö ‘брюшная полость’, письм.-монг. öri, örö, öri ‘внутренность; сердце; живот; аорта; брюшная полость’. Халха ör(n) ‘подложечная область; душа; центр’; Ордос. ör (o) ‘душа’. Бур. Üre ‘внутренняя часть, центр’. Калм. ör ‘ядро, центр; грудь, душа’. Баоань. огэ ‘желудок’. Могол. ourâ ‘сердце, душа’» [Дыбо, с. 107–108].

Алынган нәтиҗәләрне 1 нче таблицага төшерәбез. «+» тамгасы – мотивлаштыра торган билге булуны, « – » тамгасы аның булмавын аңлата.

1 нче таблица

*Душа, soul* һәм *җан* концептларының мотивлаштыра торган билгеләре

| №№ | Мотивлаштыра торган билгеләр | Душа | Soul | Җан |
|---|---|---|---|---|
| 1. | ‘күбәләк’ | + | – | – |
| 2. | ‘корсак / карын / эч’ | – | – | + |
| 3. | ‘суда’ | – | + | – |
| 4. | ‘агачта’ | – | + | – |
| 5. | ‘җил’ | + | – | + |
| 6. | ‘өермә’ | – | – | + |
| 7. | ‘һава’ | + | – | – |
| 8. | ‘янарга’ | – | – | + |
| 9. | ‘күкрәк’ | – | – | + |
| 10. | ‘өрергә’ | – | – | + |
| 11. | ‘рух’ | + | – | – |
| 12. | ‘сулыш’ | + | – | – |
| 13. | ‘суларга’ | – | – | + |
| 14. | ‘ашказаны’ | – | – | + |
| 15. | ‘тормыш өчен кирәкле’ | – | + | – |
| 16. | ‘вак күбәләк’ | + | – | – |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17. | ‘өрәкләр’ | + | – | – |
| 18. | ‘гакыл’ | + | – | – |
| 19. | ‘диңгездән’ | – | + | – |
| 20. | ‘күлдән’ | – | + | – |
| 21. | ‘күкрәк асты’ | – | – | + |
| 22. | ‘-ныкы булу’ | – | + | – |
| 23. | ‘килгән’ | – | + | – |
| 24. | ‘йөрәк’ | – | – | + |
| 25. | ‘көч’ | – | + | – |
| 26. | ‘кояш’ | – | + | – |
| 27. | ‘күләгә’ | – | – | + |
| 28. | ‘күкрәк читлеге өстендәге чокырчык’ | + | – | – |

Рус дөнья тел картинасында *душа* концепты структурасында түбәндәге тугыз мотивлаштыра торган билге ачыкланган: ‘күбәләк’ ‘җил’, ‘һава’, ‘рух’, ‘сулыш’, ‘вак күбәләк’, ‘өрәкләр’, ‘гакыл’, ‘күкрәк читлеге өстендәге чокырчык’.

Инглиз дөнья тел картинасында *soul* концептында түбәндәге тугыз мотивлаштыра торган билге табылган: ‘суда’, ‘агачта’, ‘тормыш өчен кирәкле’, ‘диңгездән’, ‘күлдән’, ‘кемнекедер булу’, ‘килгән’, ‘көч’, ‘кояш’.

Төрки дөнья тел картинасында *җан* концептының түбәндәге унбер мотивлаштыручы билгесе бар: ‘корсак/ карын/ эч’, ‘җил’, ‘өермә’, ‘янарга’, ‘күкрәк’, ‘өрергә’, ‘суларга’, ‘ашказаны’, ‘күкрәк асты’, ‘йөрәк’, ‘күләгә’.

Рус дөнья тел картинасында *душа* һәм *дух* концептлары изомотивлашкан булып торалар. Бу концептлар бер тамырлы лексемалар белән вербальләшәләр.

Рус һәм төрки дөнья тел картиналарында ‘җил’ мотивлаштыра торган билгесе уртак. *Душа* концептының – ‘сулыш’ һәм ‘күкрәк читлеге өстендәге чокырчык’, *җан* концептының ‘суларга’, ‘күкрәк’ кебек мотивлаштыра торган билгеләре үзара яраша. *Soul* һәм *җан* концептлары арасында үзара бәйләнеш күзәтелә: аларның ‘кояш’ һәм ‘янарга’ кебек мотивлаштыра торган билгеләре охшаш була.

Җанның стихияләр белән бәйләнеше игътибарны үзенә җәлеп итә: рус дөнья тел картинасында *душа* белән – һава (‘җил’, ‘һава’, ‘рух’, ‘сулыш’), инглизнекендә *soul* белән – су (‘суда’, ‘диңгездән’, ‘күлдән’ һәм ут (‘кояш’), төркинекендә *җан* белән – һава (‘җил’, ‘өермә’, ‘өрергә’, ‘суларга’) һәм ут (‘янарга’) ассоциацияләнә.

## Әдәбият

*Гаспарян Н.К.* Концепт «Душа» в сопоставительном аспекте: русская и армянская картины мира // Слово.ру: Балтийский акцент. 2017. Т. 8. № 1. С. 84–91.

*Горяев Н.В.* Сравнительный этимологический словарь русского языка. Тифлис: Тип. Канцелярии главнонач. гражд. ч. на Кавказе, 1896. 558 с.

Древнетюркский словарь / ред.: В.М. Наделяев, Д.М. Насилов, Э.Р. Тенишев, А.М. Щербак. Л.: Наука, Ленинград. отд-ние, 1969. 676 с.

*Дыбо А.В.* Этимологический словарь тюркских языков. Этимологический словарь базисной лексики тюркских языков. Астана: ТОО «Prosper Print», 2013. Т. IX. 616 с.

*Журавлева Е.А.* Концепт «Душа» в русском национальном самосознании // Актуальные вопросы современной филологии и журналистики. 2007. № 3. С. 107–113.

*Крылов Г.А.* Этимологический словарь русского языка. СПб.: ООО «Полиграфуслуги», 2005. 428 с.

*Маковский М.М.* Историко-этимологический словарь английского языка. М.: Диалог, 1999. 416 с.

*Маринина Г.И.* Национально-культурная специфика реализации концепта «Душа» в английской, немецкой и русской фразеологической картине мира // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2017. № 10 (76). В 3-х ч. Ч. III. С. 132–135.

*Пименова М.В.* Этногерменевтика языковой наивной картины внутреннего мира человека: монография. Кемерово: Кузбассвузиздат; Landau: Verlag Empirische Pädagogik, 1999. 262 с. (Серия «Этнориторика и этногерменевтика». Вып. 5).

*Пименова М.В.* Концепты внутреннего мира (русско-английские соответствия): дис. … д-ра филол. наук. СПб., 2001. 497 с.

*Пименова М.В. Душа* и *дух*: особенности концептуализации: монография. Кемерово: ИПК «Графика», 2004. 386 с. (Серия «Концептуальные исследования». Вып. 3).

*Преображенский А.Г.* Этимологический словарь русского языка. М.: Тип. Г. Лисснера и Д. Совко, 1910–1914. Т. I.

*Расторгуева В.С., Эдельман Дж.И.* Этимологический словарь иранских языков. М.: Восточная литература, 2000. Т. I. 328 с.

*Свиридова М.Н.* Этимологический словарь современного русского языка. М.: Аделант, 2014. 511 с.

*Сейдакматов К.* Кыргыз тилинин кыскача этимологиялык сөздүгү (Краткий этимологический словарь кыргызского языка). Фрунзе: Илим басмасы, 1988. 331 с.

Словарь русских народных говоров / под ред. А.Е. Аникина. М.: Наука, 1972. Т. 8. 369 с.

*Цыганенко Г.П.* Этимологический словарь русского языка: Более 5000 слов. 2-е изд., перераб. и доп. Киев: Рад. шк., 1989. 510 с.

*Черных П.Я.* Историко-этимологический словарь современного русского языка: в 2 т. 3-е изд., стереотип. М.: Русский язык, 1999. Т. I.

*Шанский Н.М.* Школьный этимологический словарь русского языка. [Электронный ресурс]. URL: https://gufo.me/dict/shansky/%D0%B4%D1%83%D1%88%D0%B0 (дата обращения: 19.03.2023).

*Шапошников А.К.* Этимологический словарь современного русского языка: в 2 т. 2-е изд., стер. М.: ФЛИНТА, 2016. Т. I. 586 с.

Этимологический словарь славянских языков. Праславянский лексический фонд / под ред. О.Н. Трубачёва. М.: Наука, 1988. 232 с.

Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на буквы «Ж,», «Ж» и «Й» / отв. ред. Л.С. Левитская. М.: Наука, 1989. Т. IV. 292 с.

Chamber`s Etymological Dictionary of the English language / Ed. J. Donald. London & Edinburg: W. & R. Chambers, 1874. 596 p. P. 481.

Collins English Dictionary. Copyright © HarperCollins Publishers. [Электронный ресурс]. URL: https://www.collinsdictionary.com/dictionary/english/soul (дата обращения: 19.03.2023).

Collins Concise English Dictionary © HarperCollins Publishers. [Электронный ресурс]. URL: https://www.wordreference.com/definition/soul (дата обращения: 19.03.2023).

Dictionary.com [Электронный ресурс]. URL: https://www.dictionary.com/browse/soul (дата обращения: 19.03.2023).

Etymologeek.com [Электронный ресурс]. URL: https://etymologeek.com/eng/soul/35205984 (дата обращения: 19.03.2023).

Online Etymology Dictionary [Электронный ресурс]. URL: https://www.etymonline.com/word/soul (дата обращения: 19.03.2023).

*Partridge E.* A Short Etymological Dictionary of the Modern English. London and New York: Taylor & Francis Group, 2006.

*Pokorny J.* Indogermanisches etymologisches Wörterbuch. Francke Verlag Bern und München, 1959. 348 s.

***Пименова Марина Владимировна,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*П.П. Семёнова – Тян-Шанский исемендәге*
*Халыкара гуманитар университет ректоры (Санкт-Петербург)*

УДК 81'373.47

***М.З. Вәлиева***

# XVII–XVIII ГАСЫР ИСКЕТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ТОТРЫКЛЫ СҮЗТЕЗМӘЛӘР

Статья посвящена изучению фразеологизмов в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII веков. В работе выявлены и описаны основные функции устойчивых словосочетаний. Исследование показывает, что в текстах старотатарских письменных источников преобладают фразеологизмы, выполняющие экспрессивно-описательную функцию, для создания образности, выразительности и заостренности мысли.

**Ключевые слова:** старотатарский письменный литературный язык, лексика, стилистика, устойчивые словосочетания, фразеологизмы.

The article is devoted to the study of phraseological units in the Old Tatar written sources of the 17th–18th centuries. The work identifies and describes the main functions of stable phrases. The study shows that phraseological units that perform an expressive-descriptive function to create imagery, expressiveness and sharpness of thought prevail in the texts of Old Tatar written sources.

**Keywords:** Old Tatar written literary language, vocabulary, stylistics, set phrases, phraseological units.

Тотрыклы сүзтезмәләр, ягъни фразелогик берәмлекләр әдәби әсәрләрдә, шул исәптән язма истәлекләрдә халык авыз иҗаты белән тыгыз бәйләнештә торган сурәтләү чарасы булуы белән кыйммәтле. Татар телендә фразеологизмнарны өйрәнү, төрләрен билгеләү, туплау, төркемләү мәсьәләләре, аларга хас семантик һәм грамматик үзенчәлекләр һ. б. Ш.А. Рамазанов [1954], Г.Х. Әхәтов [1979], Г.Х. Ахунҗанов [1972], С.Ш. Поварисов [1982], Ф.С. Сафиуллина [1999] хезмәтләрендә, «Татар теле лексикологиясе» академик басмасында яктыртыла. Татар тел белемендә фразеология сүзенең ике мәгънәдә йөрүе искәртелә: 1) телнең тотрыклы сүзләр җыелмасы; 2) тотрыклы сүзтезмәләрне өйрәнә торган тел белеме тармагы [Татар теле лексикологиясе, 2015, б. 197]. Мәгълүм булганча, фразеологизм – күчерелмә мәгънәле, семантик структур яктан бөтен, образлылык, сурәтлелек, экспрессивлык билгеләренә ия булган, сөйләмгә әзер килеш килеп кергән тотрыклы сүзтезмә [шунда ук, б. 201]. Тотрыклы сүзтезмәләрдә халыкның зирәклеге, гасырлар дәвамында туплаган тәҗрибә белән бергә язучының дөньяга карашы, телнең нәфислеген нечкә тоемлавы бергә үрелеп бара. Әсәр тукымасына килеп кергән фразеологик әйтелмә төрле максаттан чыгып кулланыла. Галимнәр фразеологик әйтелмәләрнең берничә стилистик функциясен аерып күрсәтә. Д.Э. Розенталь тарафыннан, мәсәлән,

фразеологизмнарның төп функцияләренең берсе булып атау ягъни номинатив функция китерелә. Фразеологик әйтелмә ярдәмендә әдәби әсәрдә, сөйләмдә лирик геройны, персонажны аерып күрсәтергә, аның теге яки бу сыйфатларын атау аша, геройга бәя бирелергә мөмкин. Икенче төп вазифасы дигәндә, экспрессив-стилистик функция башкаруы күздә тотыла [Розенталь, 2019, с. 60–62]. Фразеологизмнарның кулланылышын өйрәнгән А.М. Мелерович исә фразеологик әйтелмәләрнең төп вазифаларыннан «характерлаучы функция» (характеризующая функция), «экспрессив-тасвирлама функция» (экспрессивно-описательная функция) дигән төрләрен аерып күрсәтә. Беренчесе геройга бәя бирү, теге яки бу сыйфатын аерып күрсәтүне күздә тотса, икенчесе өстәмә экспрессивлыкны, коннотативлыкны үз эченә ала, вакыйга, хис-кичерешләрне эмоциональ тасвирлау белән бәйле [Мелерович, 2011].

Фәнни хезмәтләрдән күренгәнчә, тотрыклы сүзтезмәләр аерым категория буларак шактый җентекле тикшерелгән. Әмма аларның язма истәлекләрдә кулланылыш үзенчәлекләре бүгенге көндә өйрәнүне таләп итә торган актуаль күренеш булып тора. Бу җәһәттән, Мәүла Колый хикмәтләре, билгесез автор тарафыннан язылган «Дәфтәре Чыңгызнамә», Мөслиминең «Тәварихы Болгария», фарсы теленнән тәрҗемә ителгән «Мәҗмүгъ әл-хикәят» һ. б. кебек XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә кулланылган башка төр ономастик һәм лексик берәмлекләрне тикшерү белән бергә [Валиева, 2017; 2022], аларда фразеологизмнарның кулланылыш үзенчәлекләренә дә анализ ясау зур әһәмияткә ия. Шуларны күздә тотып, әлеге язмада тотрыклы сүзтезмәләрнең XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендәге кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнүне максат итеп куябыз.

Халык зирәклеген, борынгы тел үзенчәлекләрен гасырдан гасырга күчереп саклап килә торган тотрыклы сүзтезмәләр XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә, башлыча, түбәндәге функцияләрне башкара:

1. Лирик геройга, персонажга бәя бирү, аны атау, характерын ачу функциясен үти торган фразеологизмнар. Бу төр фразеологизмнар кешенең теге яки бу гадәтенә ишарә итү, берәр эчке сыйфатын тасвирлау аша лирик геройның холык-фигылен күрсәтә. Мәсәлән, түбәндәге мисалда *күзе малга туймас* фразеологик берәмлеге тискәре геройның эчке сыйфатларын образлы итеп тасвирлау максатыннан килә: *Син хан углы дүгелсең, йортка лайык дүгелсең, дийәрләр, үз хәлен белмәсләр, **күзе малга туймаслар*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

Уңай сыйфатлары өчен якын күрү, ул кешене артыгы белән олылау-кадерләү «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә *күзе өстендә каш* фразеологизмы аша җиткерелә: *Андин соң Чыңгыз хан бу бикләрне **күзе өстендә кашы** тик күрер ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 81].

Укучының игътибарын лирик геройның тискәре якларына, мәсәлән, кешегә файда китерердәй, игелек кылырдай һөнәр-шөгыль

эшли белмәвенә кул мәгънәсендәге иске татар сүзе *әл* катнашында ясалган *әлдән / әлемдән килми* фразеологик берәмлеге ишарә итә: *Кушамат атымдыр минем – Мәндан, / Изге* ***эш килмәде бер әлемдән*** [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 168].

2. Экспрессив-тасвирлама функция башкара торган фразеологик әйтелмәләр. Тотрыклы сүзтезмәләрнең әлеге функциясе язма истәлекләрнең стилен эмоциональ яктан яңа төсмерләргә баетуы, сүзнең коннотатив мөмкинлекләрен тагын да көчәйтеп күрсәтә алуы белән аерылып тора. Иске татар язма истәлекләреннән тупланган фактик материал нигезендә, экспрессив-тасвирлама функциянең берничә тармагын аерып күрсәтергә кирәк:

1) лирик геройның эмоциональ халәтен тасвирлау функциясен башкара торган фразеологизмнар. XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә бу төр фразеологизмнар шактый киң кулланыла, биредә сөю-ярату, кайгы-хәсрәт, борчу, шатлык-сөенеч хисләре кичерү һ. б. хис-кичерешләрне тасвирлау белән бәйле әйтелмәләр күздә тотыла. Тезмә әсәрләрдә дә, чәчмә әсәрләрдә дә геройның эчке кичерешләре, теге яки вакыт аралыгында булган күңел халәте фразеологизмнар ярдәмендә образлы яктыртыла. Чәчмә әсәрләрдә, мәсәлән, фразеологик берәмлекләр лирик геройның хисләрен, гашыйк булу, сөю-ярату кебек кичерешләрне тасвирлау барышында киң кулланыла. Суфи шагыйрьләр, эчке кичерешләрне тагын да тирәнрәк, хис-тойгыны көчлерәк бирү өчен, әсәр тукымасына *күңел, бәгырь* кебек лексик берәмлекләр катнашында ясалган фразеологик берәмлекләрне кертеп җибәрә. Түбәндәге мисалларда *күңел азу, күңел төшү* кебек фразеологизмнары лирик геройның гашыйк булуын, кызга күзе төшүен җиткерә: *Йөзе гөлдин тазадыр, / Кашына каләм йазадыр, / Кашыкүзе күмелсен, / Күрсәм,* ***күңелем азадыр*** [Габдессәлам, 2006, б. 46]. ***Күңелем төште*** *үзеңә, / Күңгер-кара күзеңә* [Габдессәлам, 2006, б. 47]. Шулай ук *йөрәк яну, бәгырь яну* кебек фразеологик берәмлекләр дә лирик геройның кайнар хисләрен эмоциональ һәм образлы итеп җиткерә: ***Йөрәккәйем йанадыр,*** */ Кермәйсең лә сүземә* [Габдессәлам, 2006, б. 47]. *Сәне күрми торыр улса, /* ***Бәгърем*** *ут кеби* ***йанар*** [Габдессәлам, 2006, б. 59]. Шулай ук арада хәзерге татар әдәби телендә *бәгырем парә-парә килә* кебек фразеологик берәмлекнең башка вариантын очратырга мөмкин: ***Бәгъреме парә кыладыр*** */ Ул висалең кичәсе* [Габдессәлам, 2006, б. 54].

Гомумән, иске татар язма истәлекләре стилендә *күңел* белән бәйле фразеологик берәмлекләрнең күп булуын искәртергә кирәк. Авторларның әсәрне күңел аша үткәреп иҗат итүе, лирик геройның яки персонажның вакыйгаларны күңеле белән кабул итүе, күңелендә кайнаган хисләрен җиткерүе – болар барысы да халык телендә бүген дә актив кулланылышта булган *күңел тулу, күңел калдырмау, күңел ачылу, күңел эрү* һ. б. фразелогизмнары ярдәмендә зур осталык белән җиткерелә: *Остазым бу җиһанны фани белде, / Әүлияләр гыйшкы белә* ***күңле тулды*** [Мәула Колый, 2001, б. 16]. *Әмма* ***күңелемне кал-***

***дырмасаң** ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70]. *Кил, имде, әй, Бүртә Кучин, минем катыг **күңелемне калдырмагыл**, үзеңне миндин аермагыл, – тиде.* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 77]. *Бу тол калган җиңгәбез агамыз үлгәнгә кайгырадыр, аңа уйынга алып барамыз, **күңеле ачылсын*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 72]. *Андин соң Чыңгыз ханның **күңеле эреде,** икәүесе бер-беринә кабул булыб хәләл җефет булдылар* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 78].

Чәчмә әсәрләрдә лирик геройның яисә персонажның хис-кичерешләрен җиткерүдә дә фразеологизмнар кулланыла. Бу очракта сөенү, шатлану мәгънәсендәге *күңел табу*, борчылу, сагышлануны аңлата торган *күңеле йаман булу* кебек бүгенге әдәби телдә сирәк кулланыла торган фразеологик берәмлекләрне дә очратырга мөмкин: *Андин соң ул кичә чадыр корып йаттылар, **күңелләрен тапдылар*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70]. *Ул ике углы тугандин соң Гыйләмалик Күрекленең **күңеле йаман булды*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

Суфи шагыйрьләрнең сөйгән ярлары өчен йөрәкләре генә янып калмый, алар җаннарын да бирергә әзер. Шагыйрьнең әлеге хис-кичерешләре бүгенге көндә дә халык авыз иҗаты әсәрләрендә киң кулланыла торган *җаным фида кылу* гыйбарәсе ярдәмендә бирелә: *Җаным **фида кылырмын*** / Бер кәлимә сүзеңә [Габдессәлам, 2006, б. 46]. *Җаным **фида кылырым*** / Коңгырт кара күзеңә [Габдессәлам, 2006, б. 50]. Гаҗәпләнү, соклану кебек хис-тойгыларны исә *таңга калу, хәйран калу* фразеологизмнары ача: *Анлар бу эшне күреб **таңга калдылар*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 74]. *Хәзрәте Аксак Тимер бу кырмысканың бу эшигә **хәйран калыб** караб торыр ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82].

Шулай ук эмоциональ-экспрессив функция башкара торган фразеологизмнар арасында кешегә кайгы-хәсрәт килүне, лирик геройның борчулы уйларын җиткерә торган *яшь түгү, сагыш төшү, хәсрәт уты йагу, каты хәсрәт ору, башыма бәла килү,* кебек гыйбарәләрне очратырга мөмкин. Бу төр фразеологизмнарның иске татар язма истәлекләрендә дә урын алуы авторларның телне тирән тоемлап, аның эчке мөмкинлекләреннән киң файдаланулары хакында сөйли: *Бу мискин, Мәүла Колый, **яшьләр түксен,** / Иман әйтеп, тәгать кылып, гомер кичсен* [Мәүла Колый, 2001, б. 23]. ***Сагыш төште** күңлем эчрә, тыңла, дустлар, / Тыңласагыз, разын сезгә ачарбыз, аh* [Мәүла Колый, 2001, б. 34]. *Айырылубән китәр улдым, / Сезне күрмәк кандулә! / **Хәсрәт уты йакты*** бәне, / Канда безә шат ула [Габдессәлам, 2006, б. 70]. *Каты **хәсрәт орды** безә / Фиркать улмак бигөман* [Габдессәлам, 2006, б. 53]. ***Башымга күп бәла килсә,** / Хишем-ишем күңел өзсә, / Ушал дәмдә күңел өзмәз / Вәфалыдин җөда булдым* [Утыз Имәни, 1986, б. 33].

Герой-персонажның психологик халәтен генә түгел, ә тормыш тәҗрибәсен тасвирлау өчен дә фразеологик әйтелмәләр җәлеп ителә: *Сәнин **башындин күб эшләр кичсә** кирәкдер* [Мөслими, 1999, б. 36].

***Башындин үткән эшләрне** вә галимләр исемләрене языб, Мир Тимер хәзрәтенең алдына салды* [Мөслими, 1999, б. 42].

Әмма нинди генә авыр шартларда да, авыр сынауларда да суфи шагыйрьләрнең лирик герое үзенең кешелек сыйфатларын, сабырлыгын саклап калырга, тормыш төбеннән күтәрелергә тиеш. Мондый мизгелләрдә аңа Аллаһка ышану ярдәм итә. Лирик геройның күңелендәге әнә шундый психолик катламнарны, эмоциональ халәтен тасвирлауда шигъри текстка *өмид өзми* фразеологизмы килеп керә: *Бозык эшә тел вә дилең түзми, / Ходаның рәхмәтендин **өмид өзми*** [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 135].

Габдерәхим Утыз Имәни иҗатында өметсезлеккә бирелмәү кебек хисләр еш кына *күңел өзмәү* фразеологизмы ярдәмендә сурәтләнә: *Башымдин күб **бәла килсә**, / Хишем-ишем **күңел өзсә**, / Ушал дәмдә **күңел өзмәз** / Вәфаламдин җөда булдым* [Утыз Имәни, 1986, б. 33].

Персонажның яисә лирик геройның кылган эшләренә үкенү, тәүбәгә килүе белән бәйле хис-кичерешләре дә суфи шагыйрьләр иҗатында еш яктыртыла: *Бозык эшне куйасы, изге эшне йулласы, / Бозык эшдин **тәүбә кыйлдым**, Хак йулында буласы* [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 125].

Суфи шагыйрь укучыны тәүбә итәргә генә түгел, ә киңәшләренә колак салырга, китап укырга да өнди. Боларның барысы да *күңелгә алу, колак салу* дигән фразеологизмнар ярдәмендә укучының рухына үтеп керерлек дәрәҗәдә оста итеп җиткерелә: ***Күңелгә ал** буны, и әхи, / **Колак сал**, бераз диим вәхи* [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 130]. *Китапларга әгәр **колак салырсаң**, / Ходай тәүфикъ бирсен, кирәген алырсың* [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 164]. *Нә сүз дисәм, **колак салган**, / Ивем эчен йигып торган, Һәр эшине белеп кыйлган / Һөнәрмәнддин җөда булдым* [Утыз Имәни, 1986, б. 32].

Китап укыганда да ихтыяр көче, сабырлык таләп ителә. Бу җәһәттән дә шагыйрьләр иҗатында фразеологик берәмлекләр ярдәмендә үгет-нәсыйхәт бирү чагылыш таба. Мәсәлән, Габдерәхим Утыз Имәни белем алырга теләмәгән укучыларын *китапка тел тидермә, йөзеңне чытма* кебек гыйбарәләр кулланып ачулана: *Боңа **тел тикүрән** төшкәй хәрабә, / Зира **тел тикүребдер** күп китабә* [Утыз Имәни, 1986, б. 38]. ***Чытма йөзең**, сүзлә аңа чүн гъәсәл, / Каты сүз димә аңа һич би-мәхәл* [Утыз Имәни, 1986, б. 49].

2) яшәү, гомер итү белән бәйле вакыйга-күренешләрне экспрессив тасвирлау функциясен үти торган фразеологик берәмлекләр. Тормышны алып бару, дөнья мәшәкатьләренә күмелеп яшәү, кайчак лирик геройның ваемсыз тормыш рәвеше алып баруы да *дөнья куу, дөньяны уздыру* дигән традицион сүз-сурәт – фразеологик берәмлек ярдәмендә тасвирлана: *Йөримез **дөнйа куып** арып-ачып, / Кем теректер әҗәл шәрабын эчеп* [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 134]. *Халыкка олуг туй кыйлдылар, бу **дөнйаны уздырдылар*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 78]. Мәүла Колый лирик героеның яшәвен, гомер итүен *гомер кичү* фразеологизмы белән бирә: *Каһиллектә гафил*

*ятып* ***гомер кичәр,*** */ Җандин җөда бу бу тән гүргә күчәр* [Мәүла Колый, 2001, б. 12].

Суфи шагыйрьләр иҗатында дөньяга килү, язмышында язылганча яшәү, вафат булу кебек фәлсәфи фикер-карашлар да төрле поэтик бизәк ясауда киң кулланыла торган фразеологик берәмлекләр аша җиткерелә. *Тәгъдир язу* фразеологизмында лирик геройның кеше язмышының алдан билгеләнеп куелуы, һәрбер вакыйга-күренешнең Аллаһ кодрәтендә булуы кебек фәлсәфи карашлары чагылыш таба: *Йөретми йукса бәне* ***тәгъдир йазып,*** */ Китте бән гарибнең фигыле азып* [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 134].

Тормышта барлык нәрсә дә хәрәкәттә, кеше дә бу җиргә киләкитә. Язучының яисә лирик геройның шул хактагы фәлсәфи-уйланулары, шулай ук персонажның тууы-үлеме белән бәйле вакыйгалар шулай ук фразеологик берәмлекләр ярдәмендә бирелә. Поэтик әсәрләрдә бу вакыйга кайсыдыр урында ул *җан тәслим иту* дип, шактый кискен рәвештә, кайдадыр *гүргә керү, дөнья кую, әҗәл йиту* фразеологизмнары ярдәмендә эчке бер сабырлык белән бәян ителә: *Терекендә йавызлар берлә йөрсә, / Изге гамәл кылмай, үлеп,* ***гүргә керсә*** [Мәүла Колый, 2001, б. 21]. *Хакдин үзгә кем беләсе, кемнәр килеп кем китәсе, / Безгә гыйбрәт шул тийәсе,* ***дөнйа куйды*** *Хакның дусты* [Габделмәннан Мөслимов, 2006, б. 125]. *Бохарадин чыкыб киткән, / Каурмач мөлкинә йиткән, / Ушал йирдә* ***әҗәл йиткән*** */ Казалыдин җөда булдым* [Утыз Имәни, 1986, б. 33].

Шулай ук тезмә әсәрләрдә дә, чәчмә әсәрләрдә дә бу максаттан *җан тәслим кылу* фразеологик берәмлегенең киң кулланылуын искәртергә кирәк: *Хакка тәгат кыла күрең, гаклы дана, / Хаҗ юлында* ***җан да тәслим кылды,*** *дуслар* [Мәүла Колый, 2001, б. 17]. *Вә янә һәр төрле тәганни илә әлхан идәрләр: ишедән гашыйклар рәкыс итеп* ***җан тәслим итәр*** [Мөслими, 1999, б. 21].

Шул ук вакытта бу чорда проза белән язылган әдәби ядкәрләрдә генә кулланыла торган фразеологик берәмлекләр дә күзәтелә. Мәсәлән, *дөньядин нәкыль кылу, бәкайә рихләт әйләү, дөнйадин үтү* кебек гыйбарәләр шундыйлардан: *Падишаһзадә балин гамь вә бәстәр госсада ятып,* ***дөньядин нәкыль кылды*** [Мәҗмүгъ эл-хикәят, 1963, б. 512]. *Дүртенче ел маһе рамазан мөбәрәкнең егерме йитенче кичәсендә фәтвайе җөмһүре голәмайе хәнәфия илә ләйләтел кадердер хәзрәте Мир Тимер даре* ***бәкайә рихләт әйләде*** [Мөслими, 1999, б. 47]. *Бичара вәзир җан куркынычыннан бер ләкъмә агзыйга салды, дәрхаль егылыб* ***җан бирде*** [Мәҗмүгъ эл-хикәят, 1963, б. 510]. *Бу сүзне халаикъка васыйәт кыйлгандин соң Дуйын Бәйан* ***дөнйадин үтте*** [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

Мисаллардан күренгәнчә, үлем яисә туу хакындагы фразеологик берәмлекләр тезмә әсәрләрдә дә, шигъри текстларда да киң кулланыла. «Тәварихы Болгария» әсәрендә Аллаһы Тәгалә илчеләренең, «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә ил-дәүләт башлыкларының, «Мәҗмүгъ эл-хикәят»тә персонажларның дөньяга килүе һәм китүе сурәтләнгән

өлешләр фразеологик берәмлекләр ярдәмендә тасвирлана. Биредә алар төрле эмоциональ мәгънә төсмерләре белән баетылалар. Мәсәлән, *җан алу* фразеологизмы Газраил галәйһиссәламнең гамәлләрен тасвирлап кына калмый, ә аның өстенлеген дә күрсәтә: *Газраил галәйһиссәлам әйде: «Мән сәнең кебе кол мән, илля Мәләкел-мәүт див бәне әйтерләр, ягъни барча мәхлукатлар җаныны вә һәм атаң-анаң **җаныны** бән **алдым**, див әйтде* [Мөслими, 1999, б. 16]. Мәүла Колый иҗатында да фәрештәләр гамәлен шагыйрь *җан алу* фразеологизмы белән бирә: *Фәрештәләр киткәйләр **җанны алып**, / Бу тән милкен какшатып йиргә салып* [Мәүла Колый, 2001, б. 21]. Мисаллардан күренгәнчә, әсәргә килеп кергән һәрбер фразеологик берәмлекнең үз урыны, ул гына җиткерә ала торган мәгънәви төсмере бар. Мәсәлән, юк итү, үтерү, тузанга әйләндерү күренеше «тузан» мәгънәсендәге фарсы сүзе *гәрд* катнашында ясалган *гәрд-гәрд кылу* сүзтезмәсе белән тасвирланса, юкка чыгу мәгънәсен исә *йир йоту* фразеологизмы җиткерә: *Карунны ул көндә **йир йотды*** [Мөслими, 1999, б. 10]. *Падишаһзадә әйтде: тәгамнән тәнавел кылмасаң, башыңны фил Мәхмүтнең айакыйга салып, **гәрд-гәрд кылырмын*** [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 510].

Лирик герой яисә персонажларның тууы белән бәйле вакыйгалар да авторлар тарафыннан фразеологизмнар белән эмоциональ тасвирлана. Бу төр фразеологизмнар күптөрле булулары, бер-берсен кабатламаулары белән аерылып тора. *Вөҗүдкә килде, җиһанә килү, дөнйага килү* берәмлекләре шул максаттан кулланылган: *Вә ул әхвалдин һич йөзигә салмады вә бу арада берничә мөддәд үтеп ирде, пәри кызыйдин янә бер кыз **вөҗүдкә килде*** [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 508]. *Дауд галәйһиссәлам вә Яхья галәйһиссәлам вә Искәндәр ул көндә **җиһанә килделәр*** [Мөслими, 1999, б. 10]. *Йәнә андин соң Алангуның бу сүзе халык арасында мәшһүр булды, **дөнйага качан килер** диб баланы көтәр ирделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 73].

Персонажның ил-дәүләт белән идарә итүен бәян итә торган *йорт тотмак*, ирдән яки хатыныннан аерылуын күздә тоткан *аягын бәнддин бушатты* һ. б. дигән фразеологизмнарның, нигездә, шушы иске татар язма истәлекләрендә генә күзәтелүен дә искәртергә кирәк: *Бу миндин туган өч угыл – Бүдән Чар, Кагыйн Чар, Салчут – болар **йорт тотмага** йахшы ирмәсләрдер* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71]. *Бу зарилык һич файда кылмас дип, мең алтын хакын бирде, **аягын** бәнддин **бушатты,** ата-анасының өйигә җибәрде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 515].

Төзелеше-составы ягыннан кайбер фразеолигик берәмлекләрне иске татар язма истәлекләрендә берничә вариантта очратырга мөмкин. Әсәр тукымасына ныклап кереп урнашкан фразеологик берәмлекләр авторның индивидуаль иҗат җимешенә әверелә дисәк тә дөрес булыр. Мисал итеп, *хәсрәт уты йоту, хәсрәт уты йагу* кебек берәмлекләр шундыйлардан: *Нәфес Хакны танымас, гөнаһ кылыр, арымас, / Нәфес шомың хаҗәлетдин **хәсрәт уты йотарым*** [Мәүла

Колый, 2001, б. 15]. *Айырылубән китәр улдым, / Сезне күрмәк кандулә! / **Хәсрәт уты йакты** бәне, / Канда безә шат ула* [Габдессәлам, 2006, б. 70]. Лирик геройның ургылып чыккан хисләрен, тирән сагышын тасвирлый торган *йөрәк йану* фразеологизмы *йөрәгендә ут йану* рәвешендә дә кулланылышта йөри: ***Йөрәккәйем йанадыр,** / Кермәйсең лә сүземә* [Габдессәлам, 2006, б. 47]. *Зөләйха тик **йөрәгендә ут янса** кирәк, / Аһ итмәктә, җиһан милке көяр улыр* [Мәүла Колый, 2001, б. 18].

Шул рәвешчә, XVII–XVIII гасыр иске татар язма истәлекләрендә кулланыла торган тотрыклы сүзтезмәләр ярдәмендә әдипләр аз сүз ярдәмендә күп мәгънә аңлата, җанлы картина тудыра, әйтергә теләгән фикерләрен укучыга образлы һәм үтемле итеп җиткерә. Аеруча чәчмә әсәрләрдә авторлар фразеологик гыйбарәләр ярдәмендә лирик геройларга, персонажларга характеристика бирә, геройларның эмоциональ халәтен, хис-кичерешләрен тасвирлый, аларның холыкфигылен, эчке сыйфатларын ача, кешенең дөньяга килүе һәм китүе белән бәйле вакыйга-кичерешләрне, халыкның тәҗрибәсе нигезендә дөрес дип табылган фикерләрне гәүдәләндерә. Шулай ук фразеологизмнар рәвешендә әйтелгән фикерләр авторның, лирик геройның акыл иясе булуын, кешелекле якларын яки күркәм әхлагын ачып бирә яки киресенчә, беренче карашка артык сизелмәгән тискәре сыйфатларын күрсәтә. Әлеге сурәтләү чараларында лирик геройның гына түгел, ә халыкның да гасырлар дәвамында тупланган зирәклеге, ныклы рухы сизелеп тора.

## Әдәбият

*Ахунҗанов Г.Х.* Татар теленең идиомалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 118 б.

*Әхәтов Г.Х.* Хәзерге татар теленең лексикологиясе (укытучыларга кулланма). Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 132 б.

*Валиева М.З.* Особенности синонимической парадигмы тюрко-татарского письменного памятника XVIII века «Маджмугыл-хикаят» // Вестник Чувашского государственного педагогического университета им. И.Я. Яковлева. Чебоксары, 2017. № 1 (93). С. 37–43.

*Валиева М.З.* Ономастикон татарских письменных источников (на примере письменного памятника «Дафтар-и Чингиз-наме») // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2022. Т. 15, вып. № 2 (128). С. 449–453.

*Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари.* Шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 397 б.

Габдессәлам // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 41–73.

*Дәфтәре Чыңгызнамә* // Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 37–96.

Мәүла Колый поэмалары / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 88 б.

Мәүла Колый шигырьләре // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 487–503.

Мәҗмүгъ әл-хикәят // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 503–522.

*Мелерович А.М., Мокиенко В.М.* Современная русская фразеология: (семантика – структура – текст). Кострома, 2011. 455 с.

*Мөслими* Тәварихы Болгария / басмага әзерл. С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

*Поварисов С.Ш.* Тел – күңелнең көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 160 б.

*Рамазанов Ш.А.* Татар теле буенча очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1954. 200 б.

*Розенталь Д.Э.* Русский язык на отлично. Стилистика и культура речки. М.: Изд-во АСТ: Мир и Образование, 2019. 272 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лескикология. Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

Татар лексикологиясе: өч томда. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145, 82:801.6

***Н.М. Юсупова***

# ЭНЦИКЛОПЕДИК ЭШЧӘНЛЕККӘ ИЯ ГАЛИМ
***(танылган әдәбият белгече, академик Дания Заһидуллинаның юбилее уңаеннан)***

Статья посвящена исследованию научной и литературно-критической деятельности доктора филологических наук, академика Дании Фатиховны Загидуллиной. В ней анализируется методология и методика изучения литературного процесса, определяются принципы и подходы к системному исследованию татарской литературы, выявляются оригинальность и своеобразие историко-литературной концепции учёного. В статье выявляется, что Д.Ф. Загидуллина внесла огромный вклад в расширение представлений об истории татарской литературы и татарской литературоведческой мысли в целом. В статье доказано значение научных трудов Д.Ф. Загидуллиной для развития татарского литературоведения.

Анализ литературно-критического и научного наследия Д.Ф. Загидуллиной, его оценка в литературоведческой парадигме дадут возможность выделить новые грани не только в научной деятельности ученого, но и в развитии современного татарского литературоведения в целом.

**Ключевые слова:** Д.Ф. Загидуллина, татарское литературоведение, научная деятельность, научная концепция.

The article is devoted to the study of the scientific and literary-critical activities of the Doctor of Philology, Academician of Daniya Fatihovna Zagidullina. It analyzes the methodology of studying the literary process, defines the principles and approaches to the systematic study of Tatar literature, identifies the originality of the historical and literary concept of the scientist. The article reveals that D.F. Zagidullina made a huge contribution to the expansion of ideas about the history of Tatar literature and Tatar literary thought in general. The article proves the importance of D.F. Zagidullina's scientific works for the development of Tatar literary criticism.

The analysis of D.F. Zagidullina's literary, critical and scientific heritage, its assessment in the literary paradigm will make it possible to identify new facets not only in the scientific activity of the scientist, but also in the development of modern Tatar literary criticism in general.

**Keywords:** D.F. Zagidullina, tatar literary studies, scientific activity, scientific concept.

Фәннең теләсә кайсы өлкәсен үз эшенә чиксез бирелгән, аңа намус белән караган, һәрвакыт яңалыкка, камиллеккә омтылган галим-остазлар алга әйдәп бара. Алар үзләре сайлаган фән тармагында үзгә сукмаклар салалар яки яңа юллар ачалар, саллы фикерләре, хезмәтләре белән фикер офыкларын киңәйтәләр. Филология фәннәре докторы (2001), профессор (2006), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (2014), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе

хакыйкый әгъзасы (академигы) (2011), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы (2004), тәнкыйтьче-галим, күп яшьләргә олы фән дөньясына юл ярган Остаз, Татарстан Язучылар берлегенең И. Юзеев исемендәге (2005), әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белем өлкәсендә Җ. Вәлиди (2006) исемендәге премияләре лауреаты Дания Фатих кызы Заһидуллина нәкъ шундый галимнәрдән. Ул чын мәгънәсендә XX–XXI гасырлар чиге татар әдәбият белеме фәнен яңа баскычка күтәргән фикер иясе, әдәбият нәзариясе буенча тирән белемле һәм мәгълүматлы теоретик, татар әдәбиятын бербөтен система итеп өйрәнгән галимә булып танылa, шушы юлда үзенең фәнни мәктәбен булдыра. Аның дөнья күргән һәр хезмәте фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан әдәбият фәнендә яңа сүз, үзгә тикшерену юлларын, концепциясен тәкъдим иткән басма булып кабул ителә.

Мөслим районы Әмәкәй авылы кызы Дания Салихова мәктәп елларында ук әдәбият белән кызыксына башлый, моңа мәктәпкә, яшь әдәбият укытучысы булып, Факил Сафинның кайтуы һәм әдәби түгәрәк оештырып җибәрүе дә йогынты ясый. Булачак галимә әлеге түгәрәкнең үзәгендә кайнап, мәктәп стена газетасының мөхәррире булып эшли, шигърият белән кызыксынып китә, аерым иҗат үрнәкләре район газетасында да дөнья күрә. Әлеге мавыгулар, кызыксынулар аны «Авыл утлары» газетасы каршында Фоат Садриев оештырган әдәби берләшмәгә, 1981 елда Казан дәүләт университеты филология факультетының татар бүлегенә алып килә. Уку дәвамында ул танылган, олпат галимнәр белән очраша, татар, рус, Европа әдәбиятларыннан бердәй мәгълүматлы, әсәр язуның нечкәлекләрен яхшы белгән, үзе дә язучы М. Мәһдиев җитәкләгән «Әллүки» түгәрәгендә кайный. Иҗади рухлы студент танылган шагыйрь-язучылар белән кичәләр, Татарстан, Башкортстан төбәкләренә әдәби очрашулар оештыруда катнаша. М. Мәһдиев белән аралашу аңа әдәбият серләренә төшенергә ярдәм итеп кенә калмый, дөньяны, кешеләрне танырга, камиллекне аңларга өйрәтә, ныклы ихтыяр көче тәрбияли һәм... фән дөньясына юл ача: Дания Салихова профессор Йолдыз Галимҗановна Нигъмәтуллина оештырган семинарларга йөри, ул вакытта Казан университетында структур-семиотик тикшеренүләрнең әйдәп баручысы булып танылган галим җитәкчелегендә фән серләренә төшенә башлый.

Университетны тәмамлаганнан соң, 1986 елда Дания Заһидуллина хезмәт юлын Татарстанның Балтач районы Түнтәр урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак башлап җибәрә. Ләкин күңеле белән фән дөньясына, яңалыкка тартылган укытучыга мәктәп кысалары тар булып тоела, 1989 елда ул, аспирантурага керү теләге белән, Казанга күчә, рус мәктәбендә татар теле укыта башлый. Язмыш аны яхшы мәгънәсендә тынгысыз, «демократик» фикерле галим Тәлгат Нәби улы Галиуллин белән очраштыра. Остазы булачак галимәгә олы фән юлында беренче сукмакларны салырга булыша, алга

таба да саллы киңәшләре белән һәрчак ярдәм итеп килә. 1989 елда Д. Заһидуллина Мәскәү милли мәктәпләр институты каршындагы аспирантурага керә һәм максатчан төстә әдәбият укыту методикасы мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлый. Казан дәүләт университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты оешканнан соң, укуын әлеге факультет каршында ачылган аспирантурада дәвам итә. 1992 елдан Д. Заһидуллина шушы факультетның татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасына укытучы итеп эшкә алына. 1993 елда филология фәннәре докторы, профессор Т. Галиуллин, педагогика фәннәре кандидаты, доцент К. Биктаһиров җитәкчелегендә «Татар әдәбияты дәресләрендә лирик әсәрләр өйрәнгәндә укучыларга әхлакый-эстетик тәрбия бирү (V–VIII класслар)» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый. Республикада чыга торган газета-журналларда фәнни мәкаләләр, язмалар белән даими чыгышлар ясый башлый. 2001 елда исә остазы Т. Галиуллин җитәкчелегендә «Татар әдәбият нәзариясенең формалашу һәм үсеш этаплары (XX гасырның беренче чиреге)» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый.

Университетта ассистент буларак башланган хезмәт юлы аны өлкән укытучы (1993), доцент (1996) баскычлары аша, профессор (2002), кафедра мөдире (2008) дәрәҗәсенә күтәрә. 2007 елдан Д. Заһидуллина хезмәт юлын Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе буларак дәвам итә, шул ук елда академиянең мөхбир әгъзасы, 2011 елда хакыйкый әгъзасы (академик) булып, 2017 елдан вице-президенты итеп сайлана һәм 2023 елга кадәр шушы вазифада хезмәт куя. 2023 елдан Д. Фатих кызы Заһидуллина Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре вазифасында фәнгә хезмәт итү юлын дәвам итә.

Шушы еллар дәвамында Д. Заһидуллина әдәбият белеме фәне үсешен өйрәнүне яшәү гаменә әверелдергән, үз фәнни мәктәбен булдырган абруйлы тикшеренүчеләрнең берсе, узган гасыр башында иҗат ителгән бик күп әдәби ядкәрләрне татар укучысына кайтарган текстолог, җәмәгать эшлеклесе булып өлгерә. Ул – татар гуманитар фәнендә милли әдәбият тарихын диахрон һәм синхрон система буларак өйрәнеп, тулы бер күзаллау, татар әдәбиятын бербөтен процесс буларак өйрәнүдә үз концепциясен булдырган.

Д. Заһидуллинаның фәнни эзләнүләре берничә юнәлешне колачлый: урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы, ФДББС шартларында әдәбият укыту методикасын камилләштерү, шушы юлда белем бирү оешмалары өчен яңа уку программалары әзерләү; татар укучысына әдәби-нәзари мирасны кайтару, әдәбият теориясенең тарихын өйрәнү; теоретик эзләнүләрне камилләштерү, дөнья әдәбият белемендәге фәнни-теоретик мәктәпләрнең казанышларын милли нәзари фикергә яраклаштырып куллану юлларын тәкъдим итү; XX гасыр әдәбиятында барган модернистик мирасны өйрәнү, ике гасыр чигендәге «яңа» әдәбиятның үзара «диалогын» билгеләү;

XX гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәрешен өйрәнү концепциясен яңарту; әдәби тәнкыйть [Юсупова, 2019, б. 146]. Бер-берсенә бәйле, әмма һәркайсы мөстәкыйль үсешкә ия бу тармакларның бер галим эшчәнлегендә үрелеп китә алуы үзе үк аның глобаль, киң фәнни масштабта фикерләү сәләтенә ия булуын ассызыклый.

*Д. Заһидуллина – методист-галим.* Методик мәсьәләләр галимә фәнгә аяк басканнан алып бүгенгә кадәр даими өйрәнеп, үстереп килгән өлкә булып кала. Фәнни эшчәнлек белән янәшәдә университетта студентларга «Татар әдәбиятын укыту методикасы» курсыннан лекцияләр уку барышында ул методик белемнәрен камилләштереп, системага салып бара, рус педагогикасында барлыкка килгән яңа технологияләрне барлап, өйрәнеп, аларның уңышлы, отышлы саналганнарын милли әдәбиятны укыту өлкәсендә максатчан куллану юлларын эзли. Шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак «Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту» (2000, 2004) [Заһидуллина, 2000] дәреслеге дөнья күрә. Әлеге хезмәтендә ул татар әдәбиятын укыту методикасының тарихын барлый, бу тармакка үз өлешен керткән, методик мәсьәләләр белән шөгыльләнеп, эз калдырган методист-галимнәрнең эшчәнлеген күздән кичерә, яңалыгын билгели. Шуның белән янәшәдә әдәбият предметын укыту барышында кулланырга мөмкин булган яңа технологияләр, әдәбиятны тикшерү юллары һәм ысуллары хакында мәгълүматлар бирә, аларны куллану мөмкинлекләрен әдәби төрләр, жанрларга мөнәсәбәтле конкрет әсәрләргә анализлар мисалында нығыта. Хезмәтнең теоретик һәм гамәли кыйммәте дә шунда. Галимә сүз сәнгатен предмет буларак укытуны тагын да камилләштерү, фәндә барлыкка килгән яңалыкларны даими рәвештә мәктәпкә кертү йөзеннән вакытлы матбугат битләрендә мәкаләләр бастыра килә, укытучылар алдында чыгышлар ясый, туксанынчы елларда әле башланып кына киткән татар әдәбиятыннан республика олимпиадаларын оештыруда башлап йөри.

Алга таба Д. Заһидуллина методик эшчәнлеген мәктәпләр, урта һәм югары уку йортлары өчен дәреслек, методик кулланмалар әзерләүче буларак дәвам итә. Яңа гасыр башында тиз үзгәрешле заман таләпләре татар әдәбияты дәреслекләрен, аларның эчтәлеген үзгәртүне көн тәртибенә куя. Галимә бу таләпне тоеп ала, шул ук вакытта гамәлдәге программаларны, дәреслекләрне яңартуның дәвамлы һәм шактый катлаулы, четерекле эш икәнлеген дә аңлап, кулланмалар әзерләү эшенә керешә. Аның җитәкчелегендә эшләнеп, укучыларның татар әдәбиятыннан белемнәрен системага салуга һәм тулыландыруга йөз тоткан «Татар әдәбияты. Теория. Тарих» (2004, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйләҗев), «Татар әдәбияты. Теория. Тарих. Тулыландырылган икенче басма» (2006, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйләҗев, Н. Йосыпова) [Татар әдәбияты..., 2006], «Әдәби әсәргә анализ ясау» (2005, Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов) [Заһидуллина, 2005], «Татар әдәбияты: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» (2007, Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов, Н. Йосы-

пова, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйләҗев, Г. Гайнуллина) [Әдәбият белеме..., 2007] кебек хезмәтләр шул таләпләрне күз уңында тотып эшләнә.

Бүген инде анык әйтергә мөмкин: нәкъ шушы хезмәтләрдә Д. Заһидуллинаның үзгә карашка нигезләнгән уку-укыту программаларына җирлек салына, концептуаль яңалыклар гамәлгә куела башлый. Аларда, укучыларның кызыксынуын, фән үсешен исәпкә алып, яңа терминнар турында мәгълүматлар бирелә, фәннилеге искергән, көн таләпләренә җавап бирми башлаган терминнар яңа атамалары белән алыштырыла башлый, әдәби үсеш хакындагы гыйльми күзаллаулар киңәйтелә. «Татар әдәбияты. Теория. Тарих» (2004, 2006), «Татар әдәбиятыннан таблицалар» (2009, Д. Заһидуллина, Н. Юсупова, Ә. Закирҗанов, И. Кадыйрова) кебек кулланмалары рус методика фәнендә киң таралган, әмма бездә әле ул вакытта гамәлгә куелмаган, әдәби-теоретик мәгълүматны таблицалар һәм схемалар ярдәмендә җиткерү алымын татар әдәбияты мисалында кулланып карый. Татар әдәбиятыннан гамәлдәге мәктәп программаларын һәм дәреслекләрен өстәмә баеткан, укучыларга әдәби әсәрне, әдип иҗатын өйрәтү юлларын һәм мөмкинлекләрен тәкъдим иткән әлеге кулланмалар шунда ук республика укытучылары арасында популярлашып китә, чын мәгънәсендә аларның өстәл китабына әверелә.

Белем бирү системасындагы үзгәрешләр, яңа технологияләр системасы барлыкка килү татар әдәбиятын укыту методикасын да федераль дәүләт белем бирү стандартлары (ФДББС) нигезендә камилләштерүне таләп итә, 2008 елдан Д. Заһидуллинаның методик эшчәнлеге ФДББС шартларында татар әдәбиятын укыту программалары эшләүгә йөз тота һәм 2023 елга кадәр татар мәктәпләрендә татар әдәбияты аның җитәкчелегендә төзелгән программалар нигезендә укытыла. Бу программаларның концептуаль яңалыгы һәм практик әһәмияте нидә иде соң? Аның тарафыннан әзерләнгән әдәбият укыту программалары («Татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа» (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, 2011); «Татар телендә белем бирүче мәгариф оешмалары өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа» (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, Ф.Ф. Хәсәнова, 2014) балаларны үз милләтенең вәкиле итеп тәрбияләү, аларда милли үзаң, дөньяга караш формалаштыру, үстерү бурычын куя, әдәбият укыту әсәрне укып чыгуга гына түгел, яшь буынга матди һәм рухи мәдәниятнең, татар менталитетының үзенчәлекләрен күрсәтүгә, үзбилгеләнүгә йөз тотарга тиеш, дигән фикер тирәсенә җыела. Гуманитар белем бирү системасында татар әдәбиятын шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгеләүче төп предметларның берсе итеп күтәрә. Икенчедән, шушы юлда укучыларны әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты белән таныштыруга, аларны тикшерү-анализлау юлларын үзләштерүгә; зур сүз осталары иҗатының яңалыгын дөрес аңларга, объектив нәтиҗәләр ясарга, мөнәсәбәт формалаштырырга өйрәтүгә, балаларның психик һәм фи-

зик сәламәтлеген саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелә. Өченче яктан, заман укучысын әдәбиятка тарту, аның аңларга-анализларга өйрәнү юлында, классика белән янәшәдә, хәзерге татар әдәбиятына игътибарны арттыра.

2017 елда Д. Заһидуллина җитәкчелегендә заман таләпләренә туры китерелеп, татар телен һәм әдәбиятын укыту концепциясе эшләнә һәм ул татар методик фикеренә яңача караш алып килә: татар әдәбиятын туган телдәге әдәбият һәм чит телдәге әдәбият булараk укыту юллары аерып билгеләнеп, аның методик принциплары, укыту алымнары, юллары барлана, әдәби белем бирү системасы дүрт дәрәҗәгә бүлеп тәкъдим ителә.

*Д.Заһидуллина – теоретик галим.* Галимәнең аерым эзләнүләре татар әдәбият белеме үсешенә зур йогынты ясый. 2000 еллар башында ул әдәби нәзариянең формалашу, үсү үзенчәлеген билгеләгән, аны күпсанлы нәзари хезмәтләр, фәнни-тәнкыйди мәкаләләр нигезендә раслаган, шактый әдәби, тәнкыйди ядкәрләрне фәнни әйләнешкә кайтарган әдәбиятчы булып танылa. Бу олы нәтиҗәгә алып килгән юлның башы, татар әдәбиятын мәктәпләрдә укыту методикасы мәсьәләләре белән бәйләп, 1917 елга кадәр эшләп килгән татар укыту системасы, мәктәп-мәдрәсәләрдә гамәлдә йөргән әдәбият дәреслекләре хакында мәгълүматлар туплауга барып тоташа. Нәкъ менә әлеге эзләнүләр Д. Заһидуллинаны татар әдәбият белемендә бөтенләй өйрәнелмәгән, алга таба фәнни эзләнүләренең төп магистраль юлын тәшкил итәчәк өлкәгә – әдәбият теориясеннән беренче дәреслекләр һәм татар әдәбият нәзариясенең формалашуын тикшерүгә алып килә.

Галимәнең бу юнәлештә тикшеренүләре 1990 елларның уртасыннан башлана, матбугат битләрендә, конференция җыентыкларында басылган күпсанлы мәкаләләре шул хакта сөйли. Әдәби күренеш, агымнарның асылына бары аның нигезен барлау, тарихын өйрәнү аша гына төшенеп булачагын аңлап, ул татар нәзариясенең үткәнен тикшерүгә алына. Бу тикшеренүләр аны XX йөз башына – татар әдәбиятының алтын чорына – Д. Заһидуллина фәнни эзләнүләренең үзәгендә торачак дәвергә якынайта. Шул эзләнүләрнең беренче тәҗрибәсе булып «Әдәбият кануннары һәм заман» китабы [Заһидуллина, 2000] һәм «Татар әдәбият нәзариясенең формалашу һәм үсеш этаплары (XX гасырның беренче чиреге)» дигән темага язылган докторлык диссертациясе аваз сала. Аларда әдәбият белеменең моңа кадәр киң катлау укучыга гына түгел, күп кенә филологларга да аз таныш сәхифәләренә игътибар юнәлтелеп, идеологик кысулар тәэсирендә тарих тузанына күмелгән әдәби-мәдәни багланышлар, татар әдәби-фәлсәфи фикеренең гарби һәм шәркый бәйләнешләре татар укучысына тәкъдим ителә, беренче тапкыр әдәбият теориясе барлыкка килү һәм үсү юлы эзлекле өйрәнелә. Фәнни тикшерүләр Урта гасырлардан башлап, XX гасыр башы аша, гаять катлаулы, четерекле саналган, бер үк вакытта әдәбият белеменә шактый гына үзгәрешләр дә китергән 1920–1930 елларга кадәр җиткерелә.

Әлеге тикшеренү нәтиҗәләре XX гасыр башында формалашкан әдәби-нәзари концепцияләрне, фәнни-тәнкыйди мәктәпләрне ачыкларга мөмкинлек бирә. Үз чиратында алар татарларда әдәбият теориясе, мөстәкыйль фән тармагы буларак, соңрак – совет чорында гына формалашкан, дип калыплашкан карашны үзгәртүгә алып килә. Галимә XX гасыр башында ук татарларның үз, рус, Европа әдәбият белеменнән аермалы, иҗади фикерләү юлы, мөстәкыйль нәзари фикере формалашу, бу процессның инде XIX гасырда ук башлануы хакында әйтеп чыга: Урта гасырлардан башлап, XIX гасырның ахырларына кадәрге вакыт милли нәзария тууга әзерлек чоры буларак аерып куела. XX гасыр башындагы әдәби-нәзари агымнар, аларның оешу тарихы, төп кануннары, милли асылы, йөз тоткан, таянган юнәлешләре ныклап өйрәнелә, җәмгыятьчеләр, рухиятчеләр мәктәпләренең һәм милли сүз сәнгатендәге яңа әдәби концепцияләрнең туу алшартлары барлана, аларның үзгәреш-яңарышы ачыклана. Әлеге эзләнүләр галимәгә шул чорда милли аң үсешенең дә югары биеклеккә ирешүен исбатлау мөмкинлеген бирә. Шуның белән янәшәдә аның тарафыннан Г. Сәгъди, Г. Баттал, Г. Ибраһимов, Н. Хәлфин һ. б. ның әдәбият теориясенә кагылышлы моңа кадәр аз таныш хезмәтләре фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелә, алар Европа, рус әдәбиятчыларының карашлары, тәгълиматлары белән бәйләнештә тикшерелә, бу исә татарларда нәзария фәненең мөстәкыйль тармак буларак формалашуын ныклы исбатларга, дәлилләргә юл ача. Әйтерсең, бу тема нәкъ менә Д. Заһидуллина кебек фәнгә мөкиббән, XX гасыр башы татар әдәбиятын, әдипләрен ихлас яраткан, шул чор фикер ияләренә сокланган, яхшы мәгънәсендә табынган галим-эзләнүчесен көткән.

Диссертациясен яклаганнан соң да Д. Заһидуллина нәзарият тарихы белән кызыксынуын дәвам итә. Шушы юлдагы эзләнүләре аңа тагын бер өлкәгә – әдәбият белемендәге фәнни-тикшеренү мәктәпләрен өйрәнүгә юл күрсәтә. Галимәнең фәнни-концептуаль эзләнүләре бу өлкәне дә колачлап ала һәм татар әдәбият фәнендә алып барылган тикшеренүләрне баетып, яңа югарылыкка күтәреп җибәрә. «Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз» (2007, Д. Заһидуллина, В. Әминева, М. Ибраһимов) [Заһидуллина, 2007] хезмәтендә XX гасыр әдәбият белемендә барлыкка килгән төрле тәгълиматлар хакында теоретик мәгълүматлар бирелә, әдәби текстлар белән эшләгәндә аларны файдалану мөмкинлекләре барлана. Татар әдәбият белеме өчен яңа кулланма, яңа фикер була бу. «История науки о литературе у татар» [Загидуллина, 2011] хезмәтендә татар әдәбият белемендә формалашкан нәзари мәктәпләр аерып өйрәнелә, дөнья әдәбият белемендәге әлеге мәктәпләрнең милли үзләштерелү үзенчәлекләре билгеләнә. Болар исә галимәгә соңрак үз фәнни тәгълиматын нигезләүгә ныклы күпер хезмәтен үти.

*Д.Заһидуллина – татар әдәбияты тарихын комплекслы өйрәнгән галим-тикшеренүче.* Татар нәзари фикере тарихын тирәнтен өйрәнү, XX гасыр башы татар әдәбияты белән кызыксынып китү галимәгә

киләчәк фәнни эзләнүләр өчен тагын бер өлкәне ачып җибәрә. Ул – моңа кадәр игътибардан читтә калган, идеологик максатлардан чыгып, махсус өйрәнелмәгән яки тискәре яктан гына бәяләнеп килгән, әмма искиткеч кызыклы һәм мавыктыргыч модернистик эзләнүләр. Нәтиҗәдә, Д. Заһидуллина, әлегәчә үзенең тикшерүчесен көтеп яткан әдәби катламнарны актарып, «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» [Заһидуллина, 2003] хезмәтен татар укучысына тәкъдим итә. Онытылган авторларны кайтару, аларның иҗатына лаеклы бәя бирү омтылышы ясалган монография шартлы рәвештә ике өлешне – модернизм, аның агымнары, алымнары, милли матбугатта яңалыкка караш-мөнәсәбәт турындагы теоретик материалны һәм шуны гамәли нигезләгән модернистик, аерым алганда, символистик, экзистенциаль, импрессионистик, экспрессионистик проза үрнәкләренә анализны үз эченә ала.

Хезмәт «татар модернизмы» төшенчәсен нигезләве, аны теоретик нигезгә салуы, модернизмның рус һәм Европа әдәбиятыннан үзгә, милли төсмерләрен, аның татар әдәбиятында формалашкан төп агымнарын, аларның поэтик алымнарын, принципларын аерып чыгаруы, модернистик әсәрләрне өйрәнүнең милли концепциясен булдыруы белән әһәмиятле, актуаль. Галимә модернизмның милли сәнгатькә килеп керү юлларын аерып куя һәм мәдәни үсешнең татар милләте формалашу, татарларда иҗтимагый, фәлсәфи, сәяси күтәрелеш белән бәйле төстә баруын билгели. Әлеге тикшеренүләр моңа кадәр декадентлык исеме астында тискәре бәяләнеп килгән яңа күренешкә бөтенләй башка яссылыктан якын килү мөмкинлеге бирә, шушы юнәлештә яшәп килгән фикерләрне кире кагып, модернизмның татарлар өчен ят булмавын, хәтта гасыр башында әдипләр тарафыннан үз итеп, яратып кабул ителүен дәлилләргә юл ача.

Әмма бу эзләнүләрнең тагын бер әһәмиятле ягы була: модерн әдәбиятының фәлсәфи-эстетик нигезләрен билгеләгән әдәби материал татар матбугатында дөнья күргән тәнкыйди, публицистик, фәлсәфи, нәзари, агиографик язмалар, татар әдипләре, галим-фәлсәфәчеләренең фикерләре белән дәлилләп барыла. Биредә татар укучысы өчен билгесез саналган М. Хәнәфи, Ә. Тангатаров кебек авторлар мирасы, аерым алганда, М. Хәнәфинең «Айсылу», «Милләтем», Н. Гасрыйның «Гыйшкымның хәрабәләре», Ф. Әмирханның «Фәрештәләр җуатсыннар сине», «Ай өстендә Зөһрә кыз», Г. Рәхимнең «Эч пошканда», «Хан мәчетендә», «Көзге хикәя», З. Нуркинның «Бәхет», Б. Мансурның «Татар егете», М. Гафуриның «Хан кызы Алтынчәч», Ә. Тангатаровның «Ташландык кабер» кебек өйрәнүдән читтә калган әдәби әсәрләре халыкка кайтарыла, татар әдәбиятының тарих тузанына күмелеп, күренми яткан әдәби мирасы, байлыгы яктыртыла, М. Хәнәфи, Ә. Хәсәни, Самат, Г. Газиз кебек тәнкыйтьчеләрнең моңа кадәр махсус өйрәнелмәгән мәкаләләре әдәби-гыйльми әйләнешкә кертеп җибәрелә (гомумән, М. Хәнәфи, Ә. Тангатаров, Ә. Хәсәни исемен Д. Заһидуллина кире кайтарды дисәк тә, һич тә арттыру бул-

мас), аларның мирасына лаеклы бәя бирелә. Модернистик хикәяләр, шәрехләү методикасына таянып, берничә катламның әдәби синтезы буларак өйрәнелә, мондый тикшеренүләр өр-яңа фикерләрне яңгырату мөмкинлеген бирә. Мисал өчен, Ф. Әмирханның шактый галимнәр тарафыннан бәяләнгән «Татар кызы» хикәясенә бәяне генә алыйк.

Галимә тәкъдим иткән шәрехләүдә, үткән һәм хәзерге вакытны тоташтырып, «төш» ролен үтәүче татар кызы образы символ буларак тәкъдим ителеп, аның мәгънәләре аерып чыгарыла, ачкыч-сүзләр аша үткәрелгән идея, фәлсәфә, үкенеч һәм ирония пафосы ачыклана, кабатлау, эчке рифма, аллитерация, анафора кебек поэтик чараларның хисне җиткерүдәге роле күрсәтелә. «Әсәр үзе акыл иҗаты кебек кабул ителә. Аны укыганнан соң, сәнгатьтәге иң олы матурлык – кеше фикеренең, уеның, хыялының матурлыгы, диясе килә. Автор төзеп куйган шартлы модель-риваять гомумән Яшәешкә дә, милли чынбарлыкка да бәя булып яңгырый. Әсәрдәге хикәяләүче-автор исә – шушы катламнарга югарыдан торып күз ташлый алган акыллы кеше. Ул Яшәешнең (гомуми, милли, индивидуаль) ике юлын барлый: Азатлыкны буу – җимерелү, бетү, ә инде Ирек бирү – яңадан яши башлау» кебек нәтиҗә чыгарыла. Әнә шулай Д. Заһидуллина әсәрне Шәрык һәм Гареб традицияләре фонында анализлап, татар кызы образының татар милләтен символлаштыруы һәм әсәрнең умыртка баганасы, әдәбияттагы тормыш моделенең төше булып, милли Яшәешкә бәя бирү, фәлсәфи фикер белдерү чыганагына әйләнүе турындагы фикерен яңгырата.

Яисә икенче яңалыкка мөрәҗәгать итик. Әдәбиятта экзистенциализм фәлсәфәсен өйрәнү барышында, аның милли асылын анализлап, галимә татар әдәбият белемендә беренче тапкыр сызлану төшенчәсен тәкъдим итә. Моннан соң «сызлану фәлсәфәсе» төшенчәсе әдәбият белемендә киң таралыш алып, фәнни кулланылышка кереп китә, калыплаша. М. Гафуриның «Болгар кызы Айсылу», Н. Гасрыйның «Гыйшкымның хәрабәләре», Ф. Әмирханның «Фәрештәләр җуатсыннар сине», Г. Рәхимнең «Эч пошканда», М. Хәнәфинең «Милләтем» кебек әсәрләренә, эссенция халәтеннән экзистенция баскычына күтәрелгән геройның яшәешенә, күңел дөньясына күзәтү-бәя галимәне экзистенциаль әсәрләрдә хикәяләүченең дә, хис-кичереш, аны җиткерүче поэтик чара, алымнарның, кулланылган символларның да үзгә булуы, сызлану фәлсәфәсенең татар әдәбиятындагы образлар галереясын зыялы, фикерле, дөнья гаменә кайгыручы, ләкин көрәшче булмаган һәм була да алмаячак шәхес белән баетуы турындагы фикергә алып килә.

Бу күренеш үзе үк авторның алга таба камилләштереп барачак тагын бер фәнни эзләнүләр өлкәсен билгели: ул моңа кадәр гамәлдә булган анализ калыбының актуальлеге кимүне, үзгә фәнни-тәнкыйди тикшеренү методикасын булдыру зарурлыгын көн тәртибенә куя. Бу омтылышның әдәбиятны яңача өйрәнү кирәклеге ачыкланган, әмма фәнни җәмәгатьчелекнең төгәл нәтиҗәләргә килә алмаган чорда ясалуы аның әһәмиятен, гыйльми кыйммәтен тагын да арттыра.

Модернистик әдәбият белән кызыксыну Д. Заһидуллинаны фәлсәфи әсәрләр дөньясына алып керә. «Дөнья сурәте үзгәрү» хезмәте [Заһидуллина, 2006] шул эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак дөнья күрә. Ул – татар сүз сәнгатендә дөнья сурәтенең үзенчәлеген, аның трансформациясен тикшерү үзәгенә куйган беренче хезмәтләрдән. Әлеге монографиясендә галимә Тарту-Мәскәү семиотика мәктәбе, аерым алганда Ю.М. Лотман тәкъдим иткән әдәби әсәргә структуральсемиотик анализ ясау юлларын татар материалында чарлый, шушы тәгълиматка таянып, XX гасыр башы татар әдәбиятының үзәгендә торган дөнья сурәтенең мәгърифәтчел, трансцендентал, гыйсъяный һ. б. төрләрен аерып чыгара, Көнчыгыш һәм Европа фәлсәфи концепцияләренең татар әдипләре тарафыннан кулланылу үзенчәлеген билгели. Шуның нәтиҗәсендә ул XX гасыр башы фәлсәфи әсәрләренә хас һәм теләсә кайсы фәлсәфи әсәрне бәяләүдә нигез хезмәтен үти алырлык берничә нәзари сыйфатны, тенденцияне аерып чыгара: автор позициясе әсәр структурасында урын алган дөнья сурәте аша төгәлләшә; дөнья сурәте әдәби әсәр төзелешенең нигезендә яткан бинар оппозицияләр нигезендә ачыла; шул юлда символлар үзәкне тәшкил итә; фәлсәфи әсәр күпкатламлы булу сәләтенә ия; татар фәлсәфи әдәбияты, Көнчыгыш һәм Көнбатыш фәлсәфи концепцияләрен бербөтенгә туплап, милли җирлеккә яраклаштырып трансформацияли – аның, һичшиксез, үз милли йөзе бар. Д. Заһидуллина соңгы еллар гуманитар фәнендә игътибар үзәгенә менгән суфичылыкның татар мәдәниятенә фикри йогынты ясаган күренеш кенә түгел, әдәби дөнья сурәтен билгеләгән, аны үзгәртү көченә ия булган төп агымнардан булуын исбатлый. Шәрык һәм Гареб әдәбиятыннан, нәзариясеннән тирән белемен файдаланып, нәзари фикерләрен шушы чорның күренекле авторлары Г. Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Н. Думави, Ш. Бабич, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Ш. Камал, М. Хәнәфи, Ә. Тангатаров, М. Гафури кебек тулы бер плеяда әдипләрнең иҗатлары, аларның игътибардан читтәрәк кала килгән әсәрләре мисалында гамәли төгәлләштерә, шул рәвешле, XX гасыр башы милли сүз сәнгате хакында комплекслы күзаллау булдыра.

«Модернизм в татарской литературе первой трети XX века» хезмәтендә [Загидуллина, 2013] Д. Заһидуллина XX гасыр башы әдәбият мәйданында алып барылган эзләнүләрнең 1920 елларга кадәр үстерелеп, баетылып килүен исбатлый. Нәзари, фәлсәфи характердагы материал аша галимә татар әдәбиятын дөнья әдәбиятларына тоташтыра: Й. Нигъмәтуллина хезмәтләрендә гамәлгә куела башлаган классик булмаган мәдәният төре хакындагы күзаллауны фәнни исбатлый, аның татар җирлегендә формалашу алшартларын барлый, үзгәреш-яңарышын ачыклый, төп кануннарын, асылын, иҗат принципларын ныклап өйрәнә һәм милли сүз сәнгатен Шопенгауэр, Ницше, Вл. Соловьевларның фәлсәфи фикерләре белән бәйли.

Әлеге нәтиҗәләргә китергән, модерн әдәбиятның фәлсәфиэстетик нигезләрен билгеләгән әдәби һәм нәзари материалның искит-

кеч бай һәм тирән булуы аерым билгеләнеп үтүгә лаек. Татар матбугатында дөнья күргән тәнкыйди, публицистик, фәлсәфи, нәзари язмалар, татар әдипләре, галим-фәлсәфәчеләренең фикерләре мәдәни традицияләрне нигезле, фактик, төгәл аңлатырга мөмкинлек бирә. Алай гына да түгел, бу хезмәт 1920 еллар татар әдәбиятында алып барылган имажинистик, футуристик эзләнүләрнең гомумәдәби процесста тоткан урынын, аларның төп үзенчәлекләрен, иҗат принципларын билгеләве белән дә әһәмиятле. Шушы юнәлештәге төп әдәби әсәрләргә анализ аша Д. Заһидуллина татар әдипләренең бай иҗат дөньясын, һәр яңалыкны бизмәннәрдә үлчәп кабул итәрлек тирән эрудициясен укучыга ирештерә. Үз чиратында татар әдәбиятындагы модернистик эзләнүләр Европа, рус әдәбияты казанышлары белән бер үремтәдә тикшерелә, мондый масштаблылык галимәгә татар сүз сәнгатен дөнья әдәбияты фонында карау, шул ук вакытта милли әдәбияттагы модернизмның асыл сыйфатларын, үзгә хасиятләрен төгәлләштерү мөмкинлеген бирә. Шуның нәтиҗәсендә Д. Заһидуллина 2003 елда тәкъдим иткән татар әдәбиятында модернизмның үзгә форма һәм алымнары формалашу хакындагы фикерен тирәнәйтә, татар әдәбиятында модернизмның «соңарган» түгел, ә үзгә варианты яшәвен дәлилли. Шул чорда әдәби фикер белән янәшәдә милли аң үсешенең дә югары биеклеккә ирешүен, модернистик эзләнүләрнең махсус тикшерү объекты була алуын тагын бер кат исбатлый.

Галимәнең алга таба дәвам итәчәк эзләнүләрендә дә модернизм күренеше, яңа алымнар игътибар үзәгендә кала. 2015 елда басылып чыккан «1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр» хезмәтендә [Заһидуллина, 2015] Д. Заһидуллина татар әдәбиятында модернистик алымнарның югалмавын, ә, бәлки, XX гасырның икенче яртысында актуальләшеп китүен раслый. Бу чор әдәбиятындагы күтәрелешнең авангард эзләнүләргә бәйле булуы, авангард күренешләрнең дөнья әдәбиятындагы охшаш тенденцияләр тәэсирендә, примар системаның бер өлеше төсендә формалашуы, әмма аның үзгә традицияләргә, милли үзенчәлекләргә нигезләнеп үсүе хакындагы фикере әдәбият гыйлемендә яшәп килгән стандарт фикер офыкларын киңәйтеп җибәрә. Милли традицияләргә таянып үсү галимә тарафыннан татар сүз сәнгате өчен чикләү түгел, киресенчә, традицион нигездә яңалыкларны үзләштерүнең, милли җирлектә, нинди үзгәрешләр кичереп, иҗади яраклашуын күзәтүнең бер принцибы буларак тәкъдим ителә. Бу фикер татар әдәбият белеме өчен яңа сүз булып яңгырый.

Д. Заһидуллина тәкъдим иткән концептуаль анализлар С. Хәким, Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Ә. Еники, Г. Бәширов, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев һ. б. ныкы кебек күп тапкырлар тикшерелгән, шәрехләнгән иҗатларны, әсәрләрне бөтенләй көтелмәгән яктан ачып җибәрә, татар әдипләренең эстетик зәвыгына, әдәби осталыгына һәм талантына соклану уята. Икенче яктан, бу хезмәт 1960–1980 еллар татар әдәбиятының һич кенә дә торгынлык чоры сүз сәнгате түгел, ә милли

традицияләргә нигезләнгән күтәрелеш чоры, үсүнең өр-яңа сукмакларын салган, XX гасыр башында актив булган модерн алымнарны актуальләштергән, яңа кеше концепциясен формалаштырган дәвере булуын нигезли, совет чорында да әдәби барышны үзгәртерлек, милли нигездән үстереп китәрлек яңа сукмаклар табылуы турында хәбәр итә. Күпсанлы әсәрләргә анализлар әдәбият белемендәге «милли яңарыш 1990 елларда башлана» дип калыплашкан карашны үзгәртә һәм өр-яңа фикер белдерергә юл ача: милли нигезләргә әйләнеп кайту процессын татар әдәбияты XX гасыр уртасында ук башлый!

Галимәнең 2020 елда дөнья күргән «Татарская литература XX – нач. XXI в.: “мягкость” модернизма-авангарда-постмодернизма (к постановке проблемы)» дип аталган китабы да [Загидуллина, 2020] шушы сукмакны дәвам итеп мәйданга чыга. Модернизм – авангард – постмодернизм мөнәсәбәтләрен тикшерүгә багышланган әлеге монография XX гасыр – XXI гасыр башы татар әдәбиятын классик һәм классик булмаган (постклассик) парадигмалар яссылыгында бәяләп чыга, милли әдәби процесс кысаларында «модернизм», «авангард», «постмодернизм», «постколониаль әдәбият» төшенчәләрен аңлата, төгәлләштерә, аларның үзенчәлекләрен, үзләштерелү хасиятләрен билгели. Д. Заһидуллина татар әдәбиятында, гомумән, мәдәниятендә яңа парадигмалар формалашу процессын өйрәнеп, моңа кадәр әйтелгән нәзари фикерләрен баетып, әлеге күренешләргә бәйле әдәби барыштагы төп этапларны аерып куя: XX гасырның беренче утызъеллыгында модернизм үсеше, 1960–1980 еллар әдәбиятында авангард эзләнүләрнең активлашуы, XX–XXI гасырлар чигендә модернизмның яңарышы, XXI гасыр башында постмодернистик эзләнүләрнең актуальләшүе. Шул рәвешле, әдәби барыш эзлекле төстә күз алдына бастырыла. Татар әдәбият белемендә «милли әдәбиятта традиционлык көчле булган, яңа күренешләр локаль төстә генә алып барылган» кебек киң таралган фикерне төгәлләштереп, милли сүз сәнгатендә модерн эзләнүләрнең даими, эзлекле, системалы алып барылуын, алай гына да түгел, яңа парадигмаларның традицияләрдән аерым төстә түгел, алар белән тыгыз бәйләнештә мәйданга чыгуын, яңа һәм традицион күренешләрнең катламнар рәвешендә үсеп-үзгәреп баруын, әдәби процессның шул рәвешле эволюция кичерүен мисаллар нигезендә дәлилле раслый. Аның фикеренчә, нәкъ шушы рәвешле үсеш юлы татар әдәбиятында төрле парадигмаларның, еш кына үзара «каршы булган» күренешләрнең бер мәйданда бер-берсен этеп чыгарып түгел, ә үзара «аралашып» яшәвен тәэмин итә.

2022 елда басылган «Художественные приемы и стилевые обновления в татарской литературе (в контексте тюркских литератур XX–XXI вв.)» монографиясе [Загидуллина, 2022] татар әдәбиятындагы яңарышны төрки әдәбиятлар фонында бәяләве белән әдәбият белемендә яңа сүз буларак кабул ителә. Әлеге китапта XX гасыр – XXI гасыр башы татар әдәбияты, аң агышы, эзоп теле, полифония, жанр хәтере, канунлашу һәм канунны җимерү, орнаментальлек һ. б.

сәнгати алым һәм стиль тенденцияләренә бәйләп, башка төрки әдәбиятлар контекстында тикшерелә. Әлеге төшенчәләрнең үзләштерелү хасиятләреннән чыгып, милли әдәбиятның башка төрки әдәбиятлар фонында үз үсеш юлы, үз йөзе булган сүз сәнгате булуы тагын бер кат дәлилләнә.

Галимә милли сүз сәнгате үсешенә хас берничә механизмны аерып чыгара: үсешнең яңа юлларын, мөмкинлекләрен эзләп, татар әдәбияты даими төстә үзенең сәнгати традицияләренә мөрәҗәгать итә, «нигезенә әйләнеп кайта», аларны үз чоры сәнгати югарылыгына яраклаштырып тергезә; яңарыш чорында һәрвакыт кешелек, җәмгыять, ил тарихы, яшәеш хакыйкатен эзләүче көчле кеше концепциясен алгы планга чыгара, шул ук вакытта дөнья әдәби процессы белән элемтәсен югалтмый; тарихи-мәдәни катаклизмнарга, идеологик тыюларга карамастан, татар әдәбияты татар халкы алдындагы миссиясенең мөһимлеген һәрвакыт тоеп эш итә. Шул яссылыкта XX гасыр – XXI гасыр башы татар әдәбияты кешелеклелек, милли рухи кыйммәтләр һәм мәдәниятләрне саклау хакында укучы белән сөйләшү мәйданына әверелә. Галимә тарафыннан XX–XXI гасырлар сүз сәнгатенә бәйле тәкъдим ителгән бу фикерләр, гомумән, татар әдәбиятының үсеш закончалыгы буларак та билгеләнә ала, аның төп үсеш хасиятен ачып бирә.

*Д. Заһидуллина – текстолог.* Татар әдәбиятының яңа катламнарын татар укучысына кайтару юнәлешендә Д. Заһидуллина әдәбият галиме генә түгел, текстолог буларак та актив эшчәнлек алып бара. Фәнни эзләнүләре барышында Г. Рәхимнең (Гали Рәхим. Сайланма әсәрләр, 2004), Г. Сәгъдинең (Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык, 2008), Ә. Тангатаровның, Хәнәфинең, Ә. Хәсәнинең һ. б. тарих тузанына күмелгән әдәби-тәнкыйди, гыйльми мирасын бүгенге укучыга кайтаруга үзеннән зур өлеш кертә. Шушы юлда күпсанлы мәкаләләр бастыра, конференцияләрдә чыгышлар ясый, студент, аспирантларга диплом эшләре һәм диссертацияләр яздыра. Бу хезмәтләр 1930 елларда мәгълүм сәбәпләр нәтиҗәсендә өзелеп калган әдәби, гыйльми фикерләрне бүгенге карашлар белән ялгап җибәрә, урынсыз онытылган бу шәхесләрнең тормыш һәм иҗат биографиясен, мирасын алга таба тирәнтен итеп өйрәнүгә юл күрсәтә, тәүге сукмакларны сала.

*Д. Заһидуллина – милли әдәбиятны система буларак өйрәнү концепциясен тәкъдим итүче.* Нәзари фикер үсешен, XX гасыр башы әдәбияты тарихын өйрәнеп, Д. Заһидуллина әдәбият белеме фәнендә XX йөз әдәби процессын тикшерерлек, аның олы тарихи һәм мәдәни потенциалын күңелдән уздырып, һәр күренешнең үз урынын билгеләрлек, аңа объектив якын килерлек гыйльми концепция табылмавы хакында нәтиҗәгә килә һәм алга таба шушы өлкәдә ныклап эзләнә, үз концепциясен чарлый башлый. Әдәбият белемендә барган позитив үзгәрешләр дә сүз сәнгате тарихын өйрәнүнең кыйбласын яңартуны, үткәннәрне бөтенләй сызып ташламый гына, әдәби-мәдәни мирасны

тагын бер кат күз уңыннан үткәрүнең үзгә концепциясен тәкъдим итүне көн тәртибенә куя.

Д. Заһидуллинаның фәнни эшчәнлегендә бу юнәлештәге ныклы адымнар 2000 еллардан ук ясала башлый. XX–XXI гасырлар чиге «яңартылган» татар прозасын өйрәнүгә йөз тоткан «Яңа дулкында» хезмәте [Заһидуллина, 2006] шул юнәлештәге лаеклы хезмәтләрдән була. Галимәнең фәнни стиле монда да актуаль булып кала: «яңа дулкын» татар прозасы үсешендәге актуаль мәсьәләләрне көн тәртибенә куйган, аны өйрәнү юлларын тәкъдим иткән теоретик-методологик тикшеренүләр нәзари нигезләнә, системага салына һәм шул нәзари күзәтүләрне гамәли дәлилләгән әдәби әсәрләргә шәрехләмә бирелә, теоретик мәгълүматлар гамәли дәлилләнеп бара. Галимә Т. Миңнуллин, Ф. Бәйрәмова, Н. Гыйматдинова, Ф. Садриев, З. Хәким, Р. Зәйдулла һ. б. ның яңа дулкында язылган әсәрләренә анализ ясый, аларның чор әдәбияты үсешендә тоткан урынын ачыклый, шул юлда сүз сәнгатенең киләчәк перспективаларын да билгеләп бара.

Алга таба милли әдәбиятны система буларак өйрәнү модернизм үсешен тикшерү аша чарланып дәвам итә. Модернизмның XX гасыр әдәбиятында төрле төсмерләрдә үсешен, яңарышын өйрәнү аша Д. Заһидуллина әдәби барыштагы аерым үсеш-үзгәреш принципларын билгеләп бара. Галимәнең «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» (2003), «Дөнья сурәте үзгәрү» (2006), «Модернизм в татарской литературе первой трети ХХ века» (2013), «1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр (2015)», «Татарская литература XX – нач. XXI в.: “мягкость” модернизма-авангарда-постмодернизма (к постановке проблемы)» (2020), «Художественные приемы и стилевые обновления в татарской литературе (в контексте тюркских литератур XX–XXI вв.)» (2022) хезмәтләре шушы чылбырның аерым буыннары кебек кабул ителә.

XX гасыр татар әдәбиятының төрле дәверләрен аерым аспектларда тикшерү-анализлау, милли сүз сәнгатен Европа, рус һәм төрки халыкларның иҗади фикерләве, фәлсәфәсе, дөньяга карашы, тарихы һәм мәдәнияте призмасы аркылы бәяләү аша Д. Заһидуллина XX гасыр татар әдәбиятын бербөтен процесс буларак өйрәнүгә килә. Әнә шулай әдәбият белемендә милли сүз сәнгатенең әлеге катлаулы, каршылыклы чорын бәяләүдә яңа концепция тәкъдим ителә. Узган гасыр татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш тарихын өйрәнү объекты итеп алган «XX гасыр татар әдәбияты тарихы» (2011, Д. Заһидуллина, Н. Йосыпова) дәреслеге [XX гасыр әдәбияты..., 2011] шушы юнәлештәге беренче комплекслы хезмәтләрдән була. Биредә XX гасыр сүз сәнгатенең моңа кадәр аерым өйрәнелеп килгән XX гасыр башы, 1920–1930 еллар, сугыш һәм сугыштан соңгы еллар, 1960–1980 еллар, 1980–2000 еллар кебек чорлары бербөтенгә тупланып, дәвамчанлык принцибына салып тикшерелә, өйрәнелә торган чор сүз сәнгатенә яңача караш булдырыла. Галимә татар әдәбият белемендә тәүге тапкыр XX гасыр сүз сәнгатенең милли нигезләргә, милли

традицияләргә таянып үсү-үзгәрүе хакындагы тәгълиматны гамәлгә куя, татар әдәбият белеме өчен стандарт булмаган мондый караш аңа совет чорында да сүз сәнгатенең үзгә сукмаклар салып, югары үсешкә ирешүен исбатларга юл ача. Нәтиҗәдә, XX гасыр татар әдәбиятының, югалтулар һәм табышлар аша булса да, XX гасыр башында ирешелгәннәрне үстереп, баетып, «совет чоры» дип исемләнгән һәм бәяләнгән дәвердә дә милли нигезләрне саклап яшәргә омтылуы, башка әдәбиятларны кабатламыйча, үз йөзен булдырып үсүе исбатлана. Шушы тәгълимат нигезендә Д. Заһидуллина XX гасыр татар әдәбиятының тулы тарихын колачлап ала: XX гасыр башы әдәбияты XX–XXI гасырлар чиге сүз сәнгате белән тоташтырыла. XX гасыр әдәбиятын бөтенлекле система итеп өйрәнү милли традицияләрнең дәвамчанлыгын, эстетик байлыкны, поэтик тирәнлекне, иҗади юнәлешләр, агымнар, алымнар байлыгын күрергә мөмкинлек бирә.

Әдәбият тарихын букетен система итеп, синхрон һәм диахрон яссылыкларда масштаблы өйрәнү теләге эзләнүләрне Урта гасырлардан башлап, XX–XXI гасырлар чигенә кадәр киңәйтүне көн тәртибенә куя. Моңа кадәр дә күпсанлы тәнкыйть мәкаләләрендә ассызыкланып килгән фикер-карашлар «Современная татарская проза (1986–2016): основные тенденции историко-литературного процесса» [Загидуллина, 2017], «Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015 гг.): эстетические ориентиры и художественные поиски» [Загидуллина, 2017], «1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр», «Татарская поэзия и проза рубежа XX–XXI веков: эстетические ориентиры и художественные поиски» [Загидуллина, 2018], «Художественные приёмы и стилевые обновления в татарской литературе (в контексте тюркских литератур XX–XXI вв.)» (2022) хезмәтләрендә системага салынып җитә, тирәнәйтелә. Болар, бер яктан, әдәби барышны фәнни яктан системалы тикшерүгә яңа юллар сала, икенче яктан, укытучылар һәм студентлар, аспирантлар өчен әдәби процессны өйрәнү барышында әдәби-методик кулланма вазифасын башкара. Галимә тарафыннан, бер яктан, милли традицияләрнең хәзерге әдәбиятка кадәр килеп җитүе, ягъни татар әдәбиятының үз, милли йөзе булуы турындагы фикер исбатлана, икенче яктан, аның даими эзләнүләр юлында булуы, дөнья әдәбиятына йөз тотып үсүе ассызыклана. Мәсәлән, Р. Вәлиев, Р. Зәйдулла, Г. Гыйльманов, М. Кәбиров, М. Мирза, И. Иксанова, Р. Аймәт, Й. Миңнуллина, Л. Янсуар, Л. Гыйбадуллина, Б. Ибраһимов, Р. Галиуллин һ. б. ның әсәрләрен анализлап, аларда урын алган идеяләрне рус, Европа, төрки әдәбиятлар белән янәшә куеп карап, Д. Заһидуллина төп нәтиҗәгә килә: милли әдәбиятлар, асылда, дөнья әдәбияты дигән олы дөньяга алып килә торган, милли үзенчәлекләр белән бизәлгән төрле юлларны гына тәшкил итә һәм бүгенге татар әдәбияты башка халыклар әдәбиятыннан һич тә ким түгел! Шул рәвешле, бу тикшеренүләр татар сүз сәнгатен үз традицияләре формалашкан, шул ук вакытта яңалыкларны милли җирлеккә яраклаштырып кабул итә алган, башка алдынгы

әдәбиятлар белән янәшәдә тәңгәл үсеш-үзгәреш кичерә торган, нинди генә шартларда да үз имманент, эчке закончалыкларын саклап кала алган бөтенлекле система итеп раслый.

Д. Заһидуллинаның бу юнәлештәге эзләнүләре энциклопедик эшчәнлектә дә актуальлеген югалтмый. Г. Тукай энциклопедиясенең (2016) шактый материаллары аның тарафыннан языла, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнгән сигезтомлык «Татар әдәбияты тарихы» аның фәнни җитәкчелегендә эшләнә, Татар энциклопедиясендә XX гасыр әдәбиятына кагылышлы иң четерекле, катлаулы, аз өйрәнелгән мәсьәләләр турындагы язмалар да галимә тарафыннан әзерләнә. «Татар әдәбияты тарихы»ның 5, 6, 7 томнарының һәм яңартылган басмасының (2021–2023), гомумән, аның фәнни концепциясен алга куеп эшләнүен дә ассызыклау мөһим. Бу күренеш үзе үк – бүгенге әдәбият белемендә Д. Заһидуллина тәкъдим иткән тәгълиматның инде ныклап урнашуына һәм үстерелүенә ышанычлы дәлил.

*Д. Заһидуллина – тәнкыйтьче.* Әдәбият фәненең төрле аспектларында тирәнтен эзләнүләр алып барган, еш кына яңа сүз булып кабул ителгән, үзеннән соңгы эзләнүчеләргә сукмаклар салып калдырган монографияләре, кулланмалары белән янәшәдә галимә «Казан утлары», «Мәйдан», «Безнең мирас», «Фәнни Татарстан» кебек журналларда бүгенге әдәби барышны бәяләгән, дөнья күргән яңа әсәрләргә җентекле фәнни анализ ясаган, шулар нигезендә кызыклы гомумиләштерүләр ясаган язмалары белән дә чыгыш ясый. Фәнни, академик тәнкыйтькә йөз тоткан, үзе өйрәнү үзәгенә алган шагыйрь, прозаик яки драматургның әдәби барыштагы урынын, нинди иҗат юнәлеше, агымы тарафдары булуын, башка авторлар иҗатында дәвам ителергә мөмкин үзенчәлекләрен анык билгеләп барган бу язмалар әдәбият белеменең тагын бер тармагын – әдәби тәнкыйтьне үстерүгә, аның фикри офыкларын киңәйтүгә йөз тота.

Галимәнең тәнкыйди эшчәнлеге хакында сүз алып барганда тагын бер үзенчәлеккә игътибар юнәлтү мәгъкүл булыр. Академик тәнкыйть белән бергә Д. Заһидуллина тәнкыйтьнең тагын бер тармагын – XX гасыр башында зур үсеш алган, әмма бүгенге көн өчен актуальлеген киметкән оператив тәнкыйтьне тергезү омтылышын ясый. Гомумән, ул бүгенге көндә татар әдәби тәнкыйтен җанландыру юлын нәкъ менә оператив тәнкыйтьне популярлаштыруда күрә. 2017–2021 еллар аралыгында «Казан утлары» журналында ул алып барган «Җәһәт тәнкыйть: сәхифәне Д. Заһидуллина алып бара» рубрикасы шул хакта сөйли. Әдәби мәйданда әлегә үз фикерен әйтергә өлгермәгән, яңа аяк басып килүче яки яшь авторларның әсәрләре артыннан ук, аның сыйфаты нинди булуга карамастан, галимәнең күләме зур булмаган рецензиясе тәкъдим ителә. Аларда әсәргә беренчел бәя бирелә, аның сәнгатьлелек дәрәҗәсе тәгаенләнә, кимчелекләре һәм киләчәккә камилләшү мөмкинлекләре билгеләнә, нәтиҗәдә авторга

әсәрне үзгәртергә-төзәтергә киңәш биреп барыла. Д. Заһидуллинаның моннан тыш та республика газета-журналларында басылган күпсанлы язмаларында Р. Зәйдулла, Р. Аймәт, И. Иксанова, Г. Гыйльманов, Й. Миңнуллина, Л. Гыйбадуллина, Б. Ибраһимов һ. б. авторларның әле генә табадан төшеп, кулга килеп кергән җыентыкларына беренчел бәя бирелә. Китаплардан алган тәэсирләрне уртаклашып язылган мондый рецензияләрнең басманы укучыга тәкъдим итүгә, популярлаштыруга һәм татар укучысына тарату эшенә өлеш кертүен дә ассызыклау мөһим. Ул мәкаләләр дә, Д. Заһидуллина каләменнән төшкән монография-хезмәтләр кебек үк, теоретик нигезле, фәнни җәһәттән тирән, объектив, бер үк вакытта иҗади рухлы булулары белән аерылып тора һәм авторының чын мәгънәсендә олпат, үз концепциясен булдырган, әдәбият белеме фәнен яңа югарылыкка күтәргән галим булуын тагын бер кат раслый.

*Д. Заһидуллина – үз фәнни мәктәбен булдырган галим.* Фәнни эшчәнлеге дәвамында ул татар фәненең киләчәккә үсеш-үзгәреш перспективаларын билгеләп кенә калмый, алга таба шушы өлкәдә эзләнүләрне дәвам итәрлек галимнәр – үз эшенең дәвамчыларын әзерләүне дә тәэмин итә. Аның төрле төбәкләрдәге фәнни оешмаларда, югары уку йортларында эшләп килүче укучылары булу шул хакта сөйли. Д. Заһидуллина – фәнни өйрәнү өлкәсендә чын мәгънәсендә үз мәктәбен булдырган, үз тирәсенә фәнне намус эше итеп караган, эрудицияле фикердәшләрен туплаган галим. Бүгенге әдәбият белемендә барган яңа эзләнүләрдә, теге яки бу әдипнең иҗат үзенчәлеген, теләсә кайсы әдәби күренешнең үсеш-үзгәрешен өйрәнү-бәяләү барышында галимәнең хезмәтләре юл ярып бара. Галимә җитәкчелегендә язылган 9 кандидатлык, 2 докторлык, аның тәкъдимнәренә, фәнни концепциясенә, киңәшләренә таянып эшләнгән башка кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренең фәнни куәсе, гыйльми тирәнлеге, яңалыгы, шәкертләренең эрудициясе генә дә Д. Заһидуллинаның теоретик әзерлеген, башкаларны кабатламыйча, яңа сукмаклар салырга, шул юлларда үзгә нәтиҗәләр ясарга сәләтле булуын күрсәтә.

## Әдәбият

Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төз.-авт.: Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова һ. б. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. Казан: Казан ун-ты, 2011. 229 б.

XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. 2 нче китап: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. Казан: Казан ун-ты, 2011. 196 б.

*Загидуллина Д.Ф.* Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. 207 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Современная татарская проза (1986–2016): основные тенденции историко-литературного процесса. Казань: Изд-во АН РТ, 2017. 246 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия рубежа XX–XXI веков (1986–2015): эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Изд-во АН РТ, 2017. 268 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия и проза рубежа XX–XXI веков: эстетические ориентиры и художественные поиски. Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. 287 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература XX – нач. XXI в.: «мягкость» модернизма-авангарда-постмодернизма (к постановке проблемы). Казань, 2020. 256 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Художественные приемы и стилевые обновления в татарской литературе (в контексте тюркских литератур XX–XXI вв.). Казань, 2022. 252 с.

*Заһидуллина Д.Ф.* Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. Казан, 2000. 335 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман: Татар әдәбияты нәзариясе барлыкка килү һәм үсеш этаплары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 255 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәби әсәргә анализ ясау: фәнни-методик кулланма / Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. Казан: Мәгариф, 2005. 110 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 255 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2006. 191 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз / Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. Казан: Мәгариф, 2007. 112 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Мәгариф, 2006. 319 б.

*Юсупова Н.М.* Әдәбият белеменең фикер офыкларын киңәйтү юлында // Фәнни Татарстан. 2019. №3. Б. 145–154.

***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы профессоры, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге доценты*

УДК 141.336,82-1

***А.А. Хасавнех***

# ТАТАР ФӘННИ ӘДӘБИЯТЫНДА СУФИЧЫЛЫК: ХАТЫН-КЫЗ МӘСЬӘЛӘСЕ

Статья посвящена проблеме суфизма в татарской научной литературе. Автор исследует два сочинения, принадлежавшие суфийским авторам: «Табсырат ал-муршидин мин ал-маша’их ал-халидийин» («Руководство наставников от шайхов халидийской [ветви]») М.-З. Камалова и рукописный сборник на старотатарском языке «Мәрсийәә дамелла Мөхәммәд-Закир хәзрәт әл-Чистай» («Элегия на кончину дамеллы Мухаммад-Закира хазрата ал-Чистави»), составленный одним из учеников-муридов шайха (имя неизвестно). Автор указывает, что наряду с важными вопросами этики и ритуальной практики значительное внимание в сочинениях уделено проблемам женщины в мусульманском обществе и в суфизме: вступление женщин в тарикат, общение с наставником, чтение дополнительных намазов, коллективных зикров и т.д. На основе проделанной текстологической работы проанализированы важные аспекты в этике суфийских сообществ. Для проведения исследования автор применяет научно-сопоставительный и герменевтический методы. Герменевтическая трактовка арабоязычного и арабографичного сочинений способствовала расшифровке суфийских терминов и глубокому проникновению в своеобразие этико-эстетических категорий суфизма.

**Ключевые слова:** суфийская научная литература, сочинение татарского шайха М.-З. Камалова, рукопись, женщины-святые (аулийа), тарикат.

The article is devoted to the problem of Sufism in Tatar scientific literature. The author examines two works that belonged to Sufi authors: «Tabsyrat al-murshidin min al-masha’i al-khalidiyin» («The guidance of mentors from the Shaykhs of the Khalidian [branch]») M.-Z. Kamalov and a handwritten collection in the Old Tatar language «Mursiye damella Mohammad-Zakir hazrat al-Chistai» («Elegy on the death of Damella Muhammad-Zakir Hazrat al-Chistavi»), compiled by one of the Murid Shaikh students (name unknown). The author points out that along with important issues of ethics and ritual practice, considerable attention in the writings is paid to the problems of women in Muslim society and in Sufism: the entry of women into Tariqa, communication with a mentor, reading additional prayers, collective dhikr, etc. Based on the textual work done within the framework of the stated topic the author analyzes important aspects in ethics Sufi communities. To conduct the research the author uses scientific-comparative and hermeneutical methods. The hermeneutical interpretation of Arabic and Arabic-language writings contributed to the deciphering of Sufi terms and a deep insight into the uniqueness of the ethical and aesthetic categories of Sufism.

**Keywords:** Sufi scientific literature, writings of the Tatar shaykh M.Z. Kamalov, manuscript, women saints (auliya), tariqa.

Исламда һәм аерым алганда суфичылыкта хатын-кыз тематикасы, аз өйрәнелгән булуына карамастан, белгечләр арасында төрле аспектларда зур кызыксыну тудыра. Әлеге катлаулы дини-фәлсәфи

юнәлештә хатын-кызларның урынын билгеләү, ролен ачыклау, туып торган сорауларга җавап табу, хатын-кызларның үзләренең әлеге юнәлешкә тартылуларына йогынты ясау һ. б. җәһәттән суфичылык һәм хатын-кыз мәсьәләсе дини һәм фәлсәфи категорияләр, социаль һәм хокукый доктриналар эволюциясе белән тыгыз бәйләнгән. Җәмгыятьтә хатын-кызның урынын билгеләү җәһәтеннән әлеге проблема бүгенге чорларда да ныклы нигезне тәшкил итә һәм суфичылыкка бәйләнешле төрле характердагы тикшеренүләрдә чыганак ролен башкара. Шуңа күрә суфичыл җәмгыятьләрдә һәм, шул исәптән, төрле елларда фәнни әдәбиятта чагылыш тапкан мөселман хатын-кызлары мәсьәләләре темасы аеруча актуаль. Әлеге проблема бүгенге көндә чагыштырма һәм янәшә куеп махсус фәнни өйрәнү таләп итә.

Тикшеренүебезнең материалы гарәп телле һәм иске татар язуындагы чыганаклардан гыйбарәт: Мөхәммәдзакир әл-Казани әл-Чистави Камаловның (Мөхәммәдзакир Камалов әл-Чистави (Мөхәммәтзакир Габделваһап улы Габделваһапов ) (1804–1893)) «Тәбсыйрәт әл-мөршидин мин әл-мәшаих әл-халидийин) («Халидия [тармагы] шәехләре остазларыннан кулланма»сы) [Әбу Габдеррахман Мөхәммәд, б. 5–76], шулай ук шәехнең шәкертләреннән берсе тарафыннан төзелгән иске татар телендәге кульязма чыганак – «Мәрсийәэ дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт әл-Чистай» [Мәрсийәэ дамелла...]. Фәнни тикшеренүгә алынган тема кысаларында мәкаләбезнең теоретик базасын татар һәм дөнья суфи әдәбияты үсешенең тарихи этапларын һәм сәнгати үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр тәшкил итә [Аверьянов; Barkan; Bayram; Хасавнех; Мөхәммәтҗанова, Хасавнех, 2024; Шиммель]. Мәсәлән, А. Шиммель (2000) хезмәтендә суфичылык проблемасы гомумдөнья мөселман мәдәнияте контекстында карала, автор иң беренче суфи хатын-кызлардан булган Рабига әл-Гадәвийәнең эшчәнлеген яктыртуга җентекле игътибар бирә. «Хаджи Бекташ Вели и суфийское братство бекташийа» хезмәте авторы бикташи дип аталган [Аверьянов] суфичылык тарикатенең күбесенчә Госманлы империясендә яшәгән, фәнни җәмгыятьләргә аз мәгълүм булган изге хатын-кызларның (*әүлийә*) биографияләрен бөтен яклап җентекле өйрәнгән булуы белән мәшһүр. Дагстан галиме А.К. Амраховның «Единобожие и мистицизм» хезмәте Урта гасыр мөселман әдәбиятларындагы хатын-кыз образын күзәтүгә багышланган. Әлеге хезмәттә алгы планга суфичылыкның, исламның башка тармаклары белән чагыштырганда, иң башыннан ук хатын-кызларга хәерхаһлы мөнәсәбәттә булганлыгы, аларны популярлаштыруга ярдәм иткәнлеге хакындагы тезис чыгарыла. Әлеге тикшеренү гарәп телле чыганак текстларын тәрҗемә итеп ясалган фәнни анализыбызга да таяна [Мөхәммәтҗанова, Хасавнех].

Суфичылыкка мөнәсәбәттә хатын-кыз проблемасына багышланган кайбер хезмәтләр булуга карамастан, Россия Шәрык әдәбияты белемендә хатын-кыз суфилар эшчәнлеген тиешенчә өйрәнелгән дип

санап булмый. Бу җәһәттән чит ил галимнәре О.Л. Бәркән [Barkan] һәм М. Бәйрәм [Bayram] хезмәтләре игътибарга лаек. Алар бикташи тарикатенең башында торган хатын-кыз дәрвишләр эшчәнлеген өйрәнгәннәр. Шул ук вакытта авторлар борынгы Анатолия традицияләреннән үк килә торган бикташи һәм дионисий йолалары практикасы арасында параллельләр уздыралар. Әлеге хезмәтебезнең теоретик базаларыннан булган тагын бер хезмәтне күрсәтеп үтәргә кирәк: Ибн әл-Җәүзинең агиографик әсәренә [Ибн ал-Джаузи Абу ал-Фарадж] гарәп историографиясендәге мәшһүр йөз хатын-кыз әүлия *(әүлийә)* хакында биографик мәгълүмат кертелгән.

Этика һәм ритуаль гамәлләргә кагылышлы мөһим мәсьәләләр белән беррәттән «Кулланма...» да нәкышбәндия тарикатенең халидия тармагында хатын-кыз урыны һәм роленә әһәмиятле урын бирелгән. Бу ике әсәр Идел Буе һәм Кавказ суфи җәмгыятьләренең ритуаль практикасында әхлакый-этик кагыйдәләрне аңлауның ачкычы булып тора, башлангыч теоретик нокта ролен үти (тарикатька керү, остаз белән аралашу, өстәмә намазларны башкару, күмәк зикерләр һ. б.). Моннан тыш, М.-З. Камалов язган гарәп телле чыганакны текстологик эшкәртү, башка беренчел чыганакларга анализ ясау әлеге хезмәтнең нәкышбәндия тарикатенә керергә теләгән хатын-кызлар өчен кагыйдәләргә аңлатма бирү белән генә чикләнмәвен күрсәтә. Әлеге чыганакларны Идел Буе халыкларының, шул исәптән татарларның иҗтимагый-фәлсәфи фикере формалашу юлында мөһим кулланма сыйфатында карау да дөрес булыр. Татарларның этник үзаңы тарихын өйрәнгәндә М.-З. Камалов хезмәтләре гаять кыйммәтле материал ролен үти.

Күренекле дин белгече, татар җәмәгать эшлеклесе, Чистай шәһәрендә мәшһүр «Камалия» мәдрәсәсенә нигез салучы, нәкышбәндия тарикатенең суфи шәехе Мөхәммәдзакир Камалов әл-Чиставиның гарәп телле «Тәбсыйрат әл-мөршидин мин әл-мәшаих әл-халидийин»е («Халидия [тармагы] шәехләре остазларыннан кулланма»сы) Шөһайб б. Идрис әл-Багини (1857–1912) җыентыгы составына кертелгән. Кулланма Идел Буе территориясендә ислам фәне – суфичылыкны өйрәнүдә бик зур әһәмияткә ия. Бу хезмәтнең авторы Мөхәммәдзакир Камалов Казан губернасы Чистай шәһәрендә илле елга якын имам хатип булып торган, үз вакыты өчен шактый эре саналган Камалия мәдрәсәсен тоткан. Ул мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында татарның Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, Г. Гафуров-Чыгтай, Г. Исхакый кебек мәшһүр вәкилләре бар.

Мөхәммәдзакир Камаловның күзәтелә торган китабында нәкышбәндия тарикатенең халидия тармагы суфиларында этик һәм ритуаль практика мәсьәләләре карала. Хезмәтнең кульязма версиясендә язылу вакыты буларак 1321 ел һиҗри/1903 ел милади дигән дата күрсәтелгән. Кыскартылган варианты Казанда 1890 елда мәшһүр татар галиме, җәмәгать эшлеклесе һәм мәгърифәтче Галимҗан Барудиның (1857–1921) хәйрия акчасына басылып чыккан булган. Хезмәт

кереш өлештән, 23 бүлектән, йомгактан, аңлатма рәвешендә китерелгән рәсемнәрдән гыйбарәт.

Татар шәехе М. Камалов хезмәтендә нәкышбәндия тарикатенә керергә теләгән хатын-кызлар өчен кагыйдәләр җыелмасы игътибарны аеруча җәлеп итә. Бу бүлекне автор үзе дә иң әһәмиятле бүлек дип билгели. Аерым алганда, нәкышбәндия тарикатенә килүче хатын-кызлар артык яшь булмасын, дигән таләп куя автор, остаз йортына кергәндә алар тарафыннан мөселман хатын-кызлары өчен фарыз һәрбер таләпнең үтәлгән булырга тиешлегенә басым ясый. Суфи гамәлләрен алар өйләрендә башкара, шуның белән бергә хатын-кызлар ир-атлар җыелып башкара торган күмәк рухи практик гамәлләр үтәүдән тыелып торырга тиешләр *(хәтме җәмгыя-и хәлкате тәвәҗҗеһ)*. Шул ук вакытта хатын-кызларга утызар кеше бергә җыелырга рөхсәт ителә, бу сан эченә күмәк зикер әйтергә җыелган ихлас хатын-кыз күршеләр *(мөхлисун)* дә керә [Әбу Габдеррахман Мөхәммәд..., б. 26]. Анда әйтелгәнчә, хатын-кызлар тиешле гамәлләрне өйдәге эшләрен тәмам иткәннән соң башкара алалар. Шунысы кызык, тарикатькә яшь кызларны алмаганнар, шулай ук сакаллары булмаган яшь егетләр дә тарикатькә кертелмәгән. Күрсәтелгән хезмәттә мөһим бер искәртү рәвешендә шәех белән очрашкан вакытта хатын-кызның пәрдә артында яисә мәхрәмнәрдән булган туганнары арасында торырга тиешлеге ассызыклана, хатын-кызларга шәех белән бергә-бер калу рөхсәт ителми.

Хатын-кызларның яшенә мөнәсәбәттә әсәрдә шактый күп аңлатма бирелгән. «Артык яшь булырга тиеш түгел» дигән гыйбарә шуны аңлата: яшь хатын-кызларны зикер әйтергә өйрәтмәгәннәр, иң элек алар тарикатьнең барлык этик нормаларын үзләштерергә тиеш булганнар. Этика кагыйдәләрен белү генә хатын-кызларга рухи баскычның югарырак катына үтү өчен нигез була алмаган. Бу эштә Аллаһның хәерле гамәлләр кылуга уңыш һәм ярдәм *(тәуфыйк)* бирүе төп шарт саналган, ә артык яшь хатын-кызлар, шулай ук әдәпсез саналган эшләр белән шөгыльләнүчеләр, яисә бу дөньяга артык мавыкканнар *(әһлел һава)* өчен инсафлылыкка *(тәуфыйк)* юл ябык булган. Хатын-кыз тән мәхәббәтенә *(нәфес)* тартылган һәм яшь вакыты узуга шәех, хуҗа *(мәүлә)* таләпләренә әйләнеп кайткан, шул чагында гына алар дингә өйрәтүдән файда ала дип исәпләнелгән [Әбу Габдеррахман Мөхәммәд..., б. 22].

Шунысын да искәртү кирәк: хатын-кызлар өчен аеруча мөһим дип билгеләнгән кулланмада каралган мәсьәләләрдә «Тәбсыйрат әл-мөршидин мин әл-мәшаих әл-халидиийн» авторы Халид әс-Сөләймани (Халид әл-Багдади, 1779–1826) фикеренә таяна. Халид әс-Сөләймани – халидия тармагына нигез салган нәкышбәндия тарикатендә шәехләр силсиләсендә утызынчы рухи буын вәкиле. М. Камалов үзенең язмасында аны авторитет *(хөҗҗә)* буларак телгә ала, «ул үз мәзһәбендә остаз», ди [Әбу Габдеррахман Мөхәммәд..., б. 25].

Суфичылык тарихында суфилар өчен идеалның һәрвакыт ир кеше булганлыгы мәгълүм. Сәнаи язганча, Җидегән йолдызлыгы,

гарәпчә аны «Бәнат эн-нәгыш» (җеназа ләхете кызлары) диләр, үзенең исеме белән кызларның җеназа ләхетендәгеләре тереләренә караганда яхшырак дигәнгә ишарә итә [Шиммель, б. 330]. Мөселман әдәбиятыннан яхшы билгеле: бик күп әдипләр җирдәге фани тормышны карт, гарип хатын-кыз белән яисә, киресенчә, гөнаһка этәрергә сәләтле яшь, сылу кыз белән чагыштыралар, аннан мөмкин кадәр ераграк качарга чакыралар. «Бу дөнья үзенең шәлперәйгән йөзен, тешсез авызын акшар-буяу белән каплаган карт каргага охшаулы, буяу урынына ул хәтта Коръәннең тузган битләрен дә куллана, шулар артына үзенең битендәге җыерчыкларны капларга тырыша. Шул рәвешле, ул ирләрне үзенә каратмакчы була, ул сасы исле бөкшәйгән карт карга төсле, көн саен меңәрләгән ирләрне юлдан яздыра, харап итә. Үз балаларын ашаучы, Аллаһтан язган әшәке ана кебек ул» [Амрахов, б. 634]. Ф. Гаттарның «Пәнднамә»сендә шундый ук рухтагы юллар бар: «Зал-и дөнйа чун гарус-араст-әст, Һәр ду рузи шуй-и дигәр хастәст. / Ләб бә пиши шуй-и хәндан мәкөнәд, Пәс һәлякез зәхми дәндан микөнәд» [Госманов, б. 26] / «Дөньяви карчык үзен бизәгән кәләш кебек: һәр көнне үзенә яңа ир сорый. Һәркайсына ул әүвәл матур елмая, ә аннары тешләп үтерә». Тикшеренүебезнең материалларыннан берсе булган «Мәрсийәэ дамелла.. » авторы өчен дә «бу дөнья» кайгы һәм хәсрәттән генә гыйбарәт. Бик аз вакытка гына дөнья бәндәгә йөзен ачкан кебек була, ә аннары бу җирдә яшәү күңел кайтуга китерә, ирнең гомере кайгы һәм хәсрәткә тула, ди суфи-автор: *Бу дөнья даимэн пур гамьханәдер... / Бераз мөддәт идәр мәсрур, мәгъмур, / Үзе алдар кәмишә илә йу бәли, / Сәңа бу нигъмәтеме,. – дийүр, лә йузәли. / Боның бу сузенә сән улма мәсрур, / Сәне кәнденә баглаб идәр мәгърур. / Пырагыб бер вакыт аһ вә фәганләр, / Калеб казаныда кайнайа катар* [Мәрсийәэ дамелла..., б. 11].

Әлбәттә, «суфилар өчен идеал ул – ир кеше» дигән кагыйдәдән чыгарылмалар да булган. Төрле җәмгыятьләрдә хатын-кыз әүлияләр барлыкка килә башлаган. Бу җәһәттән иң ачык мисал дип бөек гашыйк хатын-кыз Рабига әл-Гадәвийәне (717–801) күрсәтү дөрес булыр. Әмма монда да шунысын искәртми булмый: Аллаһ юлы буйлап килүче хатын-кызны хатын-кыз гына дип атап булмый. «Суфиларның мәгълүм гыйбарәсендәгечә, Аллаһ юлына баскан хатын-кыз үз асылы белән физик яктан түгел, ә рухи яктан хатын-кыз булудан туктый, ул Аллаһ юлында газап чигүче дәрвишкә *(саликун)* әверелә» [Амрахов, б. 326]. Исламның мистик аспектлары үсеше чорында нәкъ менә Рабига әл-Гадәвийә иң беренчеләрдән булып илаһ телендә сөйли башлый, бу тел суфилар теле буларак мәгълүм, бу телдә Аллаһка сөйгән ярга кебек мөрәҗәгать итәләр. Изге хатын-кыз – әүлиялар турында мәгълүмат бик күп халыкларның тарихи очеркларында сакланган. Мәсәлән, ул Төркиядә VIII гасырда ук барлыкка килгән дини-фәлсәфи алевизм юнәлешендә очрый. Пир Солтан Абдала шигырьләрендә, мәсәлән, Чәчәк-ана («Чичек-ана») телгә алына яисә Чәчәк тавы дигән тауда «Кырык кыз» кабере хакында мәгълүмат бирелә һ. б.

Шунысын искәртү мөһим: ортодоксаль мөселман традицияләреннән аермалы буларак, баштагы дәверләрендә суфичылыкта хатын-кызларга һәм дини, һәм иҗтимагый-социаль өлкәләрдә үзүзләрен табарга киң мөмкинлекләр бирелгән була. Әлеге фикерне А.К. Амрахов яклый: «Суфичылыкның гүзәл затларга мөнәсәбәте амбивалентлы булып, исламдагы башка юнәлешләргә караганда суфичылык хатын-кыз активлыгына күбрәк хәерхаһлык күрсәткән дип әйтергә дә мөмкин» [Амрахов, б. 629].

Мөселманнарның бик күп буыннары Гайсә пәйгамбәрнең (г. в.) анасы Мәрьям ананы (*библ.* Мария), Мөхәммәд с. г. в. нең анасы Әминәне, хатыны Хәдичәне, пәйгамбәребез нәселен дәвам иткән кызы Фатыйманы олылаганнар, аларга карата нәзберек-дулкынланулы мөнәсәбәт саклаганнар. Бу хөрмәткә, күрәсең, алга таба изге хатын-кызлар культы формалашуның һәм үсүенең орлыгы салынган булган. Иң башта әүлия хатын-кызларда Аллаһтан курку, Аллаһка бирелеп хезмәт итү, матди байлыкларга һәм тән ихтыяҗларына битарафлык, тыйнаклык, сабырлык кебек сыйфатлар кыйммәтле санала. Тора-бара исә әлеге сыйфатларга дин кагыйдәләрен белү, укымышлылык, хәйриячелек итү, могҗиза тудыруга сәләтле булу кебек сыйфатлар да өстәлә.

Суфичылык тарикатенең кайберләрендә хатын-кызлар җыелышларда ирләр белән беррәттән катнаша торган булганнар; ә икенчеләрендә исә алар ирләрдән аерым җыелган. Кайбер хатын-кызлар аскетлар юлына басканнар һәм, Рабига кебек, җәмгыятьтән аерым яшәп, үзләрен Аллаһка багышлаганнар. Ә кайбер хатын-кызлар хәйриячелек белән шөгыльләнгәннәр, дәрвишләргә ярдәм иткәннәр. Бик күпләгән мәгълүм остазларның укытучылары, укучылары, рухи фикердәшләре хатын-кызлар булып, аларның тормышларына һәм дөньяга карашларына хатын-кызлар зур тәэсир ясаган. Кемнеңдер анасы, хатыны буларак, хатын-кызлар үз гаиләләренә дә ярдәм итеп яшәгәннәр, шул ук вакытта Аллаһ белән кушылырга, бер булырга омтылышлы юлларын да дәвам иткәннәр. Суфичылыкның эре вәкиле һәм теоретигы әш-шәехел әкбар Ибн Гарәби (1165–1240) үзенә бик нык йогынты ясаган ике хатын-кыз суфины телгә ала: «елаучыларның» берсе, Мәрчиннән Шәмс һәм Кордовадан Фатыйма [Геммы мудрости, б. 215]. Моннан тыш шунысы да билгеле: иртә чорлардагы, Баязид Бистами (804–846), Зу-н-Нун әл-Мисри (796–859), әл-Хәким әт-Тирмизи (755–869) кебек исеме дөньяга билгеле мистикларның остазлары әүлия хатын-кызлар булган, алар әлеге мәгълүм ир-ат суфиларның рухи дөньяларына зур тәэсир ясаганнар. Мондый хатын-кызлар рәтендә Фатыйма Нишапурины (838 елда үлгән), һинд императоры Шах Җәһанның кызы Фатыйма яисә Җәһан-Аруны санарга мөмкин.

Фарсы һәм борынгы Гарәбстан территорияләрендә беренче актив суфи җәмгыятьләре якынча IX гасырда барлыкка килгән. Алар башта аскетизмга *(зөһед)* һәм Аллаһны ихлас яратуга *(мәхәббә)* чакырганнар. Мистик юнәлешләрнең идеологлары булып ирләр *(әүлийә)*

саналса да, Якын Көнчыгыш мөселман җәмгыятьләрендәге беренче суфи-аскетлар арасына тәкъвалыгы белән дан казанган хатын-кызлар да кергән. Әбу Габдерахман әс-Сүләми (1021 елда үлгән) «Суфичылыкта ирләр һәм хатын-кызлар» («Братья и сёстры в суфизме») дигән мәшһүр әсәре исламдагы иң тәүге хезмәтләрдән санала. Ул озак еллар югалган дип исәпләнелде. Китапта Гарәбстанның зур территорияләрендә VIII–XI гасырларда яшәп киткән йөзләгән суфи хатын-кызның тормыш юлы яктыртылган. Ул чагында гарәп кабиләләре арасында дин белеме күбесенчә телдән телгә тапшыру юлы белән бирелә торган булса да, күп кенә язма чыганакларны да очратырга мөмкин. Алар арасында хатын-кыз суфилар тарафыннан язылганнары да бар. Беренче суфи хатын-кызлар дип Ибраһим б. Әдһәмнең апасын (160/876 елда вафат); Забада бинт әл-Хафине (741 елда вафат) санарга мөмкин. Соңгысының мондый сүзләре билгеле: «Аллаһ колы өчен иң авыры – ул аның гөнаһлары, ә иң җиңеле – тәүбәгә килүе» [Ибн ал-Джаузи..., б. 514]. Хатын-кыз суфилар аеруча тәкъва булулары, Аллаһтан куркулары белән аерылып торганнар, ашау-эчүләрен, йокыларын чикләп яшәгәннәр, аскетларча кырыс тормыш рәвеше алып барганнар, үз артларыннан баручы күпләгән шәкерт булдырганнар.

Кызганычка, әдәбиятта яисә тарихи чыганакларда суфи тематикасын өйрәнгән галимнәрнең бик азы гына суфиларда хатын-кыз мәсьәләсенә туктала. Шундый тикшеренүчеләрнең берсе төрек галиме О.Л. Бәркән колонияләштерү чорында суфи җәмгыятьләренең (*зәвия*) күпчелегенең башында хатын-кызлар торганлыгын ачыклаган. Галим аларның исемнәрен дә атый: Кыз Ана, Ахи Ана, Сагры Хатун, Хаҗи Фатыйма, Хаҗи Баҗи, Хөнди Баҗи Хатун, Суме Баҗи һ. б. [Barkan, б. 323.] Бикташи орденын өйрәнгән Россия тикшеренүчесе Ю.А. Аверьянов фикеренчә, бу рәткә «Хаҗи Бикташ Вәли нәсел дәвамчысы Кадынҗык Ананы» да кертергә мөмкин [Аверьянов, б. 31]. Бикташи тарикатендә хатын-кызларга карата шактый демократик кагыйдәләр урнашкан булган. Мәсәлән, алар теге я бу вакыфның (*мөтәвәлли*) идарәчесе вазифасын башкара алганнар. О.Л. Бәркән хатын-кызның хәтта шәех дәрәҗәсенә җитүенә ике мисал китерә [Barkan, б. 315–316]. 1987 елда Конья шәһәрендә М. Бәйрәмнең Хаҗи Бикташ Вәли тарикатенә якын торган хатын-кыз дәрвишләр турындагы тикшеренүе басылып чыкты [Bayram M. Bacıyan-i Rum..., б. 35–36]. Хезмәт фәнни даирәдә күп бәхәсләр һәм фикерләр тууга сәбәпче булды. Автор бекташиларга хас йолаларны дионисийлар тарикате йолалары белән чагыштыра. Галим гимннар җырлау, биюләр белән үтә торган, хатын-кызлар саны ирләрнеке белән бертигез булган, аларның, бергәләп, төрле йолалар башкаруыннан гыйбарәт җыелышлар Хаҗи Бикташ уйлап чыгарган гамәл түгел, ә Анатолиядәге борынгы традицияләрдән үк килә дигән нәтиҗәгә килә [Bayram, б. 100]. Ничек кенә булмасын, әлеге хезмәт суфичылык тарихында хатын-кызлар һәм аларның хокуклары хакында тәүге мәгълүматлар бирә торган чыганак буларак кыйммәт.

М.Ф. Күпреле соңгы чор Урта гасырларда мөселман Шәрыгында хатын-кызларның социаль оешмалары булмау турында тәкъварга җавап итеп, Кече Азиядә хатын-кызларның хәтта кораллы һәм сугышчан җәмгыяте *(баҗийан)* булганлыгын күрсәтә, бу оешма ирләрнең яшерен *ахи* берләшмәсе белән параллель рәвештә яшәгәнлеген әйтә [Аверьянов, б. 322]. Хатын-кызларның әлеге оешмасы эшчәнлеге турында бүгенге көндә дә җитәрлек мәгълүмат юк һәм моның шулай булуы төрле фаразлар тууга җирлек әзерли.

Идел-Урал Буе территорияләрендә гомер-гомергә гүзәл затларга демократик мөнәсәбәт яшәгән. Әйтик, XIX–XX йөз архив документларына караганда [Бустанов, б. 167], хатын-кызлар ирләр белән берәттән күмәк зикерләрдә *(хәтме хваҗаган)* катнаша торган булганнар, бу гамәлнең аеруча Себердә теркәлгәнлеге мәгълүм [Тычинских, б. 93–106]. Берләшкән дәүләт сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление – ОГПУ) архив документларына һәм мәгълүматларына таянып та шуны әйтергә мөмкин: 50–70 нче елларда Дагстанда мөритләр белән җитәкчелек иткән хатын-кызларның булуы теркәлеп калган [Бустанов, б. 168], алар асылда шәех функциясен башкарганнар. «Тәбсыйрат әл-мөршидин…» әсәренең авторы М. Камалов үзе дә, камиллеккә ирешкән остаз *(мөршид камил)* буларак, үзенең мөритләре арасында хатын-кызларның да булуына ирек куйган. Әлеге факт хакында билгесез автор тарафыннан шигъри формада төзелгән мәрсиядә хәбәр ителә: *Хак Тәгалә шәбабындин вирде хикмәт, җәмгы фән, / Дәрседин тәгълим алырлар әһлийәсендин әһле зан. / Хак Тәгалә вирсә иде гомренә тул бәка, / Тәдрис-тәглимедән һәр фән алыр әһле сафа* [Мәрсийәэ дамелла..., б. 14].

М. Камалов иң беренче чиратта суфи җәмгыятьләрдә күп гасырлардан ныгып урнашкан фикерләргә таяна, шул ук вакытта «Тәбсыйрат әл-мөршидин…»дә Идел буе регионында, шәхсән татарларда, гомер-гомергә хатын-кызга булган демократик карашларның йогынтысы да сиземләнә.

Шул рәвешчә, югарыда китерелгән мисаллар төрле мөселман халыкларында суфилар арасында хатын-кызларның иҗтимагый тормышта җитәрлек дәрәҗәдә әһәмиятле урын биләгәнлекләре хакында сөйли. Бу дәрәҗәләргә хатын-кыз суфилар үзләренең аскетларча тормыш рәвешләре, югары шәхси әхлагы һәм игелекле эшләре аркасында ирешкәннәр. Урта гасыр әдәбиятларында хатын-кызларның каршылыклы чагылдырылган булуына карамастан, суфи тарикатьләренең күпчелегендә аларга мөнәсәбәт демократик характерда булган дип нәтиҗә ясарга нигез бар.

М.-З. Камаловның гарәп телендәге «Тәбсыйрат әл-мөршидин мин әл-мәшаих әл-халидийин»е («Халидия [тармагы] шәехләре остазларыннан кулланма»сы) нәкышбәндия тарикатенең халидия тармагы суфилары ритуаль практикасы нигезенә салынган теоретик принципларның Идел һәм Урал буенда да киң таралганлыгын күрсәтә. М. Камаловның мөритләре арасындагы хатын-кызлар әлеге тарикать

суфилары арасында шактый югары дәрәҗә биләгәннәр. Моннан тыш, башка суфи җәмгыятьләре белән чагыштырганда, нәкышбәндия тарикатенә гомумән хас булганча, биредә хатын-кызлар мөрит-шәкертләрнең остазлары – мөршидләр дә була алганнар. М. Камаловның «Тәбсыйрат әл-мөршидин мин әл-мәшаих әл-халидийин» әсәрендә дә хатын-кызларга хөрмәт, киң күңеллелек мөнәсәбәте күрсәтелә, аларның иң югары әхлакка ирешкәннәрен ир-атлар белән тигез дәрәҗәгә кую омтылышы сиземләнә. Шул ук вакытта Идел-Урал буе татар хатын-кызлары арасында суфилар даирәсендә зур авторитетка ия хатын-кызлар гына тарикатьтә тиешле дәрәҗәдәге урын яулый алган, М. Камалов хезмәтеннән аңлашылганча, суфилык юлына керүче хатын-кызларга таләпнең дә иң югарысы куелган.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, хатын-кыз суфилар күп гасырлар буена ислам дөньясында актив дини һәм иҗтимагый эшчәнлек алып барганнар. Аеруча суфи җәмгыятьләрнең нәкышбәндия һәм бекташи тарикатьләрендә бу ачык чалымлана. Әлеге факт тарихи документларда гына теркәлеп калмыйча, гарәп телле яисә гарәп язулы кулъязма җыентыкларда, мистик практикаларны җентекле аңлаткан теоретик хезмәтләрдә, мәрсияләрдә дә чагылыш тапкан. Мөселман дөньясының киң ареалында (Идел буе, Урал, Кавказ, Төркия, Якын Көнчыгыш, Төньяк Америка илләре) үсеш алган изге хатын-кызлар (әүлияләр) культы суфи җәмгыятьләрендә гүзәл затларның югары дәрәҗәдә торулары хакында сөйли. Хатын-кызларга мондый мөнәсәбәт исламда мистицизм үсә генә башлаган дәверләрдән алып суфи җәмгыятьләре ныгып оешкан чорларны иңли. Идел буе территориясендә дә мондый характердагы кулланмаларның булуы үз чоры өчен тормыш таләбеннән чыгып башкарылган.

**Әдәбият**

*Аверьянов Ю.А.* Хаджи Бекташ Вели и суфийское братство бекташийа. М.: Марджани, 2011. 648 с.

*Амрахов А.К.* Единобожие и мистицизм: монография: в 2-х т. Махачкала: Лотос, 2019. Т. 1. 792 с.

*Бустанов А.К.* Рукопись в контексте сибирского ислама // *Селезнёв А.Г., Селезнёва И.А., Белич И.В.* Культ святых в сибирском исламе: специфика универсального. М.: Марджани, 2009. С. 167.

Геммы мудрости / пер. В.А. Смирнова. Изд.: Бейрут, 1980 // Смирнов А.В. Великий шейх суфизма (опыт парадигмального анализа философии Ибн Араби). М., 1993. С. 145–321.

*Госманов И. Г.* Габделҗаббар Кандалый. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 558 б.

*Ибн ал-Джаузи Абу ал-Фарадж ʻАбд ар-Рахман бин ʻАли.* Сифат ас-суфуа. Бейрут: Дар ал-китаб ал-ʻараби. 2012. 535 с.

Мәрсийәә дамелла Мөхәммәд-Закир хәзрәт әл-Чистай. Казань, 1895 // ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. Ф. 39. Тасв. 1. Сакл. бер. 5107. 15 б.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х., Хасавнех А.А.* Суфичыл җәмгыятьләрдә хатын-кыз урыны һәм роле (Шәех М.-З. Камалов хезмәтләре нигезендә) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2024. № 1. Б. 160–170.

*Тычинских З. Ә.* XVI–XVIII гасырларда Көнбатыш Себернең мөселман элитасы // Фәнни Татарстан. 2023. № 1. Б. 93–106.

*Хасавнех А.А.* Накшбандийский шайх Волго-Уральского региона М.-З. Камалов и его сочинение «Табсират ал-муршидин» // Ученые записки Казан. ун-та. Серия «Гуманитарные науки». 2013. Т. 155. № 3–2. С. 120–126.

*Шиммель А*. Мир исламского мистицизма / пер. с англ. Н.И. Пригариной, А.С. Раппопорт. М.: Алетейя; Энигма, 2000. 414 с.

ابن الجوزي، أبو الفرج عبدالرحمن بن علي. صفات الصفوة. بيروت: دار الكتاب العربي ٢٠١٢. 535 ص.
Ибн ал-Джаузи, Абу ал-Фарадж ‘Абд ар-Рахман бин ‘Али. Качества жизни в достатке. Бейрут: Дар ал-китаб ал-‘араби. 2012). Ибн ал-Джаузи, Абу ал-Фарадж ‘Абд ар-Рахман бин ‘Али. Сифат ас-суфууа. Бейрут: Дар ал-китаб ал-‘араби, 2012. – 535 с. (Гарәп телендә).

أبو عبدالرحمن محمد بن عبدالوهاب الچستاوي. تبصرة المرشدين م المشايخ الخالديين// شعيب بن ادريس الباكني. طبقات الخواجكان النقشبندية و سادات المشايخ الخالدية المحمودية. دماشق: دار النعمان العلوم، ١٩٩٩
Әбу Габдеррахман Мөхәммәд б. Габделвәһһаб әл-Чистави. Табсирател мөршидин минәл мәша’их әл-халидиийин // Шугайб б. Идрис әл-Багини. Табакател Хваджаканен Нәкешбәндийә вәс-сәдател мәша̓ ихел Халидийә әл-Мәхмудийә. Дамаск: Дарен ногманел голүм, 1999. Б. 5–76. (Гарәп телендә).

*Barkan Ö.L.* Osmanlı Imparatorluğunda bir iskân ve kolonizasyon metodu olarak vakıflar ve temlikler // Vakıflar dergisi. 1942. Sayı II. 386 p. (Төрек телендә).

*Bayram M.* Bacıyan-i Rum, Selçuklular tarihinde kadın tekilatları. Konya, 1987. 403 p. (Төрек телендә).

***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, Болгар ислам академиясенең*
*Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-131

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ТАТАР РУХИ МИРАСЫ БУЛАРАК «САЛСАЛ» ДАСТАНЫ:

## М. Юмачиков һәм Г. Исмәгыйлев вариантлары

В статье на примере дастана «Салсал» автор поднимает вопрос взаимодействия и взаимовлияния фольклорной и книжной традиции в современном литературоведении, рассматривает проблему соприкосновения устной и письменной традиций в национальной эпической культуре, отмечает роль автора-сказителя в книжном дастане. Целью статьи является определить значение дастана в этнолитературоведении в целом. Неизученность данного произведения в истории литературоведения и фольклористики обуславливает актуальность темы исследования. В статье автор анализирует два варианта дастана: вариант, составленный М. Юмачиковым в XIX веке, и вновь найденный в наши дни вариант Г. Исмагилова; характеризует основные отличия между вариантами; выявляет общность и особенность текстов; подчеркивает ценность каждого варианта дастана «Салсал» в духовной жизни татар; обращает внимание на живучесть литературно-письменных и фольклорных традиций. В исследовании малоизвестных в филологической науке материалов автор применяет описательный, текстологический, герменевтический методы. Автор определяет высокий потенциал дальнейшего изучения темы.

**Ключевые слова**: дастан «Салсал», духовная культура татар; народное творчество, литературоведение, религиозно-героическое произведение, вариант, национальный эпический фонд.

In the article, using the example of two variants of the dastan «Salsal», the author raises the issue of interaction and mutual influence of folklore and book traditions in modern literary studies, examines the problem of contact between oral and written traditions in national epic culture, notes the role of the author-storyteller in the book dastan. The purpose of the article is to determine the importance of dastan in ethnoliterature studies in general. The unexplored nature of this work in the history of literary studies and folklore studies determines the relevance of the research topic. In the article, the author analyzes two versions of the dastan: the version compiled by M. Yumachikov in the XIX century and the version of G. Ismagilov found again today; characterizes the main differences between the variants; identifies the commonality and peculiarity of the texts; emphasizes the value of each variant of the dastan «Salsal» in the spiritual life of the Tatars; draws attention to the survivability of literary, written and folklore traditions. In the study of materials little known in philological science, the author uses descriptive, textual, hermeneutic methods. The author identifies a high potential for further study of the topic.

**Keywords:** dastan «Salsal», spiritual culture of the Tatars; folk art, literary criticism, religious and heroic work, variant, national epic fund.

«Салсал» дастаны – татар халкы рухи мирасының нигезен тәшкил иткән, әмма соңгы елларда хаксызга онытылган әдәби-фольклор үрнәкләренең берсе. Әдәбият тарихында да, халык иҗатында да заманында зур урын тоткан булуына карамастан, әлеге дастан тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә кала килә, кирилл язуына күчерелмәү сәбәпле, аның тексты да бүгенге укучыга аз билгеле яисә бөтенләй билгесез.

Язманың чыганакларда теркәлә башлау тарихына килсәк, «Салсал» беренче тапкыр 1879 елда Казан университеты типографиясендә 4800 данә тираж белән басылып чыккан. 1883 елда «Вячеслав типографиясе»ндә, 1888 һәм 1906 елларда кабат университет типографиясендә, 1909 елда Казанның «Үрнәк» типографиясендә, 1912 елда тагын университет китапханәсендә шулай ук зур-зур тиражлар белән нәшер ителгән.

«Салсал» дастаны гарәп язулы шигъри тексттан гыйбарәт, күләме 70, 96, 100 битлек китаплар булып, гадәттә «Кыйссаи Салсал» исеме белән дөнья күргән. Әйтик, Казанда 1906 елда басылган вариант түбәндәге сүзләр белән башланып китә:

*Әүвәлдә яд иттем тәңрем атын,*
*Сорасаңыз, Мәүлекәйдер бәнем атым.*
*Төмән менән Омский арасында*
*Һич адәмнән ким имәс солтанатым*

[Кыйссаи Салсал, 1906, б. 3].

Текстта дастанның халыкка җиткерелүенә нисбәтле Мәүлекәй исеме телгә алына. Төрки-татар дөньясына яхшы таныш Мифтахетдин Акмулла, Гали Чокрыйларның чордашы, әмма иҗат белән шөгыльләнүе гомеренең икенче яртысына караган М. Юмачиков халык бәетләре, дастан-кыйссалары нигезендә шигъри яки чәчмә формалы әсәрләр төзеп бастыру белән шөгыльләнгән иҗат кешесе буларак билгеле. Әмма татар дини мәдрәсәсендә белем алган әлеге укымышлы зат хакында фольклористикада да, әдәбият белемендә дә мәгълүматлар аз, шәхесенә һәм иҗатына мөнәсәбәтле махсус тикшеренүләр бөтенләй юк.

Китапның беренче юлларыннан аңлашылганча, М. Юмачиков – талантлы әдип, «Салсал» кыйссасын төзеп бастыручы. Биредә ул дастанны шигъри формага китереп тәкъдим итә. Татар әдәбияты тарихында М. Юмачиков «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Сәет Баттал», «Нәүширван», «Тәминдар», «Карабәк», «Гөлҗәмилә», «Дәрига кыз» һ. б. кыйссаларны Казанда берничә мәртәбә бастырган, «Җар-җар бәете», «Эрбет бәете», «Исерек хәлләре» кебек әсәрләр иҗат иткән [Татар халык иҗаты. Дастаннар, б. 371], «Мәкәрҗә ярминкәсе бәете»н яңача формалаштырган. Казан университеты фәнни китапханәсенең сирәк кульъязмалар бүлегендә аның мәхәббәт лирикасы үрнәкләре саклана [Юмачиков М., 1405Т]. Моннан тыш ул Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанын казакъ теленә тәрҗемә итүче буларак та мәгълүм

[Таһирҗанов, 1975]. Төрки халыкларда уртак сюжетка корылган «Шаһсәнәм һәм Гариб» дастанының татар варианты [Татар халык иҗаты, б. 243–271] да М. Юмачиков каләме белән язылган. Бу – билгеле факт. (Әсәрнең текстын Казан федераль университеты фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә 1513Т шифры белән саклана торган кульязмадан әдәбият белгече М. Гайнетдинов күчереп алган). Кайбер хәбәрләргә караганда, М. Юмачиков үзе язганнарны татар телендә генә түгел, казакъ телендә дә бастырган [Ибатуллин М., электрон ресурс].

М. Юмачиковның төп иҗат методы – халык иҗатының күләмле лиро-эпик һәм эпик әсәрләрен яңартып эшкәртү, аларның форма һәм эчтәлекләрен үзгәртү. Игътибар итсәк, татар халкы китаби дастаннарының бер төркеме – нәкъ менә шундый иҗат җимеше [Мөхәммәтҗанова, 2018, б. 7–9]. М. Юмачиковны гомумтөрки чичәннәрдән саналган Әсән Кайгы, Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау (XV гасыр ахыры – XVI гасыр башы), Чалгиз җырау (XV гасыр – 1560 еллар) һ. б. ларга алмашка килгән татар чичәне дип саный алабыз. Ул – борынгы сюжетларны эшкәртеп, яңа дастаннар барлыкка китергән сирәк иҗатчыларның берсе һәм үз чоры өчен иң активы. Мондый шәхесләрне әсәр авторы белән халык иҗаты ядкәрен җиткерүче информант арасында торучы иҗатчы-импровизатор, автор-җиткерүче дип атасак да дөрес булыр.

Соңгы елларда тарихчылар тарафыннан М. Юмачиковның Төмән өлкәсе Ялутор районы Сингөл авылында туганлыгы, нәсел җепләренең Урта Азия шәехләренә барып тоташканлыгы ачыкланган [Мулекай Юмачиков: новые факты из жизни, электрон ресурс]. Социаль челтәрләрдәге төрле ярым фәнни чыганакларда М. Юмачиковның яшәгән еллары 1834–1910 дип күрсәтелә. Аның шагыйрь, фольклорчы, мөгаллим булуы, 1870–1880 елларда Төмән өязенең Манчыл авылы мәдрәсәсендә мөдәррислек итүе, соңрак Ембай авылында мөгаллим булуы мәгълүм, кабере дә шушы авыл зиратында булырга тиеш дигән фаразлар бар. Мәүләкәй туган теленнән тыш гарәп, фарсы, рус һәм казакъ телләрен камил белгән [Ибатуллин М., электрон ресурс].

Әдәби дастаннар һәм китаби дастаннар традициясенә хас булганча, «Салсал» дастанының башында да, ахырында да әсәрне халыкка җиткерүче образы телгә алына. Биредә ул – М. Юмачиков үзе.

*Фарсы сүздән чыгарып үләң қылдым,*
*Җәмәгать, гаеп кылма инде безне*, –

дигән юлларыннан дастанны шигъри телдә җиткерүче Мәүләкәйнең фарсы әдәби ядкәрләре белән дә яхшы таныш булуы аңлашыла. Дастанны ул Себер җирендә шигъри формага салуы турында да әйткән. Димәк, «Салсал» сюжеты Себердә яшәүче татарлар фольклорында да таралган булган. Дастанны М. Юмачиков кәгазьгә төшергән, ягъни бу әсәр ил авызыннан җыелган һәм, М. Юмачиков тарафыннан басмага әзерләнеп, дөнья күргән. М. Юмачиков дини-романик

«Салсал» дастанын XIX йөз ахыры–XX йөз башында китабилаштырган дип бәяләү дөрес булыр. «Салсал»ны шигъриләштереп, М. Юмачиков кайчандыр Көнчыгыш кулъязмалары аша татарларга килеп ирешеп (әлегә бу әсәрнең Көнчыгыш язма мәдәниятендә тоткан урыны хакында мәгълүмат фаразларга гына нигезләнә һәм тирән тикшеренү алып баруны таләп итә), Себер татарлары авыз иҗатында популярлашкан сюжетка яңа сулыш өргән. Язма формага китерелеп, Казанда китап итеп бастырылуы дастанның Идел буенда яшәүче татарларга да үтеп керүен тәэмин иткән.

Кыйсса Аллаһны зурлый, аны пропагандалый, халыкның игътибарын исламның өстенлекләренә җәлеп итә. «Салсал» дастаны – исламны ныгыту юнәлешендә алып барылган эшчәнлекне тасвирлый торган әсәрләрнең типик үрнәге. Татар халкының билгеле бер тарихи чорында мондый характердагы, исламның җиңүе юлында күп батырлыклар кылган каһарманнарның батырлыгын һәм маҗараларын тасвирлауга корылган, дини эчтәлеккә ия дастаннар шактый киң таралган булган. Аларның татар халкы рухи тормышында үз урыны һәм функциясе бар. «Каһарман Катил», «Җөмҗөмә солтан», «Кыйссаи Сәкам», «Кисекбаш» кебек дастаннарның халыклашкан вариантлары кебек үк, «Салсал» да героик өлгеле, ягъни каһарманлык идеясе белән сугарылган, әмма дини характердагы ядкәр. Мондый төр әсәрләрдә төрки эпостагы батырлык, героика дини героика белән алышынган: моңа кадәр көрәштә үз көченә генә ышанган буйсынмас батыр каһарманлыгын Аллаһ кодрәтенә таянып, Аллаһка буйсынып һәм ислам җиңүе хакына башкара башлый. Эчтәлеге һәм идеясеннән «Салсал» дастанының, нигездә, халык эпосының героик эпосы үрнәгендә иҗат ителгән, татар халкының дини-героик дастаннары рәтен тулыландырып килә торган әсәр булуы күренә. Үз чорында бу әсәрнең кабат-кабат басылып чыгуы һәм таралуы халыкта исламның роле һәм дини-героик китаби дастаннарга ихтыяҗы зур булуны дәлилли.

XX гасыр башында ук татар әдәбияты белгечләре «Салсал» дастаны тибындагы язма истәлекләргә игътибар иткән. Г. Гобәйдуллин мондый төр ядкәрләргә карата «сугыш китаплары» дигән термин куллана. «Безнең халыкның сөеп укый торган әсәрләре арасында үзенә бертөрле типтагы «сугыш китаплары» дип атала торган хикәяләр бар, – дип яза ул. – Бу хикәяләрнең мәүзугысы[1] – төрле каһарманнарның далилек[2], дилавәрлек[3] вә баһадирлыкларын тасвирдыр» [Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар, 2022, б. 62]. Галим мондый төр кыйссаларның татар сүз сәнгатендә бик борынгы чорлардан ук – әле «матбугат туганчы, мөселман хәрефләре белән китаплар басыла башлаганга кадәр кулъязмаларында халык арасына таралып укылган»лыгын билгели, шул чорда ук инде, кызганычка, әлеге кулъязмаларның югала баруын да искәртә: «...Ләкин ул кулъязмалар

[1] Мәүзугысы – темасы.
[2] Далилык –гайрәтлелек.
[3] Дилавәрлек – батырлык.

җыелмаган: башка кульязмаларыбыз шикелле тәләф[1] булып бетәләр инде». Димәк, әдәбият һәм фольклорның икесенә дә нисбәте зур «Салсал»га XX гасыр башында ук күпмедер игътибар күрсәтелгән, әмма алга таба дастаннарыбызны өйрәнү өчен шартлар булмау һ. б. сәбәпләр аркасында бу ядкәр дә күләгәдә калган. Әдәбият тарихында «Салсал» дастаны әледән-әле телгә алына килсә дә, әйткәнебезчә, әсәр махсус өйрәнелмәгән, бүгенге көнгәчә хәзерге язуга күчерелмәгән, төп нөсхә, ягъни татар телендә басылып чыкмаган.

М. Юмачиков вариантында Салсал энҗе җитештерү буенча остаханә хуҗасы буларак тасвирлана. Дин юлында арадан берәүне – иң кыю һәм кодрәтле мөселманны баһадир итеп билгеләү ихтыяҗы туган була, бу уңайдан пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре җыелышып фикерләшәләр. Гали батыр һәм башка мөселманнар кяферләргә каршы көрәштә Салсал батырга хат аша мөрәҗәгать итәләр, Салсал исламның җиңүе өчен кулына корал алып көрәшә, күп батырлыклар кыла. Әсәрдә патшалар һәм аларның бер-берсенә территориаль дәгъвалары мәсьәләсе дә исламга бәйләп аңлатылган.

«Салсал»да әсәр геройлары зур батырлыклар күрсәтәләр. «Салсал» – Г. Гобәйдуллин әйткәнчә, «сугыш китабы», ягъни каһарманлык героикасы белән сугарылган. Дини-героик әсәр буларак, монда шуны ассызыклау мөһим: дастанда ил һәм халыкның гадәттән тыш көчле батыры урынына пьедесталга дин юлында күрсәтелгән батырлык үрнәге, ислам тарихында мәшһүр шәхес образлары күтәрелгән. Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с. г. в.) кияве Гали образы, гайре табигый көч иясе буларак, барысыннан да югарырак тора, сюжет-вакыйгалар да исламга бәйле яктыртыла. Атына атланганда да «Я, Рәсүл Аллаһ» дип Мөхәммәд (с. г. в) пәйгамбәргә сыена торган каһарман аша дастан дин юлындагы батырлыкны бәян итә, ислам өчен көрәшне тасвирлый. Шул ук вакытта Салсал күпләр арасында бердәнбер каһарман буларак тасвирлана, батырлыгын күреп, аны халык үзе сайлый, геройлыклар кылырга өндәп зурлый.

Дастанда эпик образларга хас чикләнгәнлекнең дини элементлар белән баетылуы, сюжет-мотивларга героик эпос өчен чит саналган детальләрнең килеп керүе – татар эпосының стадиаль яктан иң соң формалашкан, XVII–XVIII гасырлардан халыкның рухи тормышында әһәмиятле урын алган дини-героик характердагы эпик ядкәрләрнең барысы өчен дә уртак сыйфат. Халык «Салсал» дастаны аша элгәрләре табынган ислам динендә, Аллаһ кодрәтенә ышануда милли һәм дини кысрыклаудан котылу һәм тынычлану тапкан. Дәүләтчелек, рухи бәйсезлек проблемалары хакында турыдан-туры сөйләп булмаган чор өчен мондый эчтәлекле дастанның әһәмияте, чыннан да, бик зур. «Салсал» – тарихи үсешнең татарлар өчен үзенчәлекле чорларында халкыбызга милли үзаңны, милли үзбилгеләнүне саклап калу чарасы буларак чын мәгънәсендә хезмәт иткән әсәрләрдән.

[1] Тәләф – әрәм.

Дини риваятьләргә нигезләнгән булуы, җир йөзендә ислам урнаштыру юнәлешендә күп көч куйган фидакяр шәхесләрне зурлап тасвирлавы белән бергә «Салсал» традицион мифологик, архаик фольклор мотивларына, җирле легенда-риваять сюжетларына да бик бай. Халыкта мәгълүм риваять буенча, Салсал Аккирмән сараен җеннәрдән тартып алган, ә соңрак сугышта Мәлик Әштер тарафыннан үтерелгән икән. Шулай ук кайчандыр халыкта Аккирмән сараеның диварлары Салсал сөякләре белән бизәлгән дигән легенда да яшәгән [Салсал, 2023, электрон ресурс]. Дастанда тасвирланган вакыйгаларда прототибы татар һәм төркиләрнең исламгача тормышында тирән эз калдырган реаль шәхес булган тарихи һәм уйдырма персонажлар (Атилла һ. б.) катнаша. Исламда тыелган «сихер» мотивының да дини характердагы әсәргә килеп керүе, сюжет корылышында аның кат-кат кабатланып, актив кулланылуы кызыклы. Болар – сюжетның халыкчанлыгын раслый торган элементлар.

Мәгълүмат бик аз булуга карамастан, Салсалны халык риваятьләрендә генә түгел, борынгы Көнчыгыш әдәбиятында да легендар герой дип уйларга нигез бар [Салсал, 2023, электрон ресурс]. Шуңа күрә Салсал образының башка төрки халыклар фольклорында һәм Урта гасырлар Көнчыгыш әдәбиятында да очрау мөмкинлеген күздә тотабыз. Дастанда күп төркиләр өчен уртак мотивлар очрый. Дини характерга ия булуы мавыктыргыч «Салсал»ны кайбер төрки халыкларның уртак сюжеты иткән булырга мөмкин. Социаль челтәрләрдә казакъ тикшеренүчеләренең XX гасыр башында Казанда М. Юмачиков бастырып чыгарган шигъри «Салсал»га мөнәсәбәттә дөньядагы иң эре «Википедия» онлайн-энциклопедиясенә казакъ телендә мәкалә кертүләре, М. Юмачиков вариантын казакъ теленә аударып, «Салсал кыйссасы» исемендәге китап итеп бастырып чыгарулары [Қазірет Әли, 2015, электрон ресурс], дастан текстын казакъ телендә интернет челтәренә урнаштырулары [Кисса Салсал, 2024, электрон ресурс] бу әсәрнең башка төркиләр өчен дә ят булмау ихтималын хәбәр итә. Алдарак «Салсал» дастанын шигъри формага салып китап чыгарган М. Юмачиковның башка халыклар белән уртак сюжетларга моңа кадәр дә әһәмият биргәнлеген искәртеп узган идек. Аның казакъларда да мөгаллимлек иткәнлеге, татар теленнән тыш берничә тел белүе әдипнең казакъ телендә дә иркен иҗат итә алуы хакында сөйли. Хәлбуки ул – себер татарларыннан һәм дастанны да татар телендә төзегән, шуңа күрә казакъ кардәшләребез үз милли версияләрен табу юнәлешендә алга таба тирән эзләнүләр алып барырлар дип уйлыйбыз. Фольклорда да, борынгы әдәбиятта да бер үк сюжетның берничә халык версиясе булырга мөмкин, «Салсал» версия-вариантлары очрагында фәнни тикшеренүләр алып бару алга таба хәлгә һичшиксез ачыклык кертер дип уйлыйбыз.

Башка дини конфессиядәге дәүләт составында гомер кичергән мөселман-татарлар, илдәге тәртипләр белән ачыктан-ачык көрәшмәсәләр дә, «Салсал» кебек дастаннары аша хөкүмәтнең эчке һәм

тышкы сәясәте өлкәсендә үз сүзләрен әйткәннәр. Мондый дастаннарда сюжетның ислам дөньясына бәйлелеге бик зур әчке мәгънәгә ия. Шул һәм башка сәбәпләр «Салсал»ны татар халкына якынайткан. Дастанның фольклор вариантлары барлыкка килеп, аларның әле бүген дә очрап куюы шул хакта сөйли. Күптән түгел Габдулла Исмәгыйлев әлеге дастанның сөйләмә варианты булганлыгын хәбәр итте. Дастан «Салсал батыр» дип атала. Информант аны кечкенә чагында әтисе сөйләгәннән хәтерендә калдырып, кәгазьгә төшергән.

«Салсал» сюжетына бу вариант М. Юмачиковныкына мөнәсәбәттә бераз үзгәреш кичергән. М. Юмачиков вариантын героик-дини характердагы китаби дастан дип бәяләгән булсак, әтисе сөйләвеннән Г. Исмәгыйлев тарафыннан кабат торгызылган вариантта каһарманлык һәм мәхәббәт сюжеты, ягъни романтиклык юнәлеше өстенлек алган. Төп игътибар Салсалның каһарманлыгын ассызыклауга, сугышкөрәш картинасын тасвирлауга, тарихилыкка, дастан каһарманының читтә үз кәләшен табу вакыйгаларына бирелгән. Пәйгамбәр, сәхабә образлары һәм ислам өчен көрәш мотивы алгы планда булмаса да, әлеге вариант ислам йогынтысыннан азат түгел. Ханнар-патшалар тормышы һәм аларның үзара мөнәсәбәтләре дә чагылыш тапкан әлеге вариантта. М. Юмачиков вариантындагы күп кенә сюжет сызыклары башка эчтәлек белән сугарылган, әмма әсәр татар дастанының төп таләпләрен саклый. «Салсал»ның Г. Исмәгыйлев варианты – героика белән бер дәрәҗәдә дип әйтерлек романтик-фәлсәфи рухка ия һәм шактый бай идея-эстетик кыйммәте булган әсәр.

Г. Исмәгыйлев варианты иң элек «Салсал»ның XX гасыр урталарына тел-авыз иҗаты буларак килеп җитә алуы белән кыйммәтле. Күләме 20 битлек бу ядкәр Татарстан Республикасы Саба районы Татар Икшермәсе авылында татар кешесе тарафыннан сөйләнеп, безнең көннәрдә Габдулла Исмәгыйль улы Исмәгыйлев тарафыннан шигъри тел белән язуга төшерелгән. Текстны Габдулла Исмәгыйлевкә телдән сөйләүче – Ибраһимов Исмәгыйль Ибраһим угылы (1897–1987, тумышы белән Татарстанның Саба районы Татар Икшермәсе авылыннан). Ишеткәннәре нигезендә дастан текстын язмада әзерләүче – информантның улы Габдулла Исмәгыйль улы Исмәгыйлев (1950 елгы, Казанда яши). Текстта проза өстенлек итә, әмма шигъри өлешләре дә бар, ягъни «Салсал»ның яңа табылган варианты – катнаш формалы дастан.

Текст ахырында язып алучы тарафыннан өстәлгән генеалогик мәгълүматлар китерелә. Дастанны җиткерүче үзе хакындагы мәгълүматны, М. Юмачиков вариантына Мәүлекәй образы кертелгән кебек, эчтәлеккә үреп урнаштырган. Бу – «Дастаны Бабахан», «Ләйлә – Мәҗнүн», «Салсал» һ. б. дастаннарыбызны халыкка җиткерү традициясенең, дастан стиленең бүгенге көннәргә исән-имин килеп җитә алуының матур үрнәге. Шуңа өстәп, дастан текстында мондый характердагы аңлатмалар урнаштырылуның татар шәҗәрәләрен барлау җәһәтеннән дә тарихи әһәмияте юк түгел. М. Юмачиков «Салсал»

сюжетлы дастан текстын Себердә төзегән булса, Г. Исмәгыйлевнең Казан татары булуы исә татар дастанының таралыш ареалы никадәр киң булуны янә бер кат раслый. Бер үк сюжетка дастанның яңа буында кабат яңаруы татар дастанының яшәүчәнлеген, дәвамчанлыгын ассызыклый.

«Салсал»ның Г. Исмәгыйлев тәкъдим иткән варианты аеруча халыкчан, җирле үзенчәлекләргә бик бай. «Салсал» исеменең килеп чыгышы да дастанда саф татар теле аша аңлатылган: Балтасар ханның улы Сөләйман бик батыр була, көрәшеп дан ала, халык аның көченә шакката, көрәштә көндәшен аркасына салырга өндәп, «Сал, сал!» – дип кычкырганнан батырның исеме Салсал булып киткән, имеш. Шул рәвешчә, Сөләйман Салсал батыр исеме белән мәгълүм була.

Эпик вакыйгалар фонында дастан Салсал батырның каһарманлык һәм мәхәббәт тарихын бәян итә. Әлеге ядкәрдә этисеннән ишеткән кыйссаны сөйләүче авторның, эпос кагыйдәләреннән бераз читкәрәк китеп, вакыйгаларны тасвирлаганда иҗади коллизияләргә күбрәк урын бирү омтылышын да искәртик. Бу – татар дастаннары үсешендә зур урын алып торган китабилык, ягъни сөйләмә эпоска язма мәдәният тәэсире белән тыгыз бәйле күренеш. Шул ук вакытта татар эпосында борынгыдан килә торган эпик мотивлар (каһарман туу, исем кушу, батыр балачак, кәләш эзләп читкә китү, каһарманга кәләш ярәшү, батырларның көрәш-орышы, каһарманның үлеме һ. б.), ханнар томышы сурәтләнү, топонимик атамаларның чынбарлык белән параллельлеге, дастанда эпик вакыйгаларга киң урын бирелү һ. б. – болар барысы да «Салсал батыр»ның М. Юмачиков варианты шулай ук татар эпосы белән аваздашлыгын раслый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, «Салсал» – дини-героик яисә дини-романтик характердагы күләмле эпик әсәр. Фольклор белән әдәбият арасында тора торган ядкәр буларак, ул татар дастаннарының китаби төренә керә. Дастанның XIX гасырда татар китаби дастаннарын үстерү юнәлешендә эшчәнлек алып барган сирәк шәхесләрнең берсе М. Юмачиков төзегән варианты да, бүгенге көндә табылып, дастанның халык телендә әле дә яшәвен раслый торган, Г. Исмәгыйлев тарафыннан язма формада җиткерелгән варианты да – татар дастаны тарихын һәм милли эпик фондны баета торган ярым әдәби, ярым фольклор истәлекләр. Дини һәм романтик героика белән сугарылган «Салсал» дастаны мисалында фольклор сюжетының соңгы берничә гасырда эчтәлек җәһәтеннән һәм идея-структур яктан нинди үсеш-үзгәрешләр кичерүен күзәтергә мөмкин. Әлеге дастан тирәсендә бүгенге көнгәчә ачыкланып бетмәгән сораулар алга таба бу юнәлештә фәнни эшчәнлек алып баруны көтеп кала. Дастан текстларының гарәп язуындагыларын хәзерге язуга күчереп бастырып, халыкка кире кайтару бурычы да көн кадагында кала. Гомумән, Салсал дигән исем үзенең килеп чыгышы белән фарсы чыгышлы сүз булырга мөмкин, шуңа күрә «Салсал» дастаны, чыннан да, борынгы һәм Урта гасырлар фарсы әдәбияты белән дә бәйле карала ала. Аз өйрәнелгән

әлеге дастанны фәнни тирәнлектә анализлау, генетик һәм типологик тамырларын, этимологиясен, таралыш ареалын өйрәнү, М. Юмачиков шәхесен ачыклау һәм иҗатын махсус барлау, дастанның яңа вариантларын җиткерүчеләр турында да күбрәк мәгълүмат туплау – әдәбият һәм фольклор белгечләре, текстологлар, тарихчылар алдында торган актуаль бурычларның берсе. Татар фәнендә бүгенге көндә «Салсал» дастанын монографик дәрәҗәдә өйрәнгән махсус фәнни хезмәткә чын мәгънәсендә зур ихтыяҗ бар.

**Әдәбият**


Ибатуллин М. Мауликай Юмачиков – Ембаевский стихотворец 19 века // URL: https://seber-tatar.livejournal.com/35431.html (мөрәҗәгать итү көне: 14.07.2024).

Кисса Салсал // URL: https://kozhalar.kz/20174306-qissa-salsal (мөрәҗәгать итү көне: 06.07.2024).

Кыйссаи Сал-сал. Казан: Ун-т тип., Ш. Хөсәенов варислары нәшере, 1906. 100 б.

*Қазірет Әли.* Діни дастандар. Алматы, 2015. 362 б.

Маулекай Юмачиков: новые факты из жизни // URL: https://rayon72.ru/news/history/187286.html (мөрәҗәгать итү көне: 14.07.2024).

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары. Казан: ТӘһСИ, 2018. 280 б.

Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Г. Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер. XVII–XIX гасырлар = Духовное наследие: поиски и открытия. Г. Рахим, Г. Газиз. История татарской литературы. Древний период. XVII–XIX века. Т. 2 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Ш. Гарипова, Л.Р. Надыршина, А.М. Ахунов, И.Г. Гомәров, Г.А. Хөснетдинова. Казан: ТӘһСИ, 2022. 16 нчы чыг. 300 б.

Салсал // URL: https://kk.wikipedia.org/wiki/Салсал (мөрәҗәгать итү көне: 27.07.2024).

Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар кит. нәшр., 1984. 384 б.

*Таһирҗанов Г.* Әдәби багланышлар һәм аларның нәтиҗәләре // Казан утлары. 1975. № 10.

*Юмачиков М.* Шигырьләр // КФУ Н. Лобачевский исем. фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге. 1405Т.


***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

*И.К. Заһидуллин*

# СӘЛАМ ХАТЫЙП УЛЫ АЛИШЕВ – Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНЫҢ ӘЙДӘП БАРУЧЫ ТАРИХЧЫСЫ

В этом году Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ отмечает 85-летие со дня создания. В 1963–1966 г. в его аспирантуре обучался, затем в секторе истории три десятилетия проработал Салям Хатипович Алишев (1929–2015), он здесь состоялся как крупный татарский историк и организатор науки. В 1960–1980 гг., когда плановые научные темы большинства сотрудников сектора истории ограничивались советским периодом, достижения и успехи ИЯЛИ по исследованию прошлого татарского народа XV–XIX вв. во многом определялись трудами С.Х. Алишева. Статья посвящена жизненному пути и научной деятельности известного татарского историка.

**Ключевые слова:** С.Х. Алишев, сектор истории Института языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова, история татарского народа XV–XIX вв.

This year, the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan celebrates its 85th anniversary. In 1963–1966, Salam Khatipovich Alishev (1929–2015) studied at its postgraduate school, then worked in the history sector for three decades. In the 1960s–1980s when the planned scientific topics of the majority of the employees of the History Sector were limited to the Soviet period the achievements and successes of the Institute of Literature and Literature in the study of the past of the Tatar people of the 15th–19th centuries were largely determined by the works of S.Kh. Alishev. The article is devoted to the life and scientific activities of the famous Tatar historian.

**Keywords:** S.Kh. Alishev, the history sector of the Institute of Language, Literature and History named after G. Ibragimov, the history of the Tatar people of the XV–XIX centuries.

2024 елда күренекле татар тарихчысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, тарих фәннәре докторы Сәлам Хатыйп улы Алишевның тууына 95 ел тулды.

1970–1980 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлегендә күпчелек темалар совет чорын өйрәнүгә багышланган иде. Шул сәбәпле татар халкының XV–XIX гасырлардагы тарихын тикшерү өлкәсендәге күп кенә казанышлар нәкъ менә С.Х. Алишев хезмәтләре белән билгеләнде. Ул Институтта 1963–1966 елларда аспирантурада укыды, аннан соң өч дистә ел биредә фәнни эзләнүләр белән шөгыльләнде, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен әзерләп, уңышлы яклады, мәшһүр татар тарихчысы булып танылды, соңгы бер дистә елдан артык, 1990–

1996 елларда, тарих бүлеге мөдире буларак, фәнни эзләнүләр оештыруда зур хезмәт куйды.

Минем галим белән якыннан аралашуым 1990–1993 елларда, фәнни хезмәткәр сыйфатында, С.Х. Алишев СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы тарих бүлеге мөдире булып эшләгәндә башланды. Вакытлар үтеп, үзем Тарих институтында Урта гасырлар тарихы бүлеген җитәкләгәндә, Сәлам Хатыйп улы 1998–2011 елларда баш гыйльми хезмәткәр вазифасында хезмәт куйды.

1989–1994 елларда бүлек хезмәткәрләре дүрт китаптан торган «Татарстан Республикасы тарихын» язу белән шөгыльләнде. Беренче томга мәкаләләрне С.Х. Алишев, Р.Г. Фәхретдинов, Р.Г. Галләм, А.А. Арсланова, Н.С. Хәмитбаева язды. Икенче томның бүлекләрен язуга Ю.И. Смыков, Р. Г. Әмирханов, Н.С. Хәмитбаева, И.К. Заһидуллин җәлеп ителде. М.К. Мөхәррәмов, И.Г. Гыйззәтуллин, К.А. Нәзипова, М.А. Сәйдәшева, З.Г. Гарипова, Г.Л. Фәйзрахманов, Ә.Г. Галләмова һәм Т.И. Славко коллектив монографиянең сугышка кадәрге (1917–1940) һәм сугыштан соңгы чорларын (1941–1990) үз эченә алган соңгы ике китабын яздылар.

Заманнар үзгәреп, кайбер томнар эшләнеп бетмәде, дүрт томлык күмәк монографиянең бер томы да басылып чыкмады. (Соңрак ул текстлар мәктәп дәреслекләре һәм уку әсбаплары, китаплар һәм мәкаләләр буларак укучыга барып иреште). Сәбәпләрнең берсе – тарихи тикшеренүләр өлкәсендә яңача фикерләүнең өстенлек алуы: 1993 елда тарих бүлегендә һәм Институтның Гыйльми советында «Татар халкы тарихы» булдыру концепциясе тикшерелде [Алишев, 2000, с. 24–25].

1989–1998 елларда хезмәт коллективының казанышлары һәм хезмәттәшләренең фәнни уңышлары турында С.Х. Алишев «1989–1998 елларда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Тарих институты тарихы бүлеге» дип аталган күләмле мәкаләсендә бәян итте [Алишев, 2000, с. 24–25].

Сәлам Хатыйп улы 1929 елның 20 мартында Аксубай районының Шәрбән авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Бер елдан гаилә әтисенең төп чыгышы булган Яңа Әлмәт авылына күченеп кайта. Әтисе (1870–1945) һәм әнисе (1887–1985) картаялар, хуҗалыкны алып бару, утын, печән хәзерләү кебек олы мәшәкатьләр яшүсмер малайга күчә. Ул сугыш елларында колхоз эшендә катнашып, җир тырмалый, лобогрейка белән урак урдыра. 1945 елдан мәктәп укучысы трактор бригадасы хисапчысы булып эшли башлый. Туган авылында балалар аз булу сәбәпле, 6 нчы сыйныф ябылгач, башта 3 чакрым ераклыкта урнашкан Кычытканлы авылы мәктәбендә 7 нче сыйныфта, аннары 5 чакрымда урнашкан Күлбай-Мораса урта мәктәбенә барып укып, урта белем турында таныклык ала.

1947 елны тарих укытучысы булырга карар кыла һәм Казан педагогика институтының тарих факультетына укырга керә. 1951 елда

институтны тәмамлап, Лаеш районы Татар Сараланы авылында урнашкан бердәнбер татар урта мәктәбенә укытучы итеп билгеләнә, бер елдан уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары вазифасын башкара башлый. Мәктәпкә төбәкнең төрле авылларыннан, шул исәптән ерак урнашкан торак пунктлардан да килеп укыйлар. Кыш көннәрендә аларны колхозчылардан арендага алган өйләргә урнаштыралар. Мәктәп бинасы зур булмаганлыктан, уку ике сменада алып барыла, кичке якта сыйныф бүлмәләре керосин лампалары белән яктыртыла.

С.Х. Алишев җәйләрен туган авылына кайтып, ялгыз яшәгән әнисенә йорт җиткерә. Эш урынына килсә – хакимият авылда яңа мәктәп бинасы төзегән, ә ул мәктәп директоры итеп билгеләнгән була.

Яшь директор тырышлыгы белән, тиз арада җиләк-җимеш һәм яшелчә тәҗрибә участогы булдырыла, мәктәпкә яңа җиһазлар кайтарыла, укытуның сыйфатына зур игътибар бирелә башлый.

Куйбышев сусаклагычы буасын ябар алдыннан район мәктәпләренә леспромхоз биналарын бүлеп бирәләр. Сүтеп, трактор чаналарына төяп алып кайткан бүрәнәләрдән мәктәп өчен зур гына остаханә һәм ике бүлмәле торак йорт җиткерелә. Директор, «чүлмәкләр» ясап, колхоз кырында кукуруз игүне дә, ит җитештерүнең бишьеллык планын өч елда үтәү кампаниясе кысаларында мәктәптә үрдәк-чеби үстерүне дә оештыра.

1950 еллар ахырында авыл мәктәпләрендә балалар санының кимүе күзәтелә. Татар Сараланы мәктәбендә дә 17 сыйныфтан 13 е кала. Директор Авыл советындагы хуҗалык кенәгәләрен өйрәнеп, киләчәктә балалар санының тагын да кимиячәген ачыклый һәм мәктәптән китәргә карар кыла. 1960–1962 елларда Югары Ослан районы Мәгариф бүлеген җитәкли, аннан Казанда кооператив фатир төзеп, гаиләсе белән шәһәргә күченә.

1963 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлегенә аспирантурага укырга кергәндә, аның гарәп графикасындагы текстларны укый белүе хәлиткеч роль уйный [Галлям, 1999, б. 6–9].

Читтән караганда, Сәлам Хатыйп улы тормышындагы мондый кискен борылыш һич кенә дә очраклы хәл дип кабул ителми: ул туган затлы нәселгә борын-борыннан гыйлемгә омтылу хас була. Шәҗәрәләреннән күренгәнчә, иң борынгы бабасы Галишаһ (XVI гасырның икенче яртысы – XVII гасырның беренче яртысы) та – дин әһеле, улы Әлмәтулла (XVII гасырның беренче яртысы) Иске Әлмәт авылында дин гыйлеме тарата, анысының нәсел дәвамчысы Сөрмәт (1620 – XVII гасыр ахыры), Сәмәркандта белем алып, Корьән-хафиз дәрәҗәсенә ирешә. Сөрмәт улы Ибраһим (1690–1780) Яңа Әлмәт авылында тормыш итә. Калган бабалары да заманының гыйлемле шәхесләре булып таныла. Җәгъфәр (1729–1796) исемлесе «Каһестани» (Күрәзәчелек иле) исемле әсәр яза. Аның улы Гобәйдулла (1751–1823) Оренбург губернасындагы мәшһүр Каргалы бистәсе мәдрәсәсендә бе-

лем ала һәм Кизләү (Корманай) авылында мәдрәсә җитәкли. Аның улы Нигъмәтулла (1775–1853) – Яңа Әлмәт авылы ишаны – турында мәгълүмат Ш. Мәрҗани хезмәтендә һәм Хөсәен Әмирханның «Тәварихе Болгария» китабында сакланган. Соңгысы болай дип язып калдырган: «Мөбарәк һәм тәбарәк, камил инсан иде Әлмәт авылында Нигъмәтулла ишан».

Татар балалар язучысы Абдулла Алиш – шул ишанның Гатаулла исемле улының оныгы.

Нигъмәтулланың бер улы Мирхәйдәрҗан (1848–1912) туган авылының җамигъ мәчетендә имам хатип булып эшли. Аның улы – Мөхәммәдхатыйп (1870–1945) – булачак тарихчының әтисе – Казанның Күл буе мәдрәсәсендә укыган, Чистай төбәгенең хөрмәтле рухание булган. Ул 1920 еллар ахырында мулла вазифасын калдырып, колхозчы булып язылган [Алишев, 2010, б. 246–247].

Шунысы кызык, Мөхәммәтхатыйп, 1945 елның февралендә Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулу уңаеннан уздырылачак чаралар турында ишеткәч, шәкерт вакытта мәгърифәтче янына килеп бер ай геометрия фәне нигезләре буенча дәресләр алуы хакында истәлекләрен Тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәрә [Каюм Насыйри..., 1948, б. 141].

Алишевлар шәҗәрәсе Сәлам Хатыйп улының мәшһүр зыялылар династиясе варисы булуын күрсәтә, бу нәсел вәкилләре руханилар әзерләүдә, татар халкы арасында дин гыйлеме тарату һәм әхлакый тәрбия бирүдә зур хезмәт куйганнар.

Аспирантурада укыганда, С.Х. Алишевның фәнни җитәкчесе Идел буе төбәгенең Урта гасырлар һәм Яңа заман тарихы буенча зур белгеч, өлкән фәнни хезмәткәр, тарих фәннәре кандидаты Е.И. Чернышев була. Ул шәкертен Урта гасыр документларын укырга өйрәтә. 1773–1775 елларда Е. Пугачёв җитәкчелегендә баш күтәрүдә Идел-Чулман төбәге халыкларының катнашуын өйрәнә башлаган олуг галим аспирантына да бу вакыйгаларда татарларның катнашуы хакындагы теманы бирә.

Тәкъдим ителгән тема яшь тарихчының киләчәктә фәнни кызыксыну өлкәләрен һәм юнәлешләрен билгеләүдә гаять мөһим роль уйный. Беренчедән, ул заман тәртибе буенча, Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләреннән ТАССРдан читтә яшәгән татарларны, нигездә, этнографлар һәм тел галимнәре өйрәнгән. Диссертация темасы исә аспирантны Е. Пугачёв җитәкчелегендәге баш күтәрүдә катнашучылары булган төбәкләрне колачларга этәрә. Икенчедән, чыганаклар туплау өчен, Мәскәү һәм күрше өлкә архивларында эшләргә кирәк була. Баш күтәрүнең икътисади, социаль һәм башка сәбәпләрен ачыклау максатында, аспирант XVIII гасырның 50–70 нче елларында империя хакимиятенең эчке сәясәтен һәм төрле социаль төркемнәрдән торган татарларның икътисади хәләтен һәм социаль тормышын өйрәнергә тиеш була (диссертациянең беренче бүлеге шуңа багышланган).

Әйтергә кирәк, аспирант 1966 елда укуын диссертациясен өстәлгә салып тәмамлый. 1968 елда «Татарларның 1773–1775 елларда Е. Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында катнашуы» дип исемләнгән кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. Хезмәттә беренче тапкыр, тарихи чыганакларга таянып, Россия халыкларының хакимияткә каршы баш күтәрүләрендә мөселманнарның актив катнашуы дәлилләнә.

1973 елда диссертация текстын тәшкил иткән «Пугачёв восстаниесендә Урта Идел Буе татарлары» китабының [Алишев, 1973] дөнья күрүе республикада төбәк тарихы белән кызыксынучылар санын арттыра. Бу фәнни монография тәэсирендә әдәби әсәрләр дә языла. Бу уңайдан, Туфан Миңнуллинның 1977 елда иҗат ителгән «Канкай углы Бәхтияр» тарихи драмасын һәм Мостафа Ногман балладасын атап үтү урынлы.

Сәлам Хатыйп улының фән өлкәсендә ирешкән уңышлары серенең нигезен хезмәт сөючәнлек һәм тырышлык, җаваплылык һәм тарихи чыганакларга тәнкыйди караш, тарихчы һөнәренә мәхәббәт һәм туган халкының чын тарихын язу теләге тәшкил итте дисәк, һич тә ялгыш булмас. Моның шулай икәнлеге галимнең, 61 яшендә докторлык диссертациясен уңышлы яклагач, элеккечә дәрт-илһам белән фәнни эзләнүләрен дәвам итүендә ачык күренә. Лаеклы ялга чыккач та, киеренке режимда эшләп, күпсанлы яңа фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр язды ул. Без, аның коллегалары, өлкән тарихчыбызның шундый нәтиҗәле эшләвенә соклана, гаҗәпләнә һәм аның белән горурлана идек.

С.Х. Алишев һәрвакыт иҗади эзләнүдә булды. Галимнең кандидатлык темасы М.Г. Госманов һәм И.А. Гыйләҗев белән берлектә әзерләгән «Воззвания и переписка вожаков пугачёвского движения в Поволжье и Приуралье» (1988) [Воззвания и переписка..., 1988] исемле документлар җыентыгында дәвам итте.

Соңрак бу тема, хронологик яктан киңәйтелеп, авторга татарларның хөкүмәткә каршы чыгышларын бербөтен иҗтимагый күренеш рәвешендә сурәтләргә, XVI–XIX гасырның икенче яртысында булган иң күләмле протест чараларын барларга, аларның сәбәпләрен, баш күтәрүчеләрнең таләпләрен, оешу һәм оештыру формаларын һәм механизмнарын билгеләргә, крестьян баш күтәрүләренең үзенчәлекле якларын һәм аларга милли элита вәкилләренең йогынты ясау юлларын ачыкларга мөмкинлек бирде. Бу эзләнүләрнең нәтиҗәсе булып «Каһарман бабайлар» [Алишев, 1976] һәм «Тернистый путь борьбы за свободу. (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI–XIX вв.)» [Алишев, 1999] китаплары тора.

1970 елларда һәм 1980 елларның беренче яртысында, С.Х. Алишев җәмәгать эшлеклеләре һәм зыялыларның юбилейлары уңаеннан, кайвакыт махсус институт басмалары өчен яки башка сәбәпләр белән К. Насыйри һәм С. Аитов, Г. Колахмәтов, Ш. Мәрҗани, Г. Ибраһи-

мов турында мәкаләләр язды. Шулай ук Казан тарихын өйрәнгән империя чоры галимнәре М.С. Рыбушкин, К. Фукс, Н.К. Баженов, Н.Я. Износков, Н.Я. Агафонов хезмәтләренә дә этрафлы бәя бирде. Бу шәхесләрнең исемнәре үзләре үк тарих секторы өлкән фәнни хезмәткәренең тикшеренү өлкәсе никадар киң булуын раслап торалар. Аның «По следам минувшего» (1986) [Алишев, 1986] исемле китабында югарыда аталган шәхесләр турында күзәтүләре туплап бирелде.

Бүгенге көнгә кадәр Татарстан башкаласының үткәне турындагы бердәнбер коллектив монография булып торган ике томлы «Казан тарихы»ның беренче китабындагы (1988) [Алишев, 1988] «Казанны рус дәүләтенә кушу», «Казан үзәкләштерелгән рус дәүләте составында», «Казан XVIII гасыр дворян империясендә» исемле бүлекләрне – берүзе, «Казанны нигезләү» бүлеген А.Х. Халиков белән бергә язды.

Ул 1970 елларда язган мәкаләләрендә Казан ханлыгының агрессив, кыргый һәм басып алучы дәүләт түгеллеген раслады, аның алдынгы, төзек, югары мәдәниятле дәүләт булганлыгын әйтте [Алишев, 1975, с. 172–185].

1978 елда Мәскәүдә – СССР Фәннәр академиясенең Тарих институтында – докторлык диссертациясенең нигезе булачак «Урта Идел төбәген рус дәүләтенә кушу» монографиясен тикшергәндә, галимнең Казан ханлыгының яулап алынуы, төбәк халыкларын көчләп Мәскәү дәүләтенә кушу һ. б. турындагы кайбер фикерләре «ялгыш» дип табыла.

1980 еллар ахырында С.Х. Алишев кабат фәнни квалификациясен күтәрү эшенә алына. 1988 елны СССР Фәннәр академиясенең Тарих институтында аның диссертация кулъязмасы тикшерелә. Мәскәү галимнәре хезмәттән Казан ханлыгы чорын алып ташларга тәкъдим итәләр, аларны авторның ханлык белән Бөек Мәскәү кенәзлеген чагыштыруы борчый. С. Алишевка шул ук елның көзендә, хезмәтен әйткәнчә үзгәртеп, кабат тикшерүгә барырга туры килә [Галлям, 1999, б. 10–11, 16]. Шул рәвешле, 1990 елны ул Мәскәүдә «VI йөздә – XIX гасырның беренче яртысында Урта Идел төбәге» дигән докторлык диссертациясен уңышлы яклый [Алишев, 1989], хезмәт шул ук елны «Фән» нәшриятында «Исторические судьбы народов Среднего Поволжья. XVI – начало XIX вв.» исеме белән нәшер ителә [Алишев, 2005].

Китапта Казан ханлыгы халыкларының яңа сәяси шартларда социаль, иҗтимагый, икътисади, мәдәни яшәеше яктыртыла, төбәк халыкларының үзара аралашулары сурәтләнә. Казан ханлыгы турындагы бүлек алына, татар халкы өчен мөһим кайбер темалар да «заманча» аңлатыла. 1552 елгы вакыйгалар феодал сугыш – ике вәхши феодаллар төркеме арасындагы канлы көрәш рәвешендә шәрехләнә [Алишев, 2005, с. 260]. Крестьяннар XVI гасырда авыр авыл хуҗалыгы хезмәте белән шөгыльләнгәннәр, алар феодалларның мәнфәгатьләрен яклап сугышырга теләмәгәннәр; бу яктан караганда, аларның яңа хакимияткә буйсынулары ирекле булган. Киң планда карасак,

аларның буйсынулары бүгенге көндә киң таралган «үз теләкләре белән кушылу» мәгънәсенә туры килә [Алишев, 2005, с. 259].

Илдә сүз иреге урнашкач кына, бу четерекле мәсьәлә турында башкача язарга мөмкинлек туды. Әйтик, 2005 елда басылган бер мәкаләсендә автор татарның туган җиренә, халкына, дәүләтенә, туган теленә булган мәхәббәте бигрәк тә Казанны батырларча саклаганда ачык күренде, дип ассызыклады [Алишев, 2005, с. 71–96].

Галимнең докторлык диссертациясен яклауга бәйле тарган «маҗаралары», яшь галимнәргә совет чоры тарих фәне үсешен өйрәнгәндә, һичшиксез, ул заман сәяси вазгыятен исәпкә алып фикер йөртергә кирәклеген искәртә.

1995 елда аның «Казань и Москва: Межгосударственные отношения в XV–XVI вв.» исемле китабы укучы кулына барып иреште [Алишев, 1995].

Сәлам Хатыйп улының фәнни һәм иҗтимагый эш юнәлешләренең берсе татар интеллектуаллары һәм галимнәренең әсәрләрен халыкка кайтару белән бәйле. Әйтик, 1977 елны Каюм Насыйриның русчага тәрҗемә ителгән хезмәтләренең бердәнбер томы [Насыри, 1977], ул 1984 елда әзерләп бастырган Г. Ибраһимовның сигезтомлыгының 7 нче томы – «Тарихи хезмәтләре» – нәшер ителү зур вакыйга булды [Ибраһимов, 1987]. 1989 елны аның редакциясендә Г. Гобәйдуллинның сайланма хезмәтләре тупланган «Тарихи сәхифәләр ачылганда» китабы дөнья күрде [Гобәйдуллин, 1989]. 1993 елда ул республика фәнни җәмәгатьчелегенә Һ. Атласиның «Себер тарихы», «Сөембикә», «Казан ханлыгы» хезмәтләрен әзерләп тәкъдим итте [Һади Атласи, 1993].

2006 елда чыккан «Татар тарихчылары» [Алишев, 2006] исемле китап исә, галимнең күпьеллык фәнни эшчәнлегенең нәтиҗәсе кебек кабул ителә. Аның беренче бүлегендә Казан ханлыгы чорыннан сакланган татарча чыганаклар бәян ителә. Икенче һәм өченче бүлекләрдә тарихи белемнәр таралу һәм беренче әсәрләр язылуның иктисади, иҗтимагый, сәяси сәбәпләре һәм алшартлары яктыртыла, XIX гасыр – XX гасырның беренче чирегендә татар галимнәренең фәнни эшләрендәге төп юнәлешләр билгеләнә. К. Насыйри, Хөсәен һәм Габделгаллəм Фәезхановлар, шагыйрь Г. Чокрый һ. б. күп кенә шәхесләрнең тарихи карашларына, татарлар тарафыннан язылган Россия һәм Гомуми тарих дәреслекләренә күзәтү ясала, Ш. Мәрҗани, Г. Гобәйдуллин, Р. Фәхретдин, Зәки Вәлиди, Хәсәнгата Габәши, Габдерәшит Ибраһимов һ. б. ларның гыйльми мираслары бәяләнә.

Татар халкының этногенезы мәсьәләсе С.Х. Алишевның «Болгаро-казанские и золотоордынские отношения. XIII–XV вв.» (2009) [Алишев, 2009] исемле китабында чагылыш тапты. Автор, Алтын Урда халыкларының күчмәннәр икәнен искәртеп, Идел-Чулман Болгар дәүләтенең дәвамчысы Казан ханлыгы булуын, анда яшәгән халыкның утрак тормыш алып баруын, этник яктан болгарлардан һәм өлешчә кыпчаклардан торуларын ассызыклады.

Күренекле тарихчы 1990 елларда милли тарихны популярлаштыру өлкәсендә республиканың вакытлы матбугаты битләрендә – автор, шулай ук «Аргамак», «Гасырлар авазы – Эхо веков», «Научный Татарстан» журналлары редакцияләре әгъзасы сыйфатында зур хезмәт куйды.

Алишев – үзе исән чакта ук илебездә төп фәнни хезмәтләре зур тиражлар белән бастырылган сирәк тарихчыларның берсе. Бу аның күренекле һәм танылган галим булуын раслаучы тагын бер дәлил булып тора.

2005 һәм 2009 елларда «Раннур» нәшрияты тарафыннан тарихчының төп әсәрләре кергән «Все об истории Казани» (40 басма табак) [Алишев, 2005] һәм «Все об истории татарского народа» (38 басма табак) [Алишев, 2010] китаплары 20 мең һәм 50 мең данә тираж белән нәшер ителү милләт тарихы белән кызыксынучылар өчен чын мәгънәсендә кадерле бүләк булды.

Эштән киткәч, гомеренең соңгы елларында ул бабаларына багышланган «Галишаһ морза нәселе» исемле фәнни-публицистик роман язу белән шөгыльләнде. Галимнең бу хезмәте 2015 елда дөнья күрде [Алишев, 2015]. Шул ук елның 23 июнендә Сәлам Хатыйп улы вафат булды.

Шунысы куанычлы: С.Х. Алишев җитәкчелегендә кандидатлык диссертацияләре яклаган Булат Хәмидуллин, Рәшит Галләм, Илшат Фәйзрахмановлар бүген эзләнүләрен нәтиҗәле дәвам итәләр.

Алишевларның галимнәр династиясе дә үсештә. Улы Булат – педагогика фәннәре докторы, оныгы Тимерхан – социология фәннәре кандидаты буларак, фәнни даирәдә танылу алдылар.

С.Х. Алишев – 19 фәнни һәм фәнни-популяр китап, 250 дән артык фәнни һәм башка мәкаләләр һәм язмалар авторы. Бу уңайдан, бүгенге укучыга атап, Сәлам Хатыйп улының фәнни әһәмиятләрен әле дә саклаган хезмәтләрен интернетка урнаштыру мәсьәләсе көн тәртибендә тора.

**Әдәбият**

*Алишев С.Х.* Болгаро-казанские и золотоордынские отношения. XIII–XV вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. 159 с.

*Алишев С.Х.* Все по истории Казани: Казань: Раннур, 2005.

*Алишев С.Х.* Все по истории татарского народа. Казань: Раннур, 2010. 606 с.

*Алишев С.Х.* Галишаһ морза нәселе // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Сб. статей. Вып. 1. Материалы Всерос. науч.-практ. конф. «Исторические судьбы народов Среднего Поволжья в XV–XIX вв.», посвященной 80-летнему юбилею д-ра ист. наук С.Х. Алишева (г. Казань, 24 марта 2009 г.) / отв. ред. и сост. И.К. Загидуллин. Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2010. С. 246–247.

*Алишев С.Х.* Галишаһ морза нәселе. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 559 б.

Каюм Насыйри турында истәлекләр // Каюм Насыйри. 1825–1945. Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материалары / җав. ред. Ш.А. Рамазанов. Казан: Татгосиздат, 1948. Б. 141.

*Алишев С.Х.* Татары Среднего Поволжья в пугачевском восстании / под ред. З.И. Гильманова. Казань: Татар. кн. изд-во, 1973. 215 с.

*Алишев С.Х.* Исторические судьбы народов Среднего Поволжья (XVI – нач. XIX в.) // Все об истории Казани. Казань: Раннур, 2005. С. 213–385.

*Алишев С.Х.* Казань и Москва: Межгосударственные отношения в XV–XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 160 с.

*Алишев С.Х.* Каһарман бабайлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 126 б.

*Алишев С.Х.* Население Казанского и Золотоордынского государств // *Алишев С.Х.* Все об истории Казани. Казань: Раннур, 2005. С. 71–96.

*Алишев С.Х.* Отдел истории Института истории АН РТ в 1989–1998 гг. // *Алишев С.Х.* Историки. Татарский народ / ред.: Р.У. Амирханов, И.К. Загидуллин. Казань: Форт-Диалог, 2000. С. 24–25.

*Алишев С.Х.* По следам минувшего. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 128 с.

*Алишев С.Х.* Присоединение народов Среднего Поволжья к русскому государству // Татария в прошлом инастоящем: сб. ст. / редкол.: М.К. Мухаррямов, З.И. Гильманов, К.А. Назипова; КФ АН СССР. ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова. Казань, 1975. С. 172–185.

*Алишев С.Х.* Среднее Поволжье в XVI – первой половине XIX в. (о прогрессивном характере совместной жизни народов): автореф. дис. … д-ра ист. наук. М., 1989. 30 с.

*Алишев С.Х.* Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа (II половина XVI–XVIII вв.) / науч. ред. И.Р. Тагиров. Казань: Фэн, 1999. 158 с.

*Алишев С.Х.* Татар тарихчылары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 206 б.

Воззвания и переписка вожаков пугачевского движения в Поволжье и Приуралье / сост. и ред.: С.Х. Алишев, Р.В. Овчинников, М.А. Усманов и др. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. 463 с.

*Галлям Р.Г.* Очерк жизни и творчества // Сәлам Хатыйб улы Алишев: Салям Хатыпович Алишев. Библиография. Казань: «ФОРТ-ДИАЛОГ», 1999.

*Гобәйдуллин Г.* Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма әсәрләр / китапны төзүче, текст, искәрмә, сүзлек һәм исемнәр күрсәткечен әзерләүчеләр С.Х. Алишев, И.А. Гыйләҗев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 334 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. Т. 7. Тарихи хезмәтләр (1911–1927) / томны төзүче, текст, искәрмә, сүзлек һәм исемнәр күрсәткечен әзерләүче С.Х. Алишев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 537 б.

История Казани: в 2 т. Т. 1 / Редкол.: Я.Г. Абдуллин, С.Х. Алишев, З.И. Гильманов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. 352 с.

*Насыри К.* Избранные произведения / сост. С.Х. Алишев, М.В. Гайнутдинов, Х.Ш. Максутов. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. 255 с.

*Һади Атласи.* Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы / төз., кереш сүз, искәрмәләр һәм белешмәләр авт., ред. С.Х. Алишев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 448 б.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Исламны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре.*

УДК 94(47)

***Ф.М. Солтанов***

# ГАЛИМ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ: ЯХЪЯ АБДУЛЛИН

Статья посвящена освещению жизненного пути известного татарского философа и общественного деятеля Я.Г. Абдуллина. После окончания Великой Отечественной войны бывший фронтовик занимал ответственные партийные посты в Казанском городском комитете партии. В 1959 г. по собственному желанию перешёл на преподавательскую работу, в 1978 г. успешно защитил докторскую диссертацию на тему «Социально-философская характеристика татарской просветительской мысли». Его научная деятельность связана с Институтом языка, литературы и истории, где он работал с 1971 года: заведующий отделом, заместитель директора, директор (1982–1986), с 1986 года главный научный сотрудник. С 1997 года главный научный сотрудник Института истории Академии наук РТ. В публикации повествуется о научном вкладе Я.Г. Абдуллина в развитие гуманитарных знаний и раскрывается его роль в формировании научного направления по изучению истории татарской общественной мысли.

**Ключевые слова**: Я.Г. Абдуллин, гуманитарные знания, наука в Татарстане, татарская общественная мысль, просветительское движение, татарское национальное движение.

The article is devoted to the life path of the famous Tatar philosopher and public figure Ya.G. Abdullin. After the end of the great Patriotic war, the former front-line soldier held responsible Party positions in Kazan and at the regional Party Committee. In 1959 at his own request he moved to teaching in 1978, he successfully defended his doctoral dissertation on the topic "Socio-philosophical characteristics of Tatar enlightening thought". His scientific activity is connected with the Institute of Language, Literature and History, where he worked since 1971: head of the department, Deputy Director, Director (1982–1986), since 1986 chief researcher. Since 1997 he has been a chief researcher at the Institute of History of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan. The publication tells about his scientific contribution to the development of humanitarian knowledge and reveals the activities for the formation of a scientific direction for the study of the history of Tatar social thought.

**Keywords:** Ya.G. Abdullin, Humanities, science in Tatarstan, the Tatar social thought, educational movement, tatar national movement.

«Татар әлегә яшәвен дәвам итә. Ләкин йокымсыраган хәлдә. Уяналмый азаплана. Әй, уятасы иде аны һәм үзенең мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә канатландырасы иде. Моның өчен анын аңына милләт идеясен тирән сеңдерәсе иде». Моннан 15 ел элек язып калдырылган бу җан авазына тиң сүзләр татар халкының аянычлы язмышын, үткән тарихи юлын һәм бүгенге хәлен тирән белгән, аның киләчәген бәхетле итеп күрергә теләгән, шул максатка булдыра алганча үзеннән өлеш кертергә тырышкан шәхескә – күренекле татар галиме, фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр

академиясенең шәрәфле әгъзасы, ТАССР, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге бүләк лауреаты, Бөек Ватан сугышы ветераны Яхъя ага Абдуллинга карый. Исән булса, аңа 2025 елда 105 яшь тулыр иде.

Яхъя ага 1920 елның 9 гыйнварында Татарстанның хәзерге Теләче районындагы гүзәл Макса елгасы буенда урнашкан борынгы татар авылы Олы Кибәхуҗада дөньяга килә. Нәсел җепләренә кагылып: «Безнең нәсел чыгышы белән Олы Кибәхуҗадан түгел. Миңа билгеле булган иң тәүге бабам Бикуш исемле. Ул чыгышы белән Теләчедән көнбатыштарак урнашкан Кукчә авылыннан. Күрәсең, укыган кеше булгандыр. Аны инде чукындырылган Олы Кибәхуҗа халкы балаларга ислам сабагы укытырга чакырып китертә... Бикуштан соңгы бабам Җәгъфәр исемле була. Аннан соңгысы Бикбау. Бикбаудан соңгы бабам Биктимер бик зирәк кеше була. Бу бабам узган гасырның урталарында (XIX гасыр) официаль рәвештә исламга кайту өчен күтәрелгән көрәшнең уртасында була һәм җәзасын да берәгәйле ала... Әтием Габдулла – 1885 елда, әнием Хәнифә 1886 елда туганнар. Һәр икесе дә хәтеремә гадел, инсафлы, эшчән, тырыш кешеләр булып кереп калганнар. Әтием бик туры сүзле иде. Аны, авыл мәктәбендә башлангыч белем алганнан соң, Казаклардагы җәдиди мәдрәсәгә укырга бирәләр. Ул анда 7 ел буе белем туплый. Тарихтан, җәгърафиядән, табигать фәннәреннән яхшы хәбәрдар иде. Дини тәгълиматны да тирән үзләштергән була», – дип яза ул [Абдуллин, 2005, б. 10–12].

Яхъя 6 яшендә мәктәп бусагасын атлап керә, 16 яшеннән район газетасында техник сәркатип буларак хезмәт юлын башлый, комсомол сафына баса, 1938 елда Алабуга шәһәрендәге Сәяси агарту техникумына (тиздән ул Республика сәяси агарту мәктәбе дип атала башлый) имтихан тота, аның комсомол комитеты сәркатибе итеп сайлана, партиягә алына; 1940 елда армиягә чакырыла, башта радистлар мәктәбенә, аннары Брянск хәрби-сәяси училищесына җибәрелә. Бөек Ватан сугышында катнаша, легендар 62 нче армия сафларында Сталинградны саклый, каты яралана, үз теләге белән тагын фронтка китә. Ленинград шәһәрен чолганыштан коткаруда, Балтыйк буе илләрен, Польшаны азат итүдә, Берлинны штурмлауда катнаша. Бу чакларны искә төшереп: «Күпне күрдем, күпне ишеттем», – дип яза Яхъя абый.

Сугыштан кайткач, 1959 елга кадәр Казанда партия эшендә була, 1949 елда партия өлкә комитеты каршындагы ике еллык республика партия мәктәбен тәмамлый, Казан юридик институтына укырга керә, 1953 елда Мәскәүгә Иҗтимагый фәннәр академиясенең Дәүләт һәм хокук бүлегенә «Фәлсәфә тарихы» белгечлегенә аспирантурага имтихан тота, 1957 елда янәдән Казанга кайта һәм Казан шәһәр партия комитетының идеология эшләре буенча секретаре итеп рәсми төстә сайланып куела. 1959 елда үз теләге белән Казан ветеринария институтына өлкән укытучы булып күчә, доцент, кафедра мөдире вазифаларын башкара, фәнгә тартыла. 1971 елда ул үзенең язмышын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты (ТӘһТИ)

белән бәйли: башта фәнни хезмәткәр, сектор мөдире, аннары институт директорының фән буенча урынбасары, институт директоры дәрәҗәсенә күтәрелә. 1986 елдан, пенсиягә китү сәбәпле, ТӘһТИдә, аннан соң Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында гомеренең соңгы елларына кадәр диярлек баш фәнни хезмәткәр, фәнни консультант булып эшли. Болар – Яхъя аганың тормыш юлына караган кыскача мәгълүматлар.

Яхъя ага – фәнгә чагыштырмача соң килгән шәхес. Ул фәнгә беренче адымын Мәскәүдә Иҗтимагый фәннәр академиясендә укыганда ясый: «Каутскийның дәүләт теориясен тәнкыйтьләү» («Критика теории государства Каутского») темасына кандидатлык диссертациясе яза һәм, аны 1957 елда уңышлы яклап, фәлсәфә фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек була. Аның фән дөньясында чын мәгънәсендә галим булып танылуы, һичшиксез, татар фәлсәфи һәм иҗтимагый фикере тарихына, шул исәптән, татар мәгърифәтчелеге һәм җәдитчелек мәсьәләләре, күренекле татар мәдәнияте эшлеклеләренең дөньяга карашларын тикшеренүгә караган хезмәтләренә бәйле.

Ул – үткән гасырның 70 нче елларында, бу өлкәдә сәяси күзлектән чыгып караганда яңалык кертү гаять кыен булган заманда, үз сүзен әйткән кеше. Барыннан да элек, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Ш. Күлтәси, Г. Утыз Имәни, Х. Фәезханов, К. Насыйри кебек татарның күренекле тарихи шәхесләренең мирасын өйрәнеп, аларның татар иҗтимагый фикерендә тоткан урыннары хакында җитди хезмәт бастырып чыгара алды, бу мирасны булдыра алганча пропагандалады. Әлеге тикшеренүләр нәтиҗәләре аның 1976 елда дөнья күргән һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан бик җылы кабул ителгән «Татар мәгърифәтчелеге фикере» [Абдуллин, 1976] исемле монографиясендә чагылыш тапты, 1978 елда СССР Фәннәр академиясенең Фәлсәфә институтында «Татар мәгърифәтчелеге фикеренә социаль-фәлсәфи бәяләмә» [Абдуллин, 1978] темасына уңышлы якланган докторлык диссертациясенә нигез булып торды. «Татар мәгърифәтчелеге фәлсәфәсе, – диелә хезмәттә, – гәрчә дөньяга дини-идеалистик караш белән араны кискен рәвештә өзә алмаса да, рационалистик фәлсәфә булды, ул бер очракларда пантеизм, икенче очракларда деизм белән бәйләнгән иде һәм, дөньяга прогрессиврак караш буларак, Урта гасырлар иррационализмына һәм мөселман схоластикасына каршы торды. Табигатьне, илаһи асылны пантеистик һәм деистик рухта аңлату дөньядагы әйберләрне һәм күренешләрне аларның үз табигатеннән һәм эчке закончалыкларыннан чыгып тикшерүгә һәм аңлатуга зарури алшарт булды» [Абдуллин, 1978, б. 143]. Монографиянең тагын бер үзенчәлекле һәм отышлы ягы шунда, галим, фәлсәфәгә хас төп ысулларның берсен кулланып, татар рухи мирасының тарихи яшәеш, тормыш итү рәвеше, милли мәдәният белән бәйлелеген уңышлы фактик материаллар нигезендә күрсәтә алуга иреште.

Төркиядә яшәүче танылган татар галиме Надир Дәүләт Яхъя аганы «татар мәгърифәтчелеген дөньяга ачкан галим» дип атады һәм,

хезмәтне югары бәяләп, үзенең «Рәсәй төркиләренең милли көрәш тарихы (1905–1917)» [Devlet, Nâdir, 1985) исемле китабында чыганак буларак куллануын ассызыклады. Америка Кушма Штатларында чыга торган «Slavie Review» журналы шулай ук хезмәтне «бик югары һәм тетрәндергеч эчтәлеге этник үзенчәлекне яклау өчен язылган», дип бәяли [Slavie Review, 1982]. Вашингтонда чыгып килгән икенче бер «Problems of Communism» басмасы: «Китапның нәшер ителүе СССР милләтләренең тарихын объектив өйрәнү тенденциясе дәвам итүгә өметләндерә», дип белдерә [Problems of Communism, 1977]. Фәлсәфәче галимнәр К.Ф. Фасеев [Фасеев, 1977], Р.Р. Мәүләтов [Мавлютов, 1977] шулай ук әлеге хезмәтне җитди фәнни тирәнлек белән сугарылган һәм җентекле язылган эш дип бәялиләр, аның татар мәгърифәтчелеге фикерен өйрәнүгә әһәмиятле яңа өлеш кертүен билгелиләр. Китапка хәзерге көнгәчә, классик төпле хезмәт буларак, ихтыяҗ зур.

Яхъя аганың тагын бер җитди фәнни кыюлыгы булып җәдитчелеккә карата моңа кадәр рәсми яшәп килгән уй-фикерне үзгәртүгә нык өлеш керткән эшчәнлеге тора. Аның «Джадидизм, его социальная природа и эволюция» («Җәдитчелек, аның социаль табигате һәм эволюциясе») [Абдуллин, 1979] исемле күләмле мәкаләсе фәндә яңа юнәлеш буларак кабул ителде. Фәлсәфәче галим җәдитчелекне, башкалардан аермалы буларак, «җәдитчелек, панисламчылык кебек үк, милли изүгә каршы протест һәм гасырлардан килгән артталыкны бетерүгә омтылышны гәүдәләндерде», – дип язып чыкты һәм аны бербөтен идеологик агым итеп күрсәтте, татар мәгариф системасын яңа баскычка күтәрүдә тоткан ролен билгеләде [Абдуллин, 1979, б. 95]. Озак еллар мәгърифәтчелек мәсьәләләрен теге яки бу дәрәҗәдә өйрәнгән атаклы әдәбият галиме Ибраһим Нуруллин Я. Абдуллинның әлеге мәкаләсен уңай бәяләп, автор «үзеннән элгәреләргә тиешле бәясен бирү һәм казанышларына таяну белән бергә, алга яңа адым ясый, күп кенә бәхәсле мәсьәләләргә ачыклык кертә алган. Барыннан да элек авторның җәдитчелекне аның үсеш-үзгәреш процессын күздә тотып тикшерүе, 1905 елгы революциягә (төгәлрәк әйтсәк, 1903 елга) кадәрге хәле белән Беренче рус революциясеннән соңгы күренеше арасына принципиаль чик уздыруына бәйләнгән. Баштагы чорында җәдитчелек тормыштагы һәм идеологиядәге уртагасырчылык калдыкларына каршы юнәлгән гомуммәгърифәтчелек хәрәкәтенә кайтып кала. 1905 елгы революциядән соң инде ул буржуаз-милләтчелек хәрәкәтенә әверелә... Фикер йөрткәндә ул "әйе-юк" принцибына түгел, бәлки чын мәгънәсендә диалектика законнарына таянып эш итә, тарихчылык принцибын эзлекле рәвештә тормышка ашыра. Мәкалә фактик материалга бай. Автор ясаган нәтиҗәләр шул материаллардан үсеп чыга», дигән фикерне алга сөрә [Социалистик Татарстан, 1980]. Мондый караш җәдитчелекнең башка төрки халыклар тарихында да тирән эз калдыруын уңай бәяләргә этәргеч бирә, бу хакта Ташкентта чыгып килгән «Звезда Востока» журналы: «Татар философы Я.Г. Абдуллинның "Җәдитчелек, аның социаль табигате һәм эволюциясе"

дигән хезмәтен аерым билгеләп үтәргә кирәк», дип искәртә [Звезда Востока, 1990, с. 141]. 1998 елда бу мәкалә тулыландырылып, аерым китапчык булып нәшер ителде [Абдуллин, 1998].

Тагын шунысын аеруча ассызыклап үтәргә кирәктер: Яхъя ага үз тикшеренүләрендә исламият, аның татар мәдәни тормышында тоткан урыны хакындагы мәсьәләләрне гел күз уңында тотты, аларга тарихи-фәлсәфи анализ бирде, үз фикерләрен төрле хезмәтләрендә курыкмыйча чагылдыра алды, халыкка җиткерергә ашыкты. Аның тырышлыгы белән Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәте әзерләнде һәм өлешчә, бер том булып басылып чыкты [Мәрҗани, 1989]. Бу шул чор өчен бик зур вакыйга булды.

Һәр эштә, ә фәндә исә бигрәк тә, галимнең абруе һәм дәрәҗәсе аның эшен дәвам итәрлек яшь алмаш әзерләп калдыруыннан, ягъни үз фәнни мәктәбен булдыруыннан чыгып билгеләнә. Яхъя ага бу юнәлештә дә бик уңышлы эш алып барды, үзенә булдыклы аспирантлар туплый алды, аларны фәндә һәм тормышта кеше итәргә тырышты. Фәлсәфә фәннәре докторы Фәрит Солтанов, фәлсәфә фәннәре кандидаты, сәяси фәннәр докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин, фәлсәфә фәннәре кандидатлары Рәшит Әмирханов, Тәфкил Камалов, Мансур Зарипов, Ләйлә Алмазова, Айдар Хәйретдинов, Гөлүсә Галиәхмәтова, тарих фәннәре кандидатлары Рафаил Мөхәммәтдинов, Фәридә Гаффарова, Мөнир Йосыпов – барысы да аның укучылары. Моннан тыш, Яхъя ага кул астында иҗтимагый фикер тарихы бүлегендә күренекле галимнәрдән академик Әбрар ага Кәримуллин, фәлсәфә фәннәре докторы Айдар Юзиев, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Әнвәр Хәйри, филология фәннәре докторы Әмир Мәхмүтов, филология фәннәре кандидаты Фәүзия Сәгъдиева дустанә бер коллектив булып эшләде. Яхъя аганың шәкертләре хәзергесе көндә төрле фәнни оешмаларда, югары уку йортларында үз белгечлекләре буенча хезмәт куя.

Я. Абдуллин яхшы оештыручы буларак та зур ихтирам яулады. Гадилеге, гаделлеге, эш өчен янып-көеп йөрүе күпләрне үзенә тартты. Институт директоры буларак, четерекле мәсьәләләрне күтәреп чыгудан да курыкмады. Әйтик, ул җитәкчелек иткән елларда татар әдәбияты тарихын өйрәнү һәм бу тарихның 5 томлыгын хәзерләү буенча зур эш башкарылганда, бу мирас тирәсендә башкорт галимнәре бәхәс куертып җибәрә. Әлеге уңайдан, Яхъя ага башлангычы белән СССР Фәннәр акдемиясенең Әдәбият институтында, ике якны чакырып, зур сөйләшү уздырыла, ул анда хәзерлекле зур делегация белән бара, ике тапкыр чыгыш та ясый. Шушы җәһәттән үзенең «Үткәннәр һәм уйланулар» дигән китабында ул: «Бәхәстә өстенлек, хаклыкның безнең якта булганлыгы ярылып ята иде. Мәскәүлеләр дә чыгыш ясадылар. Әмма аларның чыгышларыннан кемнең дә булса хаклыгын раслау, дөреслекне табарга тырышу теләге булмаганлыгы күренеп тора иде. Аларга дөреслек түгел, татар белән башкортның сугышып яшәве кирәк. Мәскәү өчен шул мөһим, шул файдалы. Ә соңыннан мин бу очрашуга хәзерләгән белешмә нигезендә үзебезнең мираска

хакыбызны раслап мәкалә яздым. Ул башта «Казан утлары»нда, соңыннан Төркиядә дөнья күрде», – дип искә ала [Абдуллин, 2005, б. 175]. Шундый ук хәл этник чыгыш мәсьәләсендә чувашлар белән килеп чыга, ләкин проблема шулай ук, Мәскәү тарафыннан дөреслекне табуга корылмаганга, чишелми, элеккечә кала [Абдуллин, 2005, б. 175–176].

Яхъя ага үз халкын, аның гореф-гадәтләрен, мәдәниятен бик тә ярата иде, ул милләт белән бергә, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен янып яшәде; шушы максаттан чыгып, милләт язмышына битараф булмаган укучыларга атап, «Милләт язмышы: уйланулар» [Абдуллин, 1999] исемле махсус китабын тәкъдим итте. Яхъя аганың үз шәкертләре күңеленә салган милли тойгы-хисләре узган гасырның 80–90 нчы елларында ургылып бәреп чыкты, ул оештырган һәм җитәкләгән бүлек хезмәткәрләренең төп өлеше җәмгыятьтә кабынып киткән татар иҗтимагый хәрәкәтендә, татар халкының милли бәйсезлеге, Татарстан Җөмһүриятенең мөстәкыйльлеге өчен көрәштә алгы сафларда булды; аларның милли оешмалардагы иҗтимагый эшчәнлекләре, массакүләм мәгълүмат чаралары аша татар халкының тарихы, теле, мәгарифе һәм мәдәнияте, дәүләтчелеге һәм бүтән милли мәнфәгатьләре турында язган мәкаләләре һәм чыгышлары, һичшиксез, эзсез калмагандыр. Яхъя ага, инде олы яшьтә булуына карамастан, үзе дә милли хәрәкәттән читтә тормады.

Берничә саллы монография, 250 дән артык фәнни, фәнни-популяр мәкаләләр, җыентыклар авторы Я. Абдуллин бигрәк тә Теләче төбәгенең патриоты, бер үк вакытта горурлыгы да, булды. Ул туган ягына һәм авылына кайтып йөрде, араларны өзмәде. Вафатыннан соң, васыятен үтәп, район китапханәсенә аның гомере буена тупланган, меңәрләгән китапны үз эченә алган шәхси китапханәсе тапшырылды. Район җитәкчелеге һәм халкы да үз якташын гел зурлап килде һәм хәзер дә зурлый: Теләченең яңа бер урамына аның исеме бирелде, Олы Кибәхуҗада туганы Мисүәр Исмәгыйлев тырышлыгы белән тантаналы төстә «Яхъя чишмәсе» ачылды. Ел саен, Яхъя аганың туган көненә туры китереп, район күләмендә мәктәп укучылары арасында «Яхъя укулары» уза, районның төбәк музеенда аның шәхси әйберләре саклана. Шунысы бәхәссез: туган җирең халкы әгәр сине танымаса, син әллә нинди мактаулы исемнәр йөртсәң дә, шәхес буларак тарихта озак кала алмыйсың, синең кадерең булмый. Яхъя ага бу яктан бик бәхетле булды, ул үзе чәчкән һәм үстергән яхшылыкларның әҗерен күрә алды, аның сикәлтәле тормыш юлларын, милләт язмышына битарафлык күрсәтмичә, горур узуы күпләр өчен үрнәк булырлык.

## Әдәбият

*Devlet, Nâdir.* Rusya Türklerinin millî mücâdele tarihi, (1905–1917). Ankara: Türk Kültürünü Araştırma enstitüsü, 1985. 350 s.

Problems of Communism. 1977. V. 28. №5–6. P.28.

Slavie Review. 1982. V. 40. № 4. P.635.

*Абдуллин Я.Г.* Джадидизм среди татар: возникновение, развитие, историческое место. Казань: Иман, 1998. 44 с.

*Абдуллин Я.Г.* Джадидизм, его социальная природа и эволюция // Из истории татарской общественной мысли. Казань: Казанский филиал АН СССР, 1979. С. 91–117.

*Абдуллин Я.Г.* Милләт язмышы: уйланулар. Казан: «Фән»,1999. 317 б.

*Абдуллин Я.Г.* Социально-философская характеристика татарской просветительской мысли: дис. ... д-ра филос. наук. М., 1978. 464 с.

*Абдуллин Я.Г.* Татарская просветительская мысль (социальная природа и основные проблемы). Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. 320 с.

*Абдуллин Я.Г.* Үткәннәр һәм уйланулар... Казан: Татарстан Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2005. 317 б.

Звезда Востока. 1990. № 9.

*Мавлютов Р.* Поборники просвещения // Наука и религия. 1977. № 3. С. 94–95.

*Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 414 б.

Социалистик Татарстан. 1980. 27 февраль.

*Фасеев К.Ф.* Рецензия на книгу Я.Г. Абдуллина «Татарская просветительская мысль» // Вопросы философии. 1977. № 2.

***Солтанов Фәрит Мирза улы,***
*фәлсәфә фәннәре докторы*
*(Казан шәһәре)*

УДК 94(470.41)

*Ә.Г. Галләмова*

# МИДХӘТ КӘРИМ УЛЫ МӨХӘРРӘМОВ: КӨРӘШЧЕ, ГАЛИМ, ӘЙДАМАН

Настоящая статья посвящена жизни и деятельности влиятельного руководителя, успешно возглавлявшего Казанский Институт языка, литературы и истории АН СССР в течение 18 лет (1963–1982) – доктора исторических наук, профессора, заслуженного деятеля науки ТАССР (1972), РСФСР (1982), кавалера пяти орденов: Ленина, Отечественной войны I и II степеней, дважды – Красной Звезды Мидхата Каримовича Мухарямова, автора более 200 публикаций, среди которых 16 монографий. Автор отмечает, что жизнь крупного татарского учёного-гуманитария приходится на советскую эпоху. Ровесник СССР, он всего на два года пережил его. М.К. Мухарямов относился к поколению историков, которые сформировались после массовых репрессий 1930-х гг., в результате которых корпорация татарской гуманитаристики была изрядно «зачищена». В историческую науку Мидхат пришёл после фронта, где он служил в самый тяжелый для страны период. Серьёзное ранение, в результате которого танкист, гвардии капитан М. Мухарямов потерял ногу, перечеркнуло его детские мечты о военной карьере. Но инвалидность не сломила сильного, харизматичного 23-летнего фронтовика. Он поступил и с отличием закончил Казанский юридический институт. С послевузовского периода жизнь М.К. Мухарямова напрочь связывается с исторической наукой, сначала – аспирантура, затем уверенное восхождение по лестнице научной карьеры историка: учёный секретарь, заведующий отделом сектора истории, директор Института языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова, который при нём стал одним из самых мощных центров гуманитаристики Татарской АССР. В статье жизнедеятельность Мидхата Каримовича характеризуется как пример высшего «пилотажа» в социальной самореализации личности своего времени, поэтому его вклад в науку оценивается автором по особым меркам.

**Ключевые слова:** советская историческая наука, Татарская АССР, советская интеллигенция, национальная культура, Институт языка, литературы и истории Казанского филиала АН СССР, Мидхат Каримович Мухарямов.

This article is dedicated to the life and work of an influential leader who successfully headed the Kazan Institute of Language, Literature and History of the USSR Academy of Sciences for 18 years (1963–1982) – Doctor of Historical Sciences, Professor, Honored Scientist of the Tatar ASSR (1972), the RSFSR (1982), Cavalier of five Orders: Lenin, the Order of the Patriotic War of the 1st and 2nd degrees, twice – the Order of the Red Star Midkhat Karimovich Mukharyamov, the author of more than 200 publications, including 16 monographs. The author notes that the life of a major Tatar scholar and humanitarian falls on the Soviet era. Being the coeval of the USSR, he outlived it by only 2 years. M.K. Mukharyamov belonged to the generation of historians which was formed after the mass repressions of the 1930s, as a result of which the fellowship of Tatar humanities was pretty much “cleaned up”. Midkhat came to historical science after the front where he served during the most difficult period for the country. The tank crewman Guard Captain M. Mukharyamov was

badly wounded and lost his leg, which destroyed his dreams of a military career. But the disability did not break the strong, charismatic 23-year-old battle-front veteran. He entered Kazan Law Institute and graduated from it with honors. Starting from the postgraduate period the life of Midkhat Karimovich Mukharyamov was completely associated with historical science: first there was a postgraduate training program and then moving towards the scientific career of a historian: academic secretary, head of the historical department, and director of G. Ibragimov Institute of Language, Literature and History, under whom it became one of the most powerful centers of humanities in the Tatar ASSR. In the article the life of Midkhat Karimovich is characterized as an example of the highest "pilotage" in the social self-realization of the individual of his time therefore his contribution to science is assessed by the author by special standards.

**Keywords:** Soviet historical science, Tatar ASSR, Soviet intelligentsia, national culture, Institute of Language, Literature and History of the Kazan branch of the Academy of Sciences of the USSR, Midkhat Karimovich Mukharyamov.

Тарихчы, тарих фәннәре докторы (1964), профессор (1967), ТАССРның, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1972, 1982), биш: Ленин, I һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, ике тапкыр – Кызыл Йолдыз – орденнары кавалеры Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов 18 ел (1963–1982) дәвамында Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих институтын җитәкли.

Күренекле татар тарихчысы Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмовның тормышы Совет дәверенә туры килә. Татар гуманитаристикасын шактый «чистарткан» 1930 еллар массакүләм репрессияләреннән соң формалашкан галимнәр буынына карый ул. Беренче карашка, алдыбызга табигый сәләте, үҗәтлеге, харизмасы, совет чоры өчен дөрес килеп чыгышы аркасында гадәттән тыш карьера ясаган гади татар авылы егете язмышы килеп баса.

Мидхәт Кәрим улының әтисе совет чорында данга күмелгән Азин дивизиясендә хезмәт итә, Казанда Совет властен ныгытуда һәм шәһәрне Ак чехлардан азат итүдә катнаша. Әмма социаль лифт өчен иң уңышлы мондый позиция дә тормыш юлын «Кызыл келәм» буйлап җайлы гына узуны беркемгә дә гарантияләми.

Мидхәт Кәрим улының җитлегү чоры 1939 елда башланган Икенче бөтендөнья сугышының авыр сынауларына туры килә. Хәер, бу аның Кызыл Армия командиры булу турындагы балачак хыялын тормышка ашырырга ярдәм дә итә. 1940 елда 18 яшьлек Мидхәт, Казан элемтә техникумында укуын ташлап (1938 елда мәктәпне тәмамлагач шунда укырга кергән була), Сызрань танк училищесына курсант булып китә. Фронтка яшь танкист 1942 ел башында барып керә. Бу СССР өчен сугышның иң авыр чоры була.

«Аңа, авыр танклар ротасы командирына, күп нәрсәне узарга туры килә: җанны көйдерә торган чигенүләр, дошман белән өзлексез бәрелешләр, кышкы салкыннарда һәм җәйге челләдә, күзге яңгырлар астында һәм язгы өзеклектә озакка сузылган ялыктыргыч походлар...», дип телгә ала бу сәхифәләрне Р. Әмирханов [История...,

2012, б. 76]. 1942 елның сентябрендә, авыр бәрелештән соң, М. Мөхәррәмов, каты пешеп, госпитальгә эләгә, ләкин 1942 елның декабрендә яңадан сафка баса.

Курск сугышы вакытында ул элемтә офицеры булып хезмәт иткән корпус зур батырлыклар күрсәтә һәм гвардия корпусына әйләнә. Әмма 1944 елның гыйнварында гвардия капитаны М.К. Мөхәррәмовның героик юлы каты яралану сәбәпле өзелә, хәрби карьерасына нокта куела. Аны авыр хәлдә, озын-озак юллар үтеп, Ташкент госпиталенә китерәләр. Биредә аңа уң аягын ампутацияләү белән килешергә туры килә. Көч-хәл белән, гадәттән тыш үзсүзлелеге аркасында, ул табиблардан сул аягын кистерми кала. Яшәү теләге, китапларга мәхәббәт ахыр чиктә яраларны төзәтә.

Өйгә кайткач, 23 яшьлек Бөек Ватан сугышы инвалидының тормышында яңа этап башлана: ул 1945 елда Казан юридик институтына укырга керә һәм 1950 елда аны яхшы билгеләр белән тәмамлый. Студент еллары, тормышта гаять зур кыенлыкларга очравына карамастан, Мидхәт Мөхәррәмовның Казандагы интеллектуаль-гуманитар мохиткә килеп керүендә әһәмиятле урын тота. Уку отличнигы һәм студентларның фәнни конференцияләрендә актив катнашучы буларак уңыш казанып, хәтта ул вакытта республикада төп басма булган «Кызыл Татарстан» газетасы хәбәрчесе Ян Винецкийның каләменә эләгә: журналист «Красная Татария» газетасына аның турында мәкалә яза (1948, 1 февраль) [История..., 2012, б. 13].

Югары уку йортын тәмамлап, Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов тормышын тарих фәне белән бәйли, башта – аспирантура, аннары фәнни карьера баскычларыннан ышанычлы күтәрелү: гыйльми сәркатип, тарих секторы мөдире һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчесе. Ул елларда Институт Татарстан АССРның иң куәтле гуманитаристика үзәкләренең берсенә әверелә.

Мидхәт Кәрим улының тормышы һәм эшчәнлеге – ул дәвер өчен югары пилотаж үрнәге. Аның уңышларының нигезе, ничек кенә баналь яңгырамасын, дисциплиналы хезмәткә омтылышта була: аспирант елларында ук ул системалы һәм нәтиҗәле эш күрсәтә. Яшәү шартлары авыр булса да, кандидатлык диссертациясен М. Мөхәррәмов аспирантураны тәмамлаганда ук язып төгәлли һәм уңышлы яклап та чыга.

Фәнни оешманың җитәкчесе булгач та, ул туктаусыз эшләвен дәвам итә. Култык таяклары белән йөргән Мидхәт Кәрим улы, җитәкче вазифалары белән мәшгуль булуына карамастан, кабинет галиме булып китми: күп вакытын архивларда үткәрә, Казан авиация институтында укыта, Дәүләт музееның Гыйльми советы утырышларына йөри. Ул вакытта музейның фәнни хезмәткәре Клара Романовна Синицына аның революционерлар белән үткәрелгән очрашуларда актив катнашуын, бер генә чараны да калдырмавын искә ала [История..., 2012, с. 60–63]. Мидхәт Кәрим улы «Белем» җәмгыятендә лекцияләр

укый, республика журналлары редколлегиясе, Тукай премиясе комиссиясе әгъзасы була, берничә ел рәттән Казан Шәһәр советы депутаты итеп сайлана. Үзенең хезмәттә кайнау гадәтенә ул соңгы елларында да тугры калды. Авыртулар (фронт яралары кайтавазы) газаплый башлагач та, Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиев, Сталинның татар мәсьәләсенә мөнәсәбәте турында берничә тирән эчтәлекле мәкалә яза. Аларга галимнең совет чорының идеологик тыюлары аркасында дөньяга чыгарыла алмаган фикерләре дә кергән [Мухарямов, 2012].

Мидхәт Кәрим улының «Октябрь и национально-государственное строительство в Татарии» («Октябрь һәм Татарстанда милли-дәүләт төзелеше») һәм «Гражданская война в Татарии» («Татарстанда Гражданнар сугышы») китаплары басылып чыгу XX гасыр Татарстан тарихында зур вакыйгага әверелә. «Октябрь һәм Татарстанда милли-дәүләт төзелеше» монографиясенең әһәмиятен билгеләп, Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов болай дип яза: «Ул, асылда, Октябрь революциясе чорында татар милли-азатлык хәрәкәтендәге кайбер тарихи вакыйгаларга яңача бәя бирүгә (ул заман рөхсәт иткән күләмдә), сталинизм йогынтысында пәйда булган кайбер коточкыч тарихи бозулардан котылуга беренче җитди омтылыш иде» [История..., 2012, б. 69]. М.К. Мөхәррәмов хезмәтләрендә Россия инкыйлабы, аннан соң килгән Гражданнар сугышы чоры вакыйгаларын аңлату үзенчәлекләре аның коллегалары И.Р. Таһиров [История..., 2012, с. 33–35], Б.Ф. Солтанбәковның [История..., 2012, с. 37–44] да шундый ук бәяләре белән дәлилләнә. Үзенең автордашы, күренекле Россия тарихчысы А.Л. Литвинның: «Сугыштан инвалид булып кайткан кеше ничек башка сугышлар тарихын җентекләп өйрәнә алган?» – дигән соравына М.К. Мөхәррәмовның җавабы аның фәнни кызыксыну даирәсен аңлауга ачкыч була ала. Мидхәт Кәримовичның: «Бөек Ватан сугышында нәрсәләр яклаганымны һәм сугышлар булмасын өчен нәрсәләр эшләргә кирәклеген аңлыйсым килде», – дигән сүзләре бүген күңелләрдә аеруча көчле яңгыраш таба [История..., 2012, с. 45].

Сүзне дәвам итеп, Альтер Львовичның тагын бер күзәтүен телгә алып китү кызык булыр: «Ул бу турыда күптән хыяллана иде (сүз «Татарстанда мәдәни инкыйлаб. 1917–1937 еллар» күмәк китабында мәдәни төзелеш турында бүлек язу турында бара. («Культурная революция в Татарии». Казань, 1986). – *Ә.Г.*), мәдәният, мәгърифәт, җимерү түгел, төзү, барлыкка китерү турында язарга. Гражданнар сугышы турындагы күп кенә китаплар белән чагыштырганда, миңа ни өчендер М.К. Мөхәррәмов бу сугышны һәрвакыт шактый әрнү һәм җирәнү белән язган кебек тоела иде. Ул сугышта тәнне һәм җаннарны үтерүләрен, имгәтүләрен дәреслекләрдән түгел, тормышның үзеннән белә иде шул...» [История..., 2012, б. 47].

Бу сүзләр Мидхәт Кәрим улы күңелендәге гражданлык җаваплылыгы, тирән гуманлылык хисләре турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Совет чоры йомгакланганда, хәбәрдарлык тантана иткән

үзгәртеп кору чорында язылган соңгы хезмәтләренең берсендә ул Татарстан АССР мәдәниятендә башланган Яңарыш, Ренессанс турында, монда яшәгән халыклар милли сәнгатенең төрле тармакларындагы казанышларын җентекләп күзәтеп, сокланып сөйли.

Әлбәттә, совет иҗат интеллигенциясе эшчәнлеген регламентлаган катгый идеологик кысалар М.К. Мөхәррәмовның төп хезмәтләре эчтәлегенә дә тәэсир итми кала алмый. Шуңа да карамастан, аның биографиясендә аларның чикләреннән чыгу омтылышы факты киң билгеле. Бу хәл аның 1917 елгы революциядә милли азатлык хәрәкәтен яңача бәяләве уңаеннан КПССның Татарстан өлкә комитетына «келәмгә» чакырылу драматик вакыйгалары белән бәйле.

Мидхәт Кәрим улына үз фикерен СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында, үзенең «Октябрь и национальный вопрос в Татарии» («Октябрь һәм Татарстанда милли мәсьәлә») китабы буенча ике көнлек фикер алышуда якларга туры килә (бу җыелышны автор позициясен гаепләү өчен әзерләгән булалар). Мидхәт Кәрим улының, култык таягына таянып, күпсанлы аудитория алдында «Документлар шулай ди» дип кабатлап, үз эшен яклавы бу вакыйганың шаһитларына көчле эмоциональ тәэсир ясый [История..., 2012, б. 11].

Тарих секторы мөдире Х.Г. Гыймади белән бергә И. Сталинга язган хатында ул М. Вахитов турындагы мәкаләне Зур совет энциклопедиясенә урнаштыру кирәклеген аңлата. Шуны ассызыклыйсы килә, хат соңыннан сталинизм дип аталган елларда, илдә куркыныч рухи атмосфера хөкем сөргән вакытта языла. Ахыр чиктә, ул уңай нәтиҗә бирә. Озак фикер алышулардан соң, ортодоксаль идеолог булып танылган СССР Югары хакимияте вәкиле М.А. Суслов оештырган зур эксперт комиссиясе татар революционеры Мулланур Вахитов турындагы мәкаләне, дөрес, җитди төзәтмәләр белән, әмма энциклопедиядә калдырырга рөхсәт итә.

Әлбәттә, заманга бәйле, М.К. Мөхәррәмовка идеологик яктан чикләнгән шартларда эшләргә туры килә. Гыйльми хезмәтләрендә дә, совет фәнендә кабул ителгәнчә, текстның марксизм-ленинизм классиклары әсәрләреннән китерелгән өземтәләр белән чуарлануы, Бөек Октябрь инкыйлабын татар халкының бәхетле язмышына мөһим борылыш буларак яктырту – шул компромисснең чагылышы. Әмма шунысын таныырга кирәк, болар Мидхәт Кәрим улы ачыклаган кыйммәтле фактологик табышларны кабул итәргә комачауламыйлар.

Аның югары фәнни-тикшеренү культурасын аерым билгеләп үтәргә кирәк: моны хезмәтләрендә искәрмәләрнең күплеге, чыганакларга сакчыл мөнәсәбәте күрсәтеп тора.

Сәяси режимның җиңә алмаслык көчен аңлап, М.К. Мөхәррәмов үзенең хезмәттәшләрен дә вазгыять белән исәпләшергә өнди. Әйтик, Ә.Х. Борһанов үзенең инде телгә алынган истәлекләрендә М.К. Мөхәррәмовның Марат Габдерәсүл улы Мөлеков диссертациясеннән Вәисиләр хәрәкәте турындагы бүлекне, аның тарихын дөрес яктыртуга объектив мөмкинлек булмавын аек аңлап, төшереп

калдыру яклы булуы хакында яза. Ә.Х. Борһановның үзен дә докторлык диссертациясендә эсерларның һәм меньшевикларның сәяси язмышын аңлатуга бәйле артык кискен фикерләре белән хезмәтен куркыныч астына куюын искәртә. Тормыш кисәтүләрнең урынлы булуын раслый: Ә.Х. Борһановның оппоненты Мидхәт Кәрим улы уңай бәяләмә язган диссертациясе, расланмыйча, М. Горбачёв үзгәртеп коруларына кадәрге 30 елга фәнни әйләнештән алына [История..., 2012, с. 71, 72].

Үз чоры тарихчылары арасында галимнең оештыру эшчәнлеге гаять зур әһәмияткә ия була. 1963–1982 елларда 18 елдан артыграк ул аларның рәсми башлыгы булып тора, СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтын җитәкли. Хәзерге вакытта бу оешма дүрт институт булып яши һәм эшли: Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, А.Х. Халиков исемендәге Археология институты, М.Х. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты.

Совет җәмгыять белемендә бу чорны еш кына үсә барган торгынлык, консерватизм чоры дип атыйлар. Ләкин М.К. Мөхәррәмов җитәкләгән коллективның эшчәнлеге, әйтергә кирәк, бу билгеләмәгә туры килми: оешма әлегә кадәр әһәмияте югалмаган бай фәнни продукция әзерли.

1977–1981 елларда татар лингвистлары «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н 3 томда бастырып чыгаралар, «Хәзерге татар әдәби теле» басмага әзерләнә. 1970 елларның икенче яртысыннан башлап татар халкының классик мирасын әзерләү һәм бастырып чыгару буенча зур эш башкарыла: Г. Ибраһимовның – 8 томда, Г. Тукайның 1970 елларда – 4 томда, 1980 елларда – 5 томда, М. Гафуриның – 4 томда һәм М. Җәлилнең шулай ук 4 томда әсәрләре басылып чыга [Файзрахманов, 1989, С.109]. Институт археологлары тырышлыгы белән төбәкнең бербөтен борынгы тарихы тергезелә. 1980 елларда ТАССРның археологик картасын 6 томда бастырып чыгару археологларның мөһим казанышы була. 1967 елда татар халкы этнографиясе буенча Н. И.Воробьёв, Г.М. Хисаметдиновның «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» («Урта Идел һәм Урал буе татарлары») дигән зур гомумиләштерү сыйфатына ия хезмәте Мәскәүдә дөнья күрә [Татары..., 1967]. М.К. Мөхәррәмов заманында, социаль-сәяси шартлар каршы килеп торган бер вакытта, иҗтимагый фикер (фактта: ислам гыйлеме) бүлеге төзелә һәм Я. Г. Абдуллинның «Татарская просветительская мысль» («Татар мәгърифәтчелек фикере») дигән бик әһәмиятле монографиясе дөнья күрә. Татар фольклорчылары тырышлыгы белән «Татар халык иҗаты» фәнни җыентыгының 12 томы нәшер ителә. Бу мисаллар, шиксез, М.К. Мөхәррәмов җитәкчелегендә ТӘһТИ коллективының тотрыксыз дөньяда татар халкының этник үзаңын саклап калудагы ныклыгын раслый.

Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов шәхсән үзе Институт хезмәтләренең башкаладагы дәрәҗәле «Наука» нәшриятында басылуы өчен

күп көч куя. Мәскәүдә булганда ул, бу нәшриятка кереп, наширлек мәсьәләләрендә сөйләшүләр алып бара. Нәкъ менә шунда «История татарской советской литературы» («Татар совет әдәбияты тарихы», 1965), «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» («Урта Идел һәм Урал буе татарлары», 1967), «Современный татарский литературный язык» («Хәзерге татар әдәби теле», 1969), К.Ә. Нәҗипованың «Национализация промышленности в Татарии. 1917–1921» («Татар сәнәгатен халыкка кайтару. 1917–1921», 1976) монографиясе һәм тагын дүрт шәхси монография дөнья күрә.

М.К. Мөхәррәмов директор булган чорда ТӘһТИ фәнни хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүдә зур уңышларга ирешелә. 1964–1978 елларда гына да 10 кеше докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Бик еш Мидхәт Кәрим улына диссертацияләрне бәяләргә туры килә. Аның оппонент сыйфатында катнашуы яклауга чыгарылган фәнни эшнең сыйфат билгесе дә булып тора, Диссертация яклау советы утырышларындагы чыгышлары һәрвакыт принципиаль, эшлекле характерда була.

Шул ук вакытта Мидхәт Кәрим улы кеше хәленә керә белә торган җитәкче иде. Ул яшь хезмәттәшләренә сүз һәм эш белән ярдәм итәргә тырышты. Бу хакта Клара Романовна Синицына, Тәэминә Әхмәт кызы Биктимерова аеруча җылылык белән искә алалар. М.К. Мөхәррәмовның яшь талантлы кадрларга карата сакчыл мөнәсәбәте турында Равил Госман улы Әмирханов мисалы да сөйли: ул, фатиры булмау сәбәпле, Яр Чаллыга күченергә җыена. Бу хакта белгәч, Мидхәт Кәрим улы КПСС өлкә комитеты аша мәсьәләне хәл итә һәм галимне Институтта калдыруга ирешә.

М.К. Мөхәррәмов белән шәхси аралашуыбыз еш булмады: аспирантурага керү имтиханы тапшыру һәм Гыйльми совет утырышларында ел саен үткәрелә торган аспирантлык хисаплары белән чикләнә диярлек. Ул мондый чараларда һәрвакыт катнаша һәм кызыксыну күрсәтә иде. Беренче тәэсир – мин аны табигать тарафыннан иң матур сыйфатлар юмарт бүләк ителгән кеше буларак кабул иттем. Аның үз дәрәҗәсен белүе, аз сүзлелеге, зыялылыгы һәм нәзакәтлелеге, чын ир-атларга хас рухи көче күзгә ташланып тора иде.

Минем фикеремчә, Институтта эшлекле, иҗади, иптәшләрчә атмосфера хөкем сөрү – директорның зур казанышы, ул билгеләгән юл булды. Озакка сузылмаса да, бергәләп эшләү дәверендә мин хезмәттәшләремнең М.К. Мөхәррәмовка ихтирамлы мөнәсәбәтен күзәттем, аларга карата, үз чиратында, җитәкче һәрвакыт зыялылык саклады.

Бик демократик рәвештә узган 60 яшьлек юбилее истә калган. Көне буе аның кабинетына бетмәс-төкәнмәс ташкын булып тарихчылар делегацияләре килә, алар юбилярны үзләренчә, ихластан котлыйлар. Аннары Татар кулинариясе йортында бик күңелле, кызыклы тостлар, шаяртулар белән үрелгән онытылмаслык кичә булды, анда Гыйльми совет әгъзалары һәм тарих бүлеге хезмәткәрләре, шул исәптән лаборантлар да чакырылган иде.

Мидхәт Кәрим улының тормышы турында уйланулар әлегә фәнни тикшеренүләрдә тиешле анализ тапмаган совет галиме образының бар катлаулылыгын аңлауга юл күрсәтә. Конформизм, идеологик толерантлык, битарафлык юнәлешендә формалашкан типажга М.К. Мөхәррәмовның үзгәртеп кору һәм сәяси плюрализм чорында хәбәрдарлык шлюзлары ачылуга ук милли тарихны анализлауда тотрыклы шаблоннардан арынуы һәм тарихи чыганакчылык белемендә аутсайдерга әйләнмәве ничектер тәңгәл килми. Бу хакта югарыда телгә алынган 1917–1918 еллардагы Татарстан социалист-мөселманнары, М. Вахитов, М.Х. Солтангалиев хакындагы мәкаләләр дә сөйли.

Мидхәт Кәрим улы лаеклы гомер кичерде. Безнең фикеребезчә, аның тормыш стратегиясен тирәнтен аңлауга Александр Кушнерның «Заманны сайлап алмыйлар: анда яшиләр һәм бакыйлыкка күчәләр / дөньяда теләнеп һәм үпкәләп йөрүдән дә зуррак явызлык юк» дигән шигъри юллары ярдәм итә ала. М.К. Мөхәррәмовның фәнни, һөнәри, шәхси уңышлары – барлык көчне намуслы нәтиҗәгә ирешүгә юнәлтеп тә, гамәлдәге иҗтимагый вазгыятьтә мөмкинлекләрнең чикләнгәнлеген аек аңлау белән бәйле. Ул гаҗәеп тирән акылга, гражданлык җаваплылыгына ия булып, тормышта яңаны тудыруга, иҗат итүгә, намус белән эшләүгә, укытуга хезмәт иткән зыялылар төркеменә керә. Шуның белән ул үзен белгән кешеләр арасында мәңге җуелмас абруй казанды.

**Әдәбият**

История. Профессия. Судьба. Памяти Мидхата Каримовича Мухарямова. Издание 2-е, доп. и доработ. Казань: Идель-Пресс, 2012. 184 с.

*Мухарямов М.К.* Левые социалисты-мусульмане Татарии в 1917–1918 гг.; Революционер-гуманист (к вопросу о партийности М. Вахитова); М.Х. Султан-Галиев о трех течениях общественно-политической жизни татар к февралю 1917 г.; В чем Сталин обвинял татар? // История. Профессия. Судьба... С. 94–102, 119–137, 149–158.

Татары Среднего Поволжья и Приуралья / отв. ред. Н.И. Воробьев, Г.М. Хисамутдинов. М.: Наука, 1967. 537 с.

*Файзрахманов Г.Л.* Развитие гуманитарных исследований в 40–80 годы: к 50-летию ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР // Великий Октябрь и некоторые вопросы формирования татарской социалистической нации. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1989. С. 96–122.

***Галләмова Әлфия Габделнур кызы,***
*тарих фәннәре докторы, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 94(47)

***Ф.Ш. Хуҗин***

# ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТАРИХ ИНСТИТУТЫНДА ТАТАРСТАН АРХЕОЛОГИЯСЕ

Статья посвящена исследованию истории Татарстанской археологии, восстановление и развитие которой происходило в составе Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, отмечающем свой 85-летний юбилей. Автор акцентирует внимание на том, что этапным для развития археологии в Татарстане стало создание в 1939 г. Института языка, литературы и истории, вошедшего в 1946 году в состав Казанского филиала АН СССР; по инициативе Н.Ф. Калинина в ИЯЛИ КФАН СССР была создана археологическая группа в составе сектора истории, проводившая значительную часть археологических изысканий в республике и соседних регионах; в 1962 г. из сектора истории выделился сектор археологии и этнографии, который в 1986 г. был разделен на два самостоятельных отдела – археологии и этнографии. В успешном развитии данного исследовательского направления автор также отмечает особую роль профессора, члена-корреспондента АН РТ А.Х. Халикова, который долгое время (1965–1989 гг.) возглавлял отдел археологии, выражает мнение о том, что именно при нем произошло организационное оформление казанской школы археологии в Татарстане, сложился коллектив специалистов по древней и средневековой истории, профильных источниковедческих дисциплин, полевым изысканиям была подвергнута вся территория республики, были выработаны основные подходы к изучению древней истории региона. В 1995 г. отдел археологии был преобразован в Национальный центр археологических исследований. Научная новизна обзора заключается в систематизации деятельности Татарстанской археологии в целом.

**Ключевые слова:** археология, Н. Калинин, А. Халиков, Археологическая карта Татарстана, раскопы в Булгарах, раскопы в Билярах, раскопы в Казанском Кремле.

The article is devoted to the study of the history of Tatarstan archeology, the restoration and development of which took place as part of the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Tatarstan Academy of Sciences which celebrates its 85th anniversary this year. The author emphasizes that a milestone in the development of archeology in Tatarstan was the creation of the Institute of Language, Literature and History in 1939 which in 1946 became part of the Kazan branch of the USSR Academy of Sciences; on the initiative of N.F. Kalinin, an archaeological group was created at the Institute of Language, Literature and History of the Kazan Branch of the USSR Academy of Sciences as part of the history sector which carried out a significant part of archaeological research in the republic and neighboring regions; in 1962 the archeology and ethnography sector was separated from the history sector which in 1986 was divided into two independent departments – archeology and ethnography. In the successful development of this research area the author also notes the special role of Professor, Corresponding Member of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan A.Kh. Khalikov who headed the Department of Archaeology for a long time (1965–1989), the author expresses the

opinion that it was under him that the organizational formation of the Kazan School of Archaeology in Tatarstan took place, a team of specialists in ancient and medieval history, specialized source study disciplines was formed, the entire territory of the republic was subjected to field research and the main approaches to the study of the ancient history of the region were developed. In 1995 the archaeology department was transformed into the National Center for Archaeological Research. The scientific novelty of the review lies in the systematization of the activities of Tatarstan archaeology as a whole.

**Keywords:** archeology, N. Kalinin, A. Khalikov, Archaeological map of Tatarstan, excavations in Bulgars, excavations in Bilyars, excavations in the Kazan Kremlin.

Татарстан археологиясенең, күренекле галимнәр Н.Ф. Калинин һәм А.Х. Халиков исемнәрен йөртүче Казан археология мәктәбенең оешуы, археология фәненең ярты гасырдан артык, 1996 еллар уртасына кадәр дәвам иткән тотрыклы, алгарышлы үсеш чорлары, борынгы һәм Урта гасырлар тарихын өйрәнү юлында ясалып, бөтен Россиядә һәм чит илләрдә танылу алган олы ачышлары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты белән бәйләнгән.

Дөрес, Татарстан археологиясенең башлангыч чорлары турында сүз барганда 1878 елда Казан университеты каршында оешып, 1930 елларга кадәр эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлеген дә онытырга ярамый. Татарстан җирлегендә беренче казу эшләрен нәкъ менә шушы җәмгыять әгъзалары – күбесе профессиональ археологиядән ерак торган кешеләр башлап җибәрәләр. С.М. Шпилевский, А.Ф. Лихачёв, А.А. Штукенберг, Н.Ф. Высоцкий, П.А. Пономарёв, Н.А. Толмачёв, В.К. Савельев, Г. Әхмәрев, В.Ф. Смолин, М.Г. Худяков кебек галимнәрнең Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «Хәбәрләре»ндә басылган фәнни мәкаләләре, казу эшләре вакытында, ә башлыча исә очраклы рәвештә табылган борынгы әйберләр коллекцияләре Татарстан археологиясе үсешендә нигез ташлары ролен үтәделәр. Мәсәлән, А.А. Штукенберг һәм Н.Ф. Высоцкий таш, бронза, элгәреге тимер гасырында яшәгән кешеләрнең беренче торулыкларын табып тикшерделәр, В.Ф. Смолин Чувашиянең Абашево авылы янында урнашкан борынгы курганнарны казып, фәндә моңа кадәр билгеле булмаган яңа археологик культура ачты. Профессор С.М. Шпилевскийның «Казан губернасында борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар истәлекләре» дигән фундаменталь хезмәте (1877) әле бүген дә үзенең фәнни кыйммәтен югалтмады, 2012 елда аның репринт басмасы дөнья күрде.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң фәнне оештыру системасында яңа үзгәрешләр килеп чыга. ТАССР Мәгариф комиссариаты каршында төзелгән Гыйльми үзәк (1921–1930), Татарларны өйрәнү Гыйльми җәмгыяте (1923–1929), Татарстанны өйрәнү җәмгыяте (1928–1930) басмаларында сирәк кенә булса да археология һәйкәлләрен өйрәнү һәм аларны саклау мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр басыла.

Шул ук вакытта А.С. Башкиров, И.Н. Бороздин, Н.Ф. Калинин кебек галимнәр тарафыннан Биләр, Җукәтау, Казан Кремле, Иске Казан ише болгар-татар калаларында зур булмаган, рекогносцировка характерындагы казу эшләре үткәрелә.

1933 елда СССР Фәннәр академиясенең Матди культура тарихы институты (Институт истории материальной культуры) оештырган археология экспедициясе Дәүләт тарих музее һәм Татарстан Үзәк музее белән бергә республикабызда казу эшләре башлап җибәрә. Тиздән атаклы болгарчы галим булып танылачак А.П. Смирнов җитәкчелегендәге экспедиция биш ел буена Сувар шәһәрлеген тикшерә, 1938 елда исә киң масштаблы һәм системалы казу эшләре Болгарда башланып китә. Бу эшләрдә Татарстан Үзәк музее хезмәткәрләре Н.Ф. Калинин, А.М. Ефимова, О.С. Хованская һәм З.А. Акчурина актив катнашалар.

1939 елда оешкан Тел, әдәбият фәнни тикшеренү институтында беренче археолог – Казан археология мәктәбенә нигез салучы олы галим Николай Филиппович Калинин 1942 елда эшли башлый, 1951 елда ул үзенең талантлы шәкерте А.Х. Халиковны лаборант сыйфатында эшкә урнаштыра, шулай итеп, институтның тарих секторында ике хезмәткәрдән торган археология «төркеме» барлыкка килә.

***Тарих секторы составындагы археология төркеме*** тиздән Т.А. Хлебникова[1], Һ.В. Йосыпов[2], В.Ф. Генинг[3] кебек яшь археологлар белән тулыландырыла.

1945 елда Институт каршына СССР Фәннәр академиясе тарафыннан Советлар Союзы халыкларының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен исәпкә алу кысаларында Татарстанның Археологик картасын төзү бурычы куела. Берничә ел эчендә республикабызның төрле районнарына экспедицияләр оештырыла, музей һәм архив фондлары тикшерелә. Үткәрелгән тикшеренүләрнең беренче нәтиҗәсе буларак, 1954 елда Н.Ф. Калининның А.Х. Халиков белән язылган китабы дөнья күрә [Калинин, 1954].

---

[1] Профессор А.П. Смирновның шәкерте, Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, 1952–1955 елларда Дәүләт тарих музеенда (Мәскәү) аспирантура үтә һәм 1957 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли башлый.

[2] Казан дәүләт университетын 1941 елда тәмамлый, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 елда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклаганнан соң, СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институтында эшли. 1958–1968 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән гыйльми хезмәткәр. Галимнең фәнни мирасын башлыча болгар-татар эпиграфикасына, этнография һәм археология өлкәсенә караган хезмәтләр тәшкил итә.

[3] Н.Ф. Калининның шәкерте, Пермь университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, 1955–1958 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында аспирантурада укый.

Сугыштан соңгы елларда, аз гына финанс мөмкинлекләре килеп чыгуга ук, борынгы археология һәйкәлләрендә стационар казу эшләре үткәрелә башлый.

Аерым алганда, Минзәлә районының Дәвек авылы янында палеолит (б. э. кадәр X–VIII меңьеллыклар), Апас районының Кабык Күпер авылы янында мезолит (б. э. кадәр VI–V меңьеллыклар), Казаннан ерак түгел Обсерватория поселогы янында неолит (б. э. кадәр IV–III меңьеллыклар) чоры кешеләре калдырган торулыклар казып өйрәнелә. Урта Идел һәм Түбән Кама төбәкләрендә моңарчы билгеле булмаган, таш гасыры чорына караган гаять кыйммәтле археологик материаллар А.Х. Халиков хезмәтләрендә беренче мәртәбә киң фәнни әйләнешкә кертелә (1958; 1960). Яшь галим, шулай ук беренче мәртәбә, бронза гасырында (б. э. кадәр II меңьеллык) яшәгән кабиләләрнең торулыкларын һәм каберлекләрен казып өйрәнә, шул материаллар нигезендә элгәреге тимер гасыры чорында ананьино культурасын формалаштыруга катнашкан Казан буе археологик культурасын ача (1954; 1962), баланово һәм абашево кабиләләренең курган каберлекләрен казый (1959; 1960). Киң колач белән үткәрелгән тикшеренүләр вакытында тупланган өр-яңа археологик материаллар нигезендә А.Х. Халиков башта кандидатлык (1955), аннан соң докторлык (1966) диссертацияләрен яклап, фән дөньясына таш һәм бронза дәверләрендә Төньяк-Көнчыгыш Европаның Урта Идел – Урал Буе төбәкләрендә яшәгән күпсанлы борынгы кабиләләрнең катлаулы тарихын тәкъдим итте.

1953–1954 елларда Н.Ф. Калинин һәм А.Х. Халиковның Лаеш районы Имәнкискә авылы янында урнашкан борынгы шәһәрлекне казыганда табылган материаллары фәндә моңа кадәр билгеле булмаган тагын бер археологик культура ачарга мөмкинлек бирде. Бу культураны IV–VII гасырларда яшәгән кабиләләр калдырган, аларны шартлы рәвештә имәнкискәлеләр дип атыйлар. Кызганычка каршы, имәнкискәлеләрнең этник тамырлары әле һаман да ачыкланмаган, болгарларның этник яктан формалашуында катнашу-катнашмау мәсьәләсе дә җитәрлек өйрәнелмәгән.

Тимер гасырына караган һәм бүгенге мари, удмурт халыкларының борынгы бабаларыннан саналган пьянобор (б. э. кадәр II – б. э. ның II гасырлары) һәм аларның дәвамчылары азелино (III–V гасырлар) кабиләләренә нисбәтле археологик истәлекләрне өйрәнү В.Ф. Генинг өлешенә туры килде (1959). Ул шулай ук имәнкискә кабиләләренең Лаеш районы Рождествено авылы янында урнашкан борынгы каберлекләрен (1962), Менделеев районының Турай авылы янында һуннарның хәрбиләре җирләнгән уникаль курганнарны казып тикшерде. Урта Идел һәм Түбән Кама төбәкләре халыкларының болгарларга кадәрге чордагы этник тарихына багышланган һәм фәнни кыйммәтен әле бүген дә югалтмаган беренче саллы хезмәтне дә В.Ф. Генинг язды [Генинг, 1959].

Азов, Кара диңгез далаларыннан безнең якларга VIII гасыр урталарында күчеп килгән болгарлар күмелгән Олы Тархан зираты

(республикабызның Тәтеш районында) 1957, 1960 елларда В.Ф. Генинг һәм А.Х. Халиков тарафыннан җентекләп өйрәнелгән иде. Аның материаллары 1964 елда Мәскәүнең «Наука» нәшриятында дөнья күрде [Генинг, 1964]. Татар этногенезының болгар чорына караган этабын өйрәнү бүген дә Олы Тархан материалларыннан башлана.

Болгарда СССР Фәннәр академиясенең А.П. Смирнов җитәкчелегендәге Идел буе археологик экспедициясе сугыш вакытында өзелеп торган эшләрен дәвам итте. Шәһәрлекнең башлыча Куйбышев сусаклагычы астында калачак өлешләре казылды. 1957 елдан башлап экспедициядә Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Т.А. Хлебникова эшли.

Һ.В. Йосыповның 1960 елда басылып чыккан фундаменталь хезмәте болгар-татар эпиграфикасына багышланган иде. Биредә татар зиратларында башлыча XIV–XVI йөзләрдән сакланып калган 500 ләп каберташ язмалары тикшерелә [Юсупов, 1960]. Еллар үткән саен әлеге хезмәтнең фәнни әһәмияте күтәрелә генә бара.

1950 елларда безнең Институт, күрше республикалар һәм өлкәләр белән фәнни хезмәттәшлек традицияләрен башлап, Мари АССРның Тел, әдәбият, тарих һәм икътисад фәнни-тикшеренү институты белән берлектә А.Х. Халиков җитәкчелегендә Мари археологик экспедициясе оештыра. Әлеге экспедиция тарафыннан Мари республикасында һәм Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсендә борынгы фин-угор кабиләләре калдырган дистәләгән археологик һәйкәлләр ачыла һәм казып тикшерелә.

***Археология һәм этнография секторы*** Тел, әдәбият һәм тарих институты составында 1962 елда оеша. 1965 елга кадәр профессор Н.И. Воробьёв, аннан соң А.Х. Халиков җитәкләгән әлеге секторның археология төркемендә 4 археолог (сектор җитәкчесеннән башка Т.А. Хлебникова, Р.С. Габәшев, П.Н. Старостин) һәм эпиграфист-галим Һ.В. Йосыпов була. Соңгырак елларда секторга яшь археологлар Р.Г. Фәхретдинов (1966 елда), Е.П. Казаков (1967 елда) килеп өстәлә. 1970 елларда археологлар төркеменә М.Г. Косменко, Ф.Ш. Хуҗин, Р.Ф. Шәрифуллин, М.М. Кавиев, Г.И. Дроздова кабул ителә. Институт коллективында археозоология (А.Г. Петренко, 1966 елда) һәм антропология (Р. М. Фәттахов, 1977 елда) буенча югары квалификацияле белгечләр эшли башлый.

Археологларның фәнни-тикшеренү планнарында өстенлекле юнәлеш булып һаман да Татарстанның археологик картасын төзү темасы кала бирде. Бу эш бары тик 1970 еллар ахырында гына тәмамланды. 4500 дән артык археология һәйкәлләренең тасвирламасын үз эченә алган хезмәт 1981–1990 елларда алты томлы китап булып басылып чыкты[1] (Археологическая карта, 1981; 1984; Археологические

---

[1] Әлеге хезмәтнең төп авторлары А.Х. Халиков, Р.С. Габәшев, Е.П. Казаков, П.Н. Старостин, Р.Г. Фәхретдинов, Ф.Ш. Хуҗин, Һ.В. Йосыпов 1994 елда Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булдылар.

памятники, 1988; 1989; 1990). Мәскәүнең «Наука» нәшрияты чыгара торган «Археологик чыганаклар тупланмасы» сериясендә тематик карталары белән Имәнкискә, Баланово, Казан тирәсе археологик культураларына багышланган китаплар дөнья күрде. Р.Г. Фәхретдиновның болгар-татар археологик һәйкәлләре тупланмасы фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алынды [Фахрутдинов, 1975].

1961 елдан Куйбышев сусаклагычының Татарстан зонасында (Идел белән Кама кушылган җирдә) башланып киткән һәм дулкыннар белән яисә су астында калып юылып юкка чыга язган 700 ләп археологик һәйкәлләрне саклау-коткару максатын күз алдында тоткан тикшеренүләр Казан археологлары эшчәнлегенең күп елларга исәпләнгән тагын бер фәнни юнәлешенә әверелде. Разведка һәм казу эшләре башлыча иртәнге яз һәм көз көннәрендә, сусаклагычта су кимегән чорда башкарылды.

1968–1972 елларда П.Н. Старостин, Р.С. Габәшев, Е.П. Казаков һәм М.Г. Косменко төзелеп килүче Түбән Кама сусаклагычы астында калачак археология һәйкәлләрен казыдылар. Әлеге эшләрнең нәтиҗәләре күпсанлы мәкаләләрдә, фәнни җыентыкларда, китапларда чагылыш тапты, тупланган материаллар М.Г. Косменконың Урта Идел мезолитына, Р.С. Габәшевның Түбән Кама неолитына багышланган кандидатлык диссертацияләрендә төп чыганак буларак кулланылды.

Бронза һәм элгәреге тимер дәверләрен өйрәнү элеккечә А.Х. Халиков һәм аның коллегалары, шәкертләре тарафыннан дәвам ителде. А.Х. Халиковның таш һәм бронза гасырларында Урта Идел бассейнында яшәгән халыкларның тарихын өйрәнүгә багышланган монографиясе [Халиков, 1969] Россия һәм чит ил галимнәре тарафыннан Татарстан археологларының чираттагы уңышы буларак югары бәяләнде. Әйтергә кирәк, А.Х. Халиков тарафыннан тәкъдим ителгән фин-угор халыкларының этногенезы концепциясе, асылда, бүген дә искермәде, яңа чыганаклар нигезендә ул һаман да камилләшә генә бара.

1960 елларның икенче – 1980 елларның беренче яртысында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре болгарларга кадәрге һәм бигрәк тә Идел Болгары чорына караган археология һәйкәлләрен өйрәнүгә күбрәк игътибар итә башладылар. П.Н. Старостин бик актив рәвештә имәнкискә кабиләләренең әле хәзер дә серләр-табышмаклар белән тулы тарихын язу белән шөгыльләнде.

1961 елдан башлап Е.П. Казаков һәм Татарстан дәүләт музее хезмәткәре Е.А. Халикова IX гасырның икенче яртысында яшәгән элгәреге болгарларның Танкеевка некрополен (биредә якынча 6 мең чамасы кабер исәпләнелә) казып тикшерә башладылар. Яңа чыганаклар Идел болгарларының этногенезында, төркиләрдән кала, фин һәм угор компонентларының да зур урын алып торуын расладылар [Khalikova, 1977].

1970 елларның икенче яртысында Казан археологлары болгар этногенезын өйрәнүгә кагылышлы тагын бер уникаль археология һәйкәленә тап булдылар: А.Х. Халиков һәм Е.А. Халикова тарафыннан республикабызның Алексеевск районы Олы Тигәнәле авылы янында элгәреге венгр-маҗарларның IX гасырда көнчыгыштан көнбатышка (Паннониягә) күчеп утырышлары вакытында калдырылган каберлекләре тикшерелде. Әлеге ачыш, аңлашыла ки, археология дөньясында, бигрәк тә Венгриядә, зур кызыксыну уятты. Венгр коллегаларыбыз, Олы Тигәнәле ачышларына багышлап, халыкара конференция дә үткәрделәр, казылмаларның материалларын да тулысынча бастырып чыгардылар [Halikova, 1981]. Кызганыч, Танкеевка материаллары (бүгенге көндә биредә 1200 кабер өйрәнелгән) әле һаман да тулысынча фәнни әйләнешкә кертелмәгән. Олы Тигәнәле материаллары исә, ниһаять, күптән түгел үзебездә рус телендә басылып чыкты [Халикова, 2018; Халиков, 2022].

1970–1980 елларда болгар шәһәрләрен археологик өйрәнү өлкәсендә зур уңышларга ирешелде. Болгарда казу эшләре дәвам итте, һәм иң мөһиме, биредә Алтын Урда чорында төзелгән борынгы архитектура корылмаларына игътибар көчәйде. Т.А. Хлебникова болгарларның Танкеевка, Алексеевское, Җүкәтау һ. б. шәһәрлекләрендә казу эшләре алып барды. Р.Г. Фәхретдинов «Иске-Казан» – XII гасыр ахырына – XVI гасыр башларына караган Камай һәм Рус Урматы комплексын казый башлады. Шул ук елларда А.Х. Халиков һәм аның хезмәттәшләре Казан Кремлендә, башкалабызга нигез салыну вакытын ачыклау максатында, кызыклы тикшеренүләр үткәрде. Куелган максатка ирешелмәсә дә, әлеге тикшеренүләр нәтиҗәсендә башкалабызның монголларга кадәрге чорда ук яшәгәнлеген исбатлаучы материаллар, шул исәптән, иң борынгы саклану корылмалары табылды. Казан ханнары күмелгән төрбәләрне ачу исә, киң җәмәгатьчелек тарафыннан олы бер сенсация буларак кабул ителде [Мавзолеи..., 1997]. Рус елъязмаларында Олуг шәһәр исеме белән билгеле булган, әмма археологик яктан бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән Биләрдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Казан дәүләт университетының берләштерелгән экспедициясе профессор А.Х. Халиков җитәкчелегендә 1967 елда киң масштаблы казу эшләре башлап җибәрде. Көнчыгыш Европаның урман-дала киңлекләрендә беренче мәртәбә буларак, Биләрне һәм аның тирә-юнен махсус приборлар белән аэрофотога төшерү, Урта Идел төбәгендә X гасырда ук салынган уникаль Җамигъ мәчет хәрабәләрен, кирпеч архитектура биналарын («кәрван-сарай» мунчасы, «бай феодал йорты», эчке шәһәрдәге җәмәгать мунчасы) казып чыгарып консервацияләү, гомуми озынлыгы 40 чакрымга җитә торган саклану диварларын, торак йорт һәм хуҗалык корылмаларын, болгар археологиясендә бүгенгәчә бердәнбер булып кала биргән юрта эзләрен, металл коючылар, тимерчеләр, чүлмәк ясаучылар яши торган һөнәрчелек бистәләрен, шәһәр зиратларын тикшерү, материалларын озакка сузмыйча фәнни

әйләнешкә кертү [Исследования..., 1976; Новое..., 1979; Культура..., 1985] – боларның барысы да Биләрне, территориясенең бары тик 0,25% гына казылган булуга карамастан, археологик яктан яхшы ук өйрәнелгән болгар шәһәрләре рәтенә куйдылар. Һәрхәлдә Биләрдә эшләүче археологлар кулында Болгар дәүләтенең беренче башкаласына кагылышлы бәхәсле проблемаларны яңадан күтәрү өчен бай мәгълүмат тупланган иде [Биляр..., 1991].

1970 елларда археологиядәге яңа ачышлар Урта Идел регионында яшәүче фин-угор һәм төрки халыкларның килеп чыгышы проблемаларын өйрәнүне актуальләштерде. Төрки халыкларның этногенезына багышланган мәкаләләр җыентыгын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты 1971 елда чыгарды [Вопросы..., 1971]. Әлеге җыентыкка кертелгән мәкаләләрнең кайберләре галимнәр арасында бәхәсләр тудырса да, ахыр чиктә, ул әлеге өлкәдә алып барыла торган тикшеренүләрне җанландырып кына җибәрде. Бу юнәлештә А.Х. Халиков бик актив эшләде. Кызганычка каршы, галимнең 1970 еллар уртасында ук тәмамланган монографиясе вафатыннан 17 ел үткәннән соң гына, шәкертләренең тырышлыгы белән дөнья күрә алды [Халиков, 2011].

Институтның сан ягыннан артык зур булмаган археологлар төркеме алып барган тикшеренүләрнең тематикасы җитәрлек дәрәҗәдә киң булып, әлеге «киңлек» авторлар коллективы әзерләп чыгарган фәнни җыентыкларда чагылыш таба иде. Әйтергә кирәк, шул тематика кысаларында планлаштырылган хезмәтләр, кагыйдә буларак, югары фәнни дәрәҗәдә башкарылалар. 1980 елларның беренче яртысында гына да Мәскәүнең «Наука» нәшриятында 5 индивидуаль монография һәм 2 коллектив хезмәт басылып чыгуы – әлеге фикерне куәтләүче ачык факт.

Казан археология мәктәбенең өлгергәнлеген күрсәтүче фактлар исәбенә галимнәребезнең еш кына Болгариядә, Венгриядә, Чехославакиядә, Финляндиядә һәм кайбер башка илләрдә үтә торган халыкара конференцияләрдә катнашуларын да өстәргә мөмкин.

1986 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтында чираттагы структур үзгәрешләр булды, аерым алганда, археология һәм этнография секторы икегә бүленде.

***Археология бүлегендә*** 9 фәнни хезмәткәр (шул исәптән, 1 доктор, 5 фәннәр кандидаты) һәм 4 лаборант эшли иде. Бүлек белән 1989 елга кадәр А.Х. Халиков, 1989–1990 елларда Ф.Ш. Хуҗин, 1990 елның октябреннән башлап П.Н. Старостин җитәкчелек иттеләр.

Фәнни тикшеренүләрнең тематикасы үзгәрмәде диярлек. Ел саен язын-көзен Идел-Кама сусаклагычлары зонасында калган һәм җимерелеп юкка чыгу куркынычы янаган борынгы объектларны саклауга, казулар үткәрүгә, һичьюгы аунап яткан табылдыкларны җыеп алуга юнәлдерелгән эшләр алып барылды. Шундый эшләр нәтиҗәсендә тупланган материалларны өйрәнеп, Е.П. Казаков Каманың түбән

агымында урнашкан болгар авыллары, халыкара сәүдә үзәкләре турында кызыклы монография язды [Казаков, 1990].

Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары зонасында башлыча борынгы таш, бронза һәм элгәреге тимер гасырына караган археология һәйкәлләре өйрәнелде. В.Н. Марков 1988 елда Мәскәүдә ананьино кабиләләренең этник компонентларын ачыклауга багышланган кандидатлык диссертациясен яклады. П.Н. Старостинны соңгырак чорда яшәгән пьянобор, азелино һәм имәнкискә кабиләләренең тарихы кызыксындырды.

Элгәреге болгарлар археологиясен Н.Ф. Калининның тууына 100 ел тулуга багышлап үткәрелгән Бөтенроссия фәнни конференциясе җанландырып җибәрде. Е.П. Казаков фәнни җәмәгатьчелеккә болгар археологиясендә әһәмиятле вакыйга буларак кабул ителгән фундаменталь монография һәм докторлык диссертациясе рәвешендә тәкъдим итте [Казаков, 1992].

Болгар һәм Биләр шәһәрләрендә казу эшләре тукталып тормады. Г.А. Фёдоров-Давыдов һәм Т.А. Хлебникова редакциясендә «Шәһри Болгар» исемле коллектив монографиянең беренче томнары дөнья күрде. Биләр археологиясенә караган хезмәтләрдән Идел Болгарстанының X–XI йөзләрдәге башкаласы проблемасын чишүгә юнәлдерелгән мәкаләләр җыентыгын атарга була [Биляр..., 1991]. Әлеге җыентык 1972–1975 елларда «Советская археология» журналы оештырган фәнни дискуссиядә традицион караш тарафдарлары буларак чыгыш ясаган А.П. Смирнов, Р.Г. Фәхретдинов һәм Т.А. Хлебниковага җавап рәвешендәрәк әзерләнгән иде. Болгар дәүләтенең әүвәлге башкаласы белән бәйле проблемаларны Ф.Ш. Хуҗин Биләрнең культура катламы стратиграфиясенә һәм хронологиясенә багышланган монографиясендә дә читләтеп уза алмады [Хузин, 1995].

1990 еллар башында Ф.Ш. Хуҗин һәм аның коллегалары моңа кадәр археологларның игътибарыннан читтәрәк калып килгән Сувар, Җүкәтау, Чаллы ише болгар-татар калаларында да казу эшләре үткәрә алдылар[1].

Украина ССР Фәннәр академиясенең Археология институты белән СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты арасында 1988 елда төзелгән килешү кысаларында XII гасыр гарәп географы әл-Идриси язмаларында тасвирланган Болгар – Киев сәүдә юлын археологик яктан өйрәнү өчен А.Х. Халиков һәм А.П. Моця җитәкчелегендәге экспедиция өч сезон буена (1989–1991 еллар) әлеге кәрван юлының көнбатыш (Русь) һәм көнчыгыш (Болгар) өлешләрендә җентекле разведка, ә кайбер пунктларда казу эшләре үткәрде. Тикшеренүләр нәтиҗәсе Воронежда һәм Казанда үткәрелгән конференцияләрдә чыгыш ясау-

---

[1] Ул вакыттагы авыр кризис шартларында әлеге экспедицияләрне оештыруда, аз булса да финанслауда Институт директоры М.З. Зәкиевнең роле зур булуын рәхмәт хисләре белән искә алып үтәсем килә. – *Авт.*

чыларның докладларында һәм соңыннан махсус монографиядә бәян ителде [Моця, 1997].

1994 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты «Казан Кремле» музей тыюлыгы һәм Казан дәүләт университеты белән берлектә Кремль территориясендә казу эшләре башлап җибәрде. Берләштерелгән археологик экспедициянең җитәкчесе итеп А.Х. Халиковның шәкерте Ф.Ш. Хуҗин билгеләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1995 ел 16 октябрендә чыккан 746 нчы номерлы карары нигезендә Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология бүлеге Археологик тикшеренүләр милли үзәге (Национальный центр археологических исследований – НЦАИ) итеп үзгәртелә. Бер елдан әлеге Үзәк Татарстан Фәннәр академиясе составында яңа оешкан Тарих институтына күчә.

Шулай итеп, Тел, әдәбият һәм тарих институты составында археология фәне зур уңышларга иреште, халыкара танылу алды. Биредә үзенең илкүләм танылган галимнәре булган Казан археология мәктәбе барлыкка килде. Институт галимнәренең борынгы таш, бронза, элгәреге тимер һәм Урта гасырлар, бигрәк тә болгар, Алтын Урда археологиясе өлкәсендә ясаган ачышлары археология фәненең киләчәктәге үсеше өчен нигез булып торалар.

**Әдәбият**

Биляр – столица домонгольской Булгарии / отв. ред. Ф.Ш. Хузин. Казань, 1991. 139 с.

Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФАН СССР, 1971. 295 с.

*Генинг В.Ф.* Очерк этнических культур Прикамья в эпоху железа // Тр. КФ АН СССР, сер. гуманит. наук. Вып. 2. Казань, 1959. С. 157–219.

*Генинг В.Ф., Халиков А.Х.* Ранние болгары на Волге: Больше-Тарханский могильник. М.: Наука, 1964. 196 с., 11 л. ил.

Исследования Великого города / отв. ред. В.В. Седов. М.: Наука, 1976. 262 с.

*Казаков Е.П.* Булгарское село X–XIII веков низовий реки Камы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 176 с.

*Казаков Е.П.* Культура ранней Волжской Болгарии / отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1992. 335 с.

*Калинин Н.Ф., Халиков А.Х.* Итоги археологических работ за 1945–1952 гг. // Труды КФАН СССР. Сер. истор. наук. Казань: Татар. кн. изд-во, 1954. 126 с.

Культура Биляра: Булгарские орудия труда и оружие X–XIII вв. / отв. ред. А.Х. Халиков. М.: Наука, 1985. 215 с.

Мавзолеи Казанского Кремля: (Опыт историко-антропологического анализа) / отв. ред. Р.С. Хакимов. Казань: Ин-т истории АН РТ, 1997. 158 с.

*Моця А.П., Халиков А.Х.* Булгар – Киев: пути, связи, судьбы. Киев, 1997. 192 с.

Новое в археологии Поволжья: Археологическое изучение центра Билярского городища / отв. ред. А.Х. Халиков. Казань: ИЯЛИ КФАН СССР, 1979. 155 с.

*Фахрутдинов Р.Г.* Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. 219 с.

*Халиков А.Х.* Великая Венгрия между Волгой и Уралом. (Археология евразийских степей. Вып. 27) / отв. ред. А.Г. Ситдиков. Казан; Воронеж, 2022. 160 с.

*Халиков А.Х.* Древняя история Среднего Поволжья. М.: Наука, 1969. 395 с.

*Халиков А.Х.* Основы этногенеза народов Среднего Поволжья и Приуралья / отв. ред.: С В. Кузьминых, Ф.Ш. Хузин. Казань: Ин-т истории АН РТ, 2011. 336 с.

*Халикова Е.А., Халиков А. Х.* Ранние венгры на Каме и Урале (Больше-Тиганский могильник) // Археология евразийских степей. Вып. 25 / отв. ред. А.Г. Ситдиков. Казань: Фэн; Ин-т археологии им. А.Х. Халикова АН РТ, 2018. 144 с.

*Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1960. 165 с., 77 табл.

*Хузин Ф.Ш.* Великий город на Черемшане. Стратиграфия, хронология. Проблемы Биляра – Болгара. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1995. 223 с.

*Khalikova E.A., Kazakov E.P.* Le cimetiere de Tankeevka // Les anciens hongrois et les ethnies voisines a l'Est. Budapest, 1977. P. 21–221.

*Halikova E.A., Halikov A.H.* Altungarn an der Kama und im Ural. (Das Gräberfeld von Bolschie Tigani) / Régészeti Füzetek, ser. II, No 21. Budapest: Maguar Nemzeti Múseum, 1981. 132 s.

***Хуҗин Фаяз Шәрип улы,***
*тарих фәннәре докторы, профессор, ТФА мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА А.Х. Халиков исемендәге Археология институтының*
*баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 398

***И.И. Ямалтдинов***

# XX ЙӨЗНЕҢ 60 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ БУЕНЧА ТИКШЕРЕНҮЛӘР

В статье проводится обзор наиболее значимых трудов по изучению татарского устного народного творчества в 1960-е гг. Автор подробно останавливается на монографии Х. Ярми «Поэтическое творчество татарского народа» (1967), отмечает, что этот труд является первым серьёзным шагом в научно-теоретическом исследовании татарского фольклора.

**Ключевые слова:** фольклористика, татарское народное творчество, жанры, изучение, Хамит Ярми.

The article begins with a review of the most significant works on the study of Tatar oral folk art in the 1960s. The author dwells in detail on the monograph of Kh. Yarmi “Poetic creativity of the Tatar people” (1967). This work is the first serious step in the scientific and theoretical study of Tatar folklore.

**Keywords:** folklore studies, Tatar folk art, genres, study, Khamit Yarmi.

Татар халкының гасырлар дәвамында барлыкка килгән поэтик иҗаты гаять төрле һәм бай. Милли фольклор әсәрләрен өйрәнү, аларга характеристика бирү һәм классификацияләү һәрвакыт татар фольклористикасының мөһим бурычларының берсе булып тора. 1960 еллардан башлап фольклор һәм әдәбият, аларның бәйләнеше һәм бер-берсенә тәэсир итүе, аерым язучыларның иҗатындагы урыны һ. б. кебек мәсьәләләр актив рәвештә карала. Вакытлы матбугатта, фәнни җыентыкларда дистәләгән мәкаләләр басылу [Ярми, 1962 // Совет әдәбияты, № 9, б. 117–126; Галиуллин, 1964 // Совет әдәбияты № 2, б. 129–135; Галиуллин, 1964 // Социалистик Татарстан, 1 март; Ахметова, 1965; Әхмәтова, 1966, Совет мәктәбе, № 7, б. 42–44; Нигъмәтуллин, 1967; Ахметова Ф, 1967, с. 50–51; Надиров, 1968, с. 185–195; Урманчеев, 1968, с. 196–208; Ахметова, 1969, 81–86], «Фольклор һәм хәзерге татар прозасы» [Ахметова, 1968], «Хәзерге татар поэзиясе һәм халык иҗаты» [Галиуллин, 1968] кебек масштаблы темаларга диссертацияләр язылу һәм яклану бу мөһим проблемалар буенча максатчан тикшеренүләрнең алып барылуы турында сөйли.

Әлеге актуаль темалар белән беррәттән, традицион фольклор, аның халык күңелендә саклануы, яңа бәетләр, җырлар һәм мәкальләр туу, фольклористиканың үсешендә үзешчән түгәрәкләрнең роле кебек мәсьәләләр дә куела. Бу проблемалар Ф. Урманчеевның «Татар совет халык иҗаты жанрларының үсеш юллары» дип исемләнгән диссертациясендә [Урманчеев, 1968] тикшерелә.

1960 елларда татар халык иҗатының аерым жанрлары буенча диссертацияләр [Касимов, 1966; Махмутов, 1969] дә яклана. Шулай ук фольклорчылар Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, И. Надиров эчтәлекле фәнни аппараты булган җыентыклар [Бәширов, 1960; Ярми, 1960; Әхмәт,

1962; Бәширов, 1963; Надиров, 1965 һ. б.] төзеп бастыра. Шушы авторлар тарафыннан халык җырлары, әкиятләр, мәкальләр кебек төп жанрларның идея-эстетик һәм тематик үзенчәлекләренә ясалган күзәтүләр татар фольклористикасы үсешендә җитди ачыш һәм мөһим адым булып тора. Алар арасында Н. Исәнбәтнең өч томнан торган «Татар халык мәкальләре» [Исәнбәт, 1959; 1963; 1967] җыентыклары фундаменталь хезмәт санала. Әмма бу казанышларны исәпкә алганда да, 1960 еллар ахырына кадәр безнең фольклористикада барлык татар халык иҗаты жанрларын колачлаган теоретик хезмәт булмый. Ниһаять 1967 елда Х. Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» китабы дөнья күрә. Әлеге хезмәт татар фольклорын фәнни-теоретик тикшерүдә беренче адым була. Шушы хезмәткә тирәнрәк тукталыйк.

Академик Ә. Кәримуллин язганча, «Х. Ярминең әлеге хезмәтендә татар фольклористикасының барлык фольклор жанрларының диярлек системалы рәвештә фәнни тикшерелүе – беренче зур казаныш» [Кәримуллин, 1968, б. 58–59]. Профессор Ф. Урманчеев та әлеге монографиягә кадәр татар фольклористикасы проблемаларын тулы итеп яктырткан фәнни хезмәтнең булмавын ассызыклый [Мәхмүтов, 2004].

Халык язучысы М. Мәһдиев үзенең «Халык әдәбиятыбызга бер караш» [Мәһдиев, 1968, б. 127–140] дип аталган күләмле мәкаләсендә, татар халык авыз иҗатын төрле яклап анализлау буенча беренче тәҗрибә буларак, Х. Ярминең хезмәтенә уңай бәя бирә.

Шулай итеп, монографиядә татар фольклористикасының барлык актуаль мәсьәләләре үз чоры өчен югары фәнни дәрәҗәдә яктыртыла.

Хезмәтнең беренче һәм иң күләмле өлеше татар фольклорын җыю һәм фәнни өйрәнү тарихына багышланган. Автор, татар фольклорының төп жанрларын җыю, бастыру һәм теоретик тикшерү юнәлешендә эшләп, бу өлкәдә билгеле булган барлык хезмәтләргә бәя бирергә омтыла. Ул беренче булып Г. Балинт, Х. Паасонен кебек чит ил һәм И. Лепехин, И. Рычков, М. Чулков, И. Добровольский, В. Радлов, Н. Катанов кебек рус галимнәренең хезмәтләрен анализлый һәм аларның татар фольклористикасы үсешендә зур роль уйнавын билгели. Шулай ук К. Насыйри, Г. Тукай, Х. Бәдигый, Г. Ибраһимовның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге дә анализлана.

Монографиядә күтәрелгән икенче мәсьәлә – татар фольклоры жанрлары проблемасы. Беренче бүлектә татар фольклоры жанрларының иң күләмлеләреннән берсе булган халык әкиятләре, аның төрләренең үсеш юллары һәм төп үзенчәлекләре тикшерелә. Мәсәлән, әкиятләр өч тематик төркемгә бүленеп, һәрберсенә характеристика бирелә, төп персонажлары өйрәнелә. Автор татар халык әкиятләренең, «Ак бүре», «Унберенче Әхмәт», «Корчаңгы тай», «Чакма ташы» әсәрләре мисалында, бик борынгы заманнарда барлыкка килүен билгели [Ярми, 1967].

Алга таба Х. Ярми мәкаль һәм әйтемнәрне анализлый, аларның үсеш юлларын тикшерә, татар фольклоры афористик жанрларының идея-тематик үзенчәлекләрен аерып күрсәтә.

Шулай ук җыр жанрын фәнни тикшереп, халыкның иң авыр вакытларда да якты киләчәккә булган өметен югалтмавын, тормышның матур якларын күреп, дуслыкка, бердәмлеккә, мәхәббәт һәм бәхеткә дан җырлавын ассызыклый. Монографиядә эчтәлеге һәм тематикасы буенча күптөрле булган татар табышмаклары да анализлана.

Әлеге һәм башка мәсьәләләрнең күбесе Х. Ярми тарафыннан беренче тапкыр куела һәм хәл ителә. «Бәетләр» бүлегендә бу жанрга җентекле анализ бирелә. Татар халык иҗатына гына хас әлеге үзенчәлекле әсәрләргә Х. Ярми үз тикшеренүләрендә зур урын бирә. Аларда халык тарихы, авыр, кайгылы тормыш яктыртыла. Башка жанрлардан аермалы буларак, бәетләр конкрет вакыйгага бәйле, анда баш геройның аерым кеше яисә халык булуы ассызыклана [Ярми, 1960].

Башка халыкларныкы кебек үк татар халык авыз иҗаты жанрлары да күптөрле. Х. Ярми «Татар халкының поэтик иҗаты» монографиясендә һәрбер жанрны социаль һәм поэтик яктан бәяли, аларның генезисын яктырта. Әлеге фундаменталь хезмәт тулаем Н. Уразованың диссертациясендә анализлана [Уразова, 2008].

Күргәнебезчә, Х. Ярми үзенең эшчәнлегендә фольклор җыю, материалны информантлардан турыдан-туры үзе язып алу аша фәнни тикшеренүләргә килә. Булган барлык материалны гомумиләштерә, анализлый һәм фәнни нәтиҗәләр ясый. Билгеле булганча, Х. Ярми татар фольклорчылары арасында беренче булып «Татар халкының поэтик иҗаты» темасына Казакъстан Фәннәр акдемиясенең филология буенча берләштерелгән Гыйльми советында докторлык диссертациясе яклый. Аның рәсми оппонентлары: филология фәннәре докторы профессор Ә. Кирәев, академик М. Габдуллин, филология фәннәре докторы И.Дюсенбаев. Чыгыш ясаучылардан профессорлар Н. Смирнова, Г. Мусабаев, тарих фәннәре кандидаты Г. Вәлиханов һ. б. Х. Ярминең докторлык диссертациясенә югары бәя биреп, фольклористикага саллы өлеш кертү дип билгелиләр.

Шулай итеп, XX йөзнең 60 нчы елларында татар халык иҗатының аерым жанрлары буенча диссертацияләр яклана, фәнни аппараты булган җыентыклар бастырыла, һәм татар фольклористикасының барлык жанрларының диярлек системалы рәвештә фәнни тикшерелүе тәүге зур казаныш булып тора.

## Әдәбият

*Ахметова Ф.В.* Народно-поэтические мотивы в романе Ф. Хусни «Тропа пешехода» // Вопросы истории и литературы народов Среднего Поволжья. Казань, 1965.

*Ахметова Ф.В.* Песни в романе А.Файзи «Тукай» // Тезисы докладов научной конференции молодых учёных. Казань, 1967. С. 50–51.

*Ахметова Ф.В.* О некоторых особенностях использования фольклора в современной татарской прозе // Вопросы татарского языка и литературы: Кн. 4. Казан, 1969. 81–86.

*Ахметова Ф.В.* Фольклор и современная татарская проза: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1968. 24 с.

*Әхмәт А.* Хуҗа Насретдин мәзәкләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. 232 б.

*Әхмәтова Ф.В.* Хәзерге татар прозасында мәкальләр һәм әйтемнәр // Совет мәктәбе, 1966. № 7. Б. 42–44.

*Бәширов Г.* Мең дә бер мәзәк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 404 б.

*Бәширов Г.* Туксан тугыз мәзәк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 88 б.

*Галиуллин Т.* Сибгат Хәким поэзиясенең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше // Совет әдәбияты. 1964. № 2. Б. 129–135.

*Галиуллин Т.* Халык күңел көзгесе // Социалистик Татарстан. 1964. 1 март.

*Галиуллин Т.Н.* Современная татарская поэзия и народное творчество: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1968. 30 с.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 916 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 960 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: 3 томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 1014 б.

*Касимов Э.С.* Сатира и юмор в татарских народных сказках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1966. 27 с.

*Кәримуллин Ә.* Уңышлы хезмәт // Совет әдәбияты. 1968. № 4. Б. 58–59.

*Махмутов Х.Ш.* Татарские народные загадки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1969. 31 с.

*Мәһдиев М.* Халык әдәбиятыбызга бер караш: [«Татар халкының поэтик иҗаты» (Казан, 1967) китабына рец.] // Казан утлары. 1968. № 11. Б. 127–140.

*Мәхмүтов Х.Ш.* Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 13.

*Надиров И.Н.* Татар халык җырлары: Лирик җырлар. Йола җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 456 б.

*Надиров И.Н.* Тукай и народная песня // Габдулла Тукай: Сборник статей о поэте. Казань, 1968. С. 185–195.

*Нигъмәтуллин Ә.* Язучыларның фольклор белән иҗади бәйләнеше // Кызыл Таң. Уфа, 1967. 22 март.

*Уразова Н.М.* Х. Ярми о влиянии фольклора на формирование татарской литературы: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 23 с.

*Урманчеев Ф.И.* Пути развития основных жанров татарского советского народно-поэтического творчества: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1968. 20 с.

*Урманчеев Ф.И.* Тукай и татарская фольклористика начала XX века // Габдулла Тукай: Сборник статей о поэте. Казань, 1968. С. 196–208.

*Ярми Х.* Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 388 б.

*Ярми Х.* Гомәр Бәширов әсәрләрендә халык поэзиясе // Сов. әдәбияты. 1962. № 9. Б. 117–126.

*Ярми Х.* Татар халык мәкальләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 243 б.

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. Б. 83.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

УДК 94(35)

*Дж.Ш. Курбангельдыев*

# СӘЛҖУКЛАР ДИПЛОМАТИЯСЕНДӘ ҖӘЯҺӘМ УК СИМВОЛИКАСЫ

Статья посвящена истории символики туркменского народа. С давних пор лук и стрела, будучи военным оружием, символизировавшим славные победы, использовались в государственной символике, внешней политике и дипломатии в качестве священных понятий, как средство против насилия и предотвращения войны. В памяти народа прочно обосновались отражение лука и стрел в национальных символиках ценностей и святынь, а также их эффективное использование в дипломатической работе. Огуз-хан использовал символику лука и стрелы как средство достижения благородных целей на основе взаимно согласованных действий. Велика была роль символики в виде лука и стрелы в дипломатических отношениях султанов Великой Сельджукской империи туркмен. Эта символика заняла прочное место в дипломатическом протоколе и этикете Сельджукидов. Автор особо подчеркивает неслучайность изображения лука и стрелы, которые символизировали верховную власть, на гербе первых сельджукских правителей.

**Ключевые слова:** история, символика, лук, стрелы, дипломатия, Великая Сельджукская империя.

Since ancient times the bow and arrow being a military weapon that symbolized the glorious victories of the Turkmen people, have been used used in state symbols, foreign policy and diplomacy as sacred concepts, as a means against violence and preventing war. The reflection of the bow and arrow in the national symbols of values and shrines, as well as their effective use in diplomatic work are firmly established in the memory of the people. Oghuz Khan used the symbolism of the bow and arrow as a means to achieve noble goals through mutually agreed upon actions. The role of symbols in the form of a bow and arrow was great in the diplomatic relations of the sultans of the Great Seljuk Turkmen Empire. This symbolism took a strong place in the diplomatic protocol and etiquette of the Seljuks. It is no coincidence that the coat of arms of the first Seljuk rulers depicted images of a bow and arrow which symbolized supreme power.

**Keywords:** history, symbols, bow, arrows, diplomacy, the Great Seljuk Empire.

2022 елның 21 июлендә Үзәк Азия дәүләтләре башлыкларының Консультатив очрашуында Төрекмәнстан Президенты Сердар Бердымөхәммәдов, Үзәк Азия куркынычлардан азат үсеш, тотрыклылык һәм ышаныч хакына тынычлык зонасы булып калсын өчен, сәяси-дипломатик мөнәсәбәтләрне активлаштыру һәм көчәйтүгә бөтен көчне куярга чакырды. Аерым алганда, бу мәсьәләдә үз карашларын аеруча ачык белдереп, безнең хөрмәтле Президентыбыз болай диде: «Төбәк конфликтларының интенсивлыгы арту фонында аларны нейтральләштерү һәм кисәтү буенча безнең килешенгән позиция аерым әһәмияткә ия була бара.

Конфликтлар кискенләшә барганда, аларны сөйләшүләр юнәлешенә күчерү өчен уңай шартлар тудыру максатында, халыкара тынычлыкка ярдәм итү, регион кысаларында да, башка дәүләтләр белән дә дипломатик хезмәттәшлекне активлаштыру максатка ярашлы булыр дип уйлыйм» [Выступление Президента Туркменистана Сердара Бердымухамедова].

Төбәктә тынычлыкны саклау һәм иминлекне тәэмин итү өчен сәяси-дипломатик эш алып бару Төрекмәнстанның изге ниятләрен чагылдыра һәм данлыклы ата-бабаларыбыз тормыш принципларының ныклылыгына тагын бер дәлил булып тора. Шуңа нисбәтле, күпгасырлык тарихы булган һәм бөтен дөньяга танылган халкыбызның тышкы сәясәтен һәм дипломатиясен, дәүләт идарәсе принципларын һәм ысулларын җентекләп фәнни өйрәнү мәсьәләсе үзенең актуальлеген югалтмый.

Төгәлрәк әйткәндә, игътибарны дәүләтнең тышкы сәяси максатларына һәм мәнфәгатьләренә, халык хәтеренә сеңгән кыйммәтләрнең һәм изге урыннарның милли символикаларда чагылышына һәм аларның дипломатик эштә нәтиҗәле кулланылуына җәлеп итәсе килә.

Элек төрекмән халкының Бөек Сәлҗук империясе солтаннары дипломатик мөнәсәбәтләрендә җәя һәм ук рәвешендәге символиканың роле зур булган. Парфян риваятьләрендә тир – ук, каман – җәя, кантир – ук кынысы кебек атамалар очрый. Шунысы кызык, төрекмәннәрнең кайбер җирле сөйләмнәрендә бу терминнарның тир (ук) һәм кеман (җәя) рәвешендәге вариантлары сакланып калган [Амбарцумян, с. 72; Гундогдыев, 2005].

Тарихчы О. Гундогдыев төрекмән җәя һәм укларының борынгыдан ук изгеләштерелүе, аларга табыну традициясе һәм гореф-гадәтләрнең дә саклануы турында яза. Бу традицияләр зороастризм чорыннан ук килә. Инде «Ригведа»да ук Ут Һәм Кояш алласы Агний Җир падишаһы Арджунга җәя һәм ук бүләк иткән урында арийларның җәя һәм укка табынулары әйтелә [Гундогдыев, 2003].

Бүләк ителгән ук түбәндәге сыйфатларга ия була:

Бүләк ителгән ук,
Аны булдыручының үзе кебек.
Ук һәрвакыт яна,
Ә үлем һәрвакыт яный [Гундогдыев, 2003].

Зороастризмның изге китабы «Авеста»да: «Җәя – көч һәм бай катлауларның куәте» диелә [Köymen, с. 97]. Ук та хакимлек символы була: баш Алла Ахурамазда Нәүруз көнендә беренче кеше Йимгә алтын ук тапшыра. Урта Азиядә Нәүрузгә бер көн кала уктан ату ярышында җиңүчене бер генә көнгә патша итеп игълан итү традициясе бәлки шуның белән бәйледер? [Гундогдыев, 2003].

Төрекмәннәрнең борынгы кагыйдәләре буенча, «Угыз хан үзенең өч өлкән улына сынган уклар биргән һәм аларның нәсел дәвамчыларын “бозок” (сынган уклар) дип атаган. Гаскәрнең уң канатын шушы

өч улына тапшырган. Алтын ук тапкан өч кече улының нәсел дәвамчыларын “уч ук” (өч ук) дип исемләгән һәм гаскәрнең сул канатын шулар кулына биргән. Угыз хан болай дип васыять иткән: “Безнең традицияләр буенча, уң канатның урыны биектәрәк, ә җәя – хакимлек символы. Шуңа күрә мин хакимлекне уң канатка бирдем. Ә сул канатта илчеләр һәм нөкәрләр булсын”» [Ýazyjy ogly Aly, с. 25–26; Агаджанов, 1991, с. 20, 59, 241].

Хакимият символы буларак җәя һәм ук алтынсу төскә урала. Алтын, алтынсу төс – хөкемдарлар төсе. Шуңа күрә борынгы арийлар, саклар һәм угызлар дастанында җәя-ук һәрвакыт алтыннан ясалган дип тасвирлана.

Борынгы авеста телендә *«зараня», «зарый»* сүзләре, ә Ведалар телендә (Ведалар теле – борынгы һинд теленең иң борынгы төре) «суря» сүзе алтынсу һәм сары төсләрне аңлата. Безнең өчен төс кенә түгел, ә идарәченеке булган бар нәрсәнең сары булуы әһәмиятле. Төрекмән дастаннарында еш кына баһадирларның «сары җәя»се турында сөйләнә. Мондый җәя бары тик ханнарда яки танылган баһадирларда гына булган. Үзенең «сары җәя»сен Гёргоглы үзе генә киерә алган. Сары – төсне түгел, бәлки идарәченең алтын җәясен аңлаткан. Ә бу, үз чиратында, бик борынгы гореф-гадәтләрнең дәвам итүенә ишарәли [Гундогдыев, 2003]. Угыз хан заманында алтын очлыклы ук һәм җәя кулланылган. Хан үз кешеләренә үзенең шәхси билгесе итеп алтын очлы ике ук һәм җәясен бирә торган булган. Каңлылар кая гына барсалар да, халык бу укларны күреп, аларның үзләрен һәм хайваннарын ризык, азык-төлек, терлек азыгы һәм су белән тәэмин иткәннәр [Рашид ад-Дин, т. 1, с. 37].

Югарыда китерелгән мисаллардан чыгып, без Угыз хан җәя һәм ук символикасын дипломатик максатларда, үзара килешенгән гамәлләр нигезендә, изге максатларга ирешү чарасы буларак кулланган, дип нәтиҗә ясый алабыз. Тарихчы О. Гундогдыевның Угыз хан үзенең җәя һәм укларын дөньяның төрле почмакларына яшереп, анда үзенең улларын җибәрүе турындагы фикере бездә зур кызыксыну уятты [Гундогдыев, 2003].

Улларының җәя һәм укларны ничек табуына карап, Угыз хан аларның җәмгыятьтәге урынын, социаль статусын билгеләгән. Рәшидетдин вариантында болай диелгән: «Угыз җәясен биргәннәрнең урыннары югарырак булырга, армиядә алар уң канат (фланг) тәшкил итәргә тиеш. Ул ук биргән кешеләр түбәнрәк рангта булып, армиянең сул канатын тәшкил итәргә тиешләр. Чөнки җәя патша сыман хакимлек итә, ә ук исә – аңа буйсынган илче генә» [Рашид ад- Дин Фазлаллах, с. 62].

Әбелгази хан (XVII гасыр) Угыз хан үз улларына әйтеп калдырган үгет-нәсыйхәтләрнең мәгънәсен ача: «Сез җәяне һәм укларны кеше ихтыяры буенча түгел, бәлки Аллаһ ихтыяры белән таптыгыз. Бездән элек үлгән кешеләр патшаны – җәягә, ә үзләрен укларга тиңлиләр, чөнки киерелгән җәядә ук кайсы якка карап тора, шул якка очып та китә» [Абуль-Гази-хан, с. 28].

Галим О. Гундогдыевның Угыз ханның җәягә һәм укка космоганик мәгънә бирүе турындагы фикере аеруча кызыклы: «Угыз хан улларының исемнәре галәмне символлаштыра: Көнхан (кояш), Айхан (ай), Йолдызхан (йолдыз) – бу өчесе космосны гәүдәләндерә; Гёкхан (күк), Денизхан (диңгез), Дагхан (Тау). Бусы – җирдәге дөньяның конструкциясе (өстә – күк, уртада – тау, аста – диңгез). Табылдыкларны берләштереп, аннары аларны улларына таратып, Угыз хан хаостан тормыш төзегән һәм Галәмдә тәртип урнаштырган. Бу очракта төрекмәннәрнең бабасы үзендә ачыктан-ачык Яралтучы сыйфатларын гәүдәләндерә. Әгәр без дөрес фаразласак, Космос – Җәянең Җир – Уклар белән ни өчен идарә итүе аңлашыла. Шулай итеп, төрекмәнугызларның ике канатка бүленүе дуалистик оешу гына түгел, ә Галәм моделе дә булып чыга. Угызлар бу модельне үз җәмгыятьләренә күчерделәр һәм шуның белән хакимиятнең илаһи башлангычын ныгыттылар» [Гундогдыев, 2003].

О. Гундогдыев язганча, җәмгыять җәяләргә һәм укларга бүленгән. Борынгы заманда алар Галәмне белдергән: җәя – бәкләрне, уклар исә – халык һәм кабиләләрне. Ук – Ут һәм Кояш алласының билгесе, тизлек, күчеп йөрү, Кояш нуры һәм яшен, кошның очуы кебек төшенчәләрне үз эченә алган. Ераклык та уклар белән үлчәнә: эпосларда еш кына, озынлык үлчәве берәмлеген күздә тотып, укның бер яки ике очышы турында әйтелә. Урта гасыр төрекмәннәрендә ук кабилә төшенчәсе буларак та кулланылган, анда *ок (ог)* бер үк вакытта укны да, кабиләне дә аңлаткан [Гундогдыев, 1999].

Җәяләр һәм уклар сәлҗукларның гына түгел, башка төрки телле халыкларның да социаль иерархиясендә югары катлауны билгеләгән. О. Гундогдыев җәя һәм укның сугышчы һәм падишаһлар коралы булуын яза. Сакларның риваятьләрендә әйтелгәнчә, Геракл васыяте буенча, аның баһадир җәясенең кынысын киергән улы гына падишаһ була алган. Скиф әлеге шартны үтәгән. Аңардан скифларның патшалары чыккан. Галим, сынган җәянең исә патшаның һәлак булуын яки дәүләтнең җимерелүен аңлатуы хакында яза [Гундогдыев, 2003; Доватур, Каллистов, Шишова, с. 103].

*Ок* сүзенең мәгънәсен аңлатканда, танылган тел галиме С. Атаниязов аның «ыруг, кабилә, буын» кебек мәгънәләре бу исем йөртүче төркемнәрнең (мәсәлән, ыруларның), тулы бер халыкның кечкенә бер өлешен тәшкил иткәнлектән барлыкка килүе турында яза. Бу мәгънәдә атаманың угыз-төрекмәннәрнең *учок, онок, бозок* кебек кабилә берләшмәләре исемнәре составында саклануына да игътибар итела [Atanyýazow, с. 255].



*Ок* сүзе сәлҗукларда һәм гомумән төрки телле халыкларда кабиләне аңлата дидек. О. Гундогдыев кабиләнең 5 тармактан, тармакның 5 ыругтан, һәр ыругның 30 гаиләдән торуына игътибар итә. Төрле заманнарда төрекмәннәрнең ата-бабаларында «30» саны «тармак», «ыру», «кабилә», «берләшмә», «адми-

нистратив бүленеш» дигән мәгънәләрдә кулланылган [Гундогдыев, 2007].

Борынгы һәм Урта гасырлардагы барлык эре төрки телле халыкларның дәүләт идарәсендә кабиләләр һәм ырулар *ок* дип аталган. «*Ок*» – ук мәгънәсендә, «ок» – кабилә һәм ыруг мәгънәсендә омонимнар булган. Аннан соңгы төрки җәмгыятьләр дә ике берләшмәгә бүленә башлый: *толос* (уң төркем) *һәм тардуш* (сул төркем). Һәр кабилә ун мең сугышчыдан, ягъни бер туменнан (төмәннән) торган. Ә бу дәүләтнең хәрби-административ берәмлегенә туры килә [Гундогдыев, 2007].



Академик В. Гордлевский билгеләп үткәнчә, төрекмән-юрюкларда (терлекчеләрдә) бу кабилә утыз гаиләдән – «оҗак»тан торган, Рум сәлҗуклары, утыз укны бергә җыеп бәйләп, үз бәкләренә буйсынуларын белдергәннәр, янычарларда оҗак аларның гаиләсе сыйфатында кабул ителгән [Гордлевский, с. 51, 63]. Сәлҗук төрекмәннәре гаскәрләрендә сугыш вакытында, традиция буенча, һәр сугышчының 60 угы була: 30 кечкенә ук дошманга ату өчен, ә зур яссы тимер очлы 30 ук дошман угының җәя керешен кисү һәм атларга ату өчен каралган [Гундогдыев, 2003].

Бөек Сәлҗук империясе солтаннарының гербларына да җәя һәм ук рәсеме төшергәннәр, һәм бу бик тирән мәгънәгә ия булган. Гербны күргән һәр кеше төрекмәннәрнең әлеге уклар кебек гадел һәм куркусыз, шулай ук төрекмән дәүләте сәясәтенең кызу һәм сыгылмалы булуына инана ала [Karayew, б. 36]. Сәлҗуклар дәүләтенең сарай бизәү кагыйдәләрендә һәм дипломатия беркетмәсендә дәүләт символикасында балта, чукмар, кылыч, сөңге, аеруча җәя һәм ук сурәтләрен чагылдыруга зур игътибар бирелә [Göksu, 2010; 2008].

Сәлҗук солтаннары дипломатиясендә җәя һәм ук илче һәм илчелек атрибуты буларак кабул ителгән. Сәлҗук империясендә, илчеләр җибәргәндә, милли традицияләргә генә түгел, Көнчыгышта кабул ителгән традицион кагыйдәләргә дә таянганнар. Беренче атрибут булып ук торган, чөнки борынгы угыз традициясе буенча, илчеләр хөкемдарларның йөкләмәләрен үтәгәннәр, ягъни җәя, илчене – укны, кая гына җибәрмәсен, шул күрсәтелгән якка юнәлергә тиеш булган. Бу традициянең тамырлары бик борынгы чорларга барып тоташа. Тарихчы О. Гундогдыев язганча, әгәр патша бәкләр арасыннан чыккан икән, аның тамгасы – җәя. Дарийның Туранга яу чабуы тасвирланган борынгы риваятьтә (аны антик автор Ктесий теркәгән) болай диелгән: «Алар (фарсылар һәм скифлар. – О.Г.) бер-берсенә җәяләр җибәрделәр; скиф җәясе ныклырак булып чыкты. Шуңа Күрә Дарий качты» [Гундогдыев, 2003].

Сәлҗук солтаннары дипломатиясендә җәя ярдәм сорап мөрәҗәгать итү билгесе булып та торган. Газнәвиләр солтаны Мәхмүд Һиндстанга походка китешли Җәйхун ярында сәлҗуклар белән очраша һәм ант биреп ныгытылган килешү төзи. Язычи углының шәрехләренә караганда,

үзенең тылы турында борчылмас өчен, сәлҗук бәге Исраилдән Мәхмүд, әгәр ул Һиндстанга походта вакытта Хорасан халкы баш күтәрсә, моны ничек белдерергә, дип сораган. Исраил, кыныннан өч укның берсен тартып алып, Солтан каршына куйган да:

– Әгәр бу укны безнең кабиләгә җибәрсәгез, сезгә ярдәмгә йөз мең җайдак килеп җитәр, – дигән.

Солтан тагын сораган:

– Әгәр алар җитәрлек булмаса?

Исраил, тагын бер ук чыгарып:

– Әгәр бу укны Төркестан (Төрекмәнстанның) Балхан тауларына җибәрсәгез, сезгә ярдәмгә тагын йөз илле мең җайдак килеп җитәр,– дип әйткән.

– Әгәр болар да җитмәсә?

Исраил, җәясен Солтан алдына куеп, болай дигән:

– Бу җәяне Төркестанга җибәрсәгез, сезгә ярдәмгә хәтта ике йөз мең җайдак та килеп җитәчәк [Ýazyjy ogly Aly, с. 45–46].

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, укларга караганда җәянең миссиясе әһәмиятлерәк булган.

Сәлҗук солтаннары дипломатиясендә җәя илчелекләр кабул иткәндә дәүләт куәте символын белдерү өчен дә кулланылган. Мәлик шаһка солтан үзенең 50 *ман*[1] авырлыгындагы кистәнен һәм 10 ман авырлыгындагы кылычын тотып килгән Караханилар илчесен кабул иткәндә, Садретдин Хөсәени аңа Сәлҗук дәүләте куәте символы булган дәһшәтле җәя күрсәтә [Садр ад-Дин Али ал-Хусайни, с. 67]. Югарыдагы мисалларны китереп, В.В. Тишин җәянең корал һәм хакимият символы функцияләрен үтәвен ассызыклый [Тишин, с. 181].



Угыз мәдәниятендә һәм угызларның милли традицияләрендә җәя һәм уклар мөстәкыйльлек символы буларак чыгыш ясый. Угыз хан һәм сәлҗукларның нәсел дәвамчылары дәүләт символикасында җәя һәм ук аерым урын алып тора. Моңа нисбәтле Сәлҗукның атасы, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм гаскәр башлыгы Дукак Демиряйлиның исемен атау урынлы булыр [Turan Refik, s. 27]. Сәлҗукларның хәрби сәнгате турындагы атаклы «The Course of Empire: The Arabs and Their Successors» дигән китабында Британиянең күренекле генерал-лейтенанты Джон Багот Глабб (John Bagott Glubb, 1897–1986) болай дип яза: «При изложении крупных войн в истории человеческого развития изобретение ранее невиданных новых оружий и их использование в соответствующие периоды написаны отдельной страницей. Эти оружия привели к коренному изменению ранее действовавших боевой тактики и способов ведения боя и падению изживших себя империй. В этом отношении на ум приходят греческие фаланги, римские

[1] 1 ман = 812,50 г.

легионы, крестоносцы в бронях, пушки, танки, самолёты, ядерные ракеты и другие. Однако роль и значение конных лучников, пробившихся из центральноазиатских равнин в конце первого тысячелетия, стоит выше всех остальных в преобразовании истории. Здесь я хочу вспомнить о туркменах и их боевом мастерстве» [Karaýew, s. 37].

Сәлҗук солтаннары дипломатиясендә урын алган җәя һәм ук нумизматика материалларында да чагылыш таба. Бу – борынгы Төрекмән дәүләтләреннән үк башлангыч ала. Җәянең хакимият символы булуын Бөек Парфия патшалыгы тәңкәләре дә дәлилли. Парфян тәңкәләренең аверсында төрекмән-парфян империясенә нигез салган Аршак I сурәтләнгән, ул кулына үзеннән аерылгысыз катлаулы җәясен тоткан [Гундогдыев, 2005; Пилипко, с.38]. Аршакларның тәңкәләрендә империянең алласы саналган ыру башлыгы сурәтләнгән. Аның да кулында ук. Археолог Һ. Йосыпов моны «ук кулында булганда аңа бернәрсә дә куркыныч булмый», дип аңлата. Тарихчы О. Гундогдыев Ниса шәһәрендә табылган мөһер эзләрендә җәя һәм уклы аучылар сурәтләнүе турында яза, алар ритоннарда да очрый.

Иске Нисада табылган тышлау плитәләрендә сурәтләнгән ук кынысы ук өлгесен символлаштыра (парфяннарда ук кынысы булмаган). Ук кынысының кесәсенә уклар каурыйларын өскә каратып тыгылган. Бу (җәя һәм ук) – парфян сугышчыларының тамгасы буларак кабул ителә [Гундогдыев, 2005].



Сәлҗук тәңкәләрендә[1] һәм истәлек билгеләрендә җәя һәм ук сурәтләре булган [Агаджанов, 1973, с. 13; Ходжаниязов, Табл. I–V]. Аларда угызларның *каи* һәм *баят* кабиләләре тамгалары арасында охшашлык сизелә [Агаджанов, 1964]. Әл-Бундари язуынча, тәңкәләрдә очрый торган кәкре ук сурәтләре [Ходжаниязов, Табл. I–V], Тугрылбәк заманыннан башлап җәя һәм укның гадиләштерелгән сурәте булып тора [Тишин, с. 175–188].

Ук белән җәя угызларның ике катлавын белдергән. Җәя *бозокны* (эре кабиләләрне), ә ук *учокны* (аларга буйсынган вак кабиләләрне) символлаштырган [Рашид ад-Дин, т. 1, с. 86–90; Кононов, с. 48–51]. Рәшидеддин *кынык* кабиләсенең *бозакка* (ягъни сул канатка) буйсынган *учокка* керүен хәбәр итә [Тишин, с. 184]. Без нәкъ менә дуалистик принципның дәүләт идарәсе дипломатиясенә һәм сәлҗук солтаннары беркетмәсенә турыдан-туры йогынты ясавын ассызыкларга телибез. Галим С. Г. Агаджанов фикеренчә, җәя белән ук «ук-герб-угыз» термины белән үзара бәйләнгән, борынгы угыз берләшмәсендә нәкъ

[1] Азәрбайҗан галиме Р.А. Гусейнов Рейада эре Монетный двор булуы турында яза [Гусейнов, с. 37].

менә җәя һәм ук сурәте аеру билгесе булып саналган [Агаджанов, с. 13].

Сәлҗукларның дәүләт идарәсе беркетмәсендә җәя һәм ук дипломатия документларын раслау өчен дә кулланылган. Чыганаклардан билгеле булганча, Тугрылбәк 1049–1050 елларда Византия белән килешүне раслау өчен җәя һәм ук сурәте төшерелгән мөһерен куя. 1055 елдан башлап ул солтан гербына әйләнә [Cahen, с. 84, 92, 101]. Сәлҗуклар мөһерендә генә түгел, башка төрки телле халыклар ханнары мөһерләрендә дә ук сурәте бар. Ул документлар ролен дә үтәгән, гаскәр җыю турында хәбәр буларак та кулланылган, хакимият символы да булган. Саклар җәя белән укны чит ил хөкемдарларына җибәргәннәр. Сәлҗук солтаннарының мөһере еш кына балдак рәвешендә булып, Солтан аны һәрвакыт кулында йөртә, кирәк вакытта, салып, мөһерен куя, документны раслый [Курбангельдыев, с. 59].

Ктесий сакларның Дарийга җәя җибәрүләре турында сөйли, ә Геродот сакларның Дарийга ук җибәрүләрен әйтә. Сакларның бу традициясе төрки-монгол халыкларында сакланып калган [Гундогдыев, 2003]. Монгол ханы Мәнгү Европа хөкемдарларының берсенә зур җәя һәм ике ук җибәрә. Бу җәяне икәүләшеп тә киерә алмаганнар. Хан үзенең илчесенә шундый йомыш кушкан: «Франклар короле янына сине монах Вильгельм де Рубрук илтәчәк. Һәм аңа минем исемнән менә шуларны бирерсең. Әгәр ул безнең белән татулашырга теләсә, без аның биләмәләренә кадәр сарациннарның җирләрен яулап алырбыз, калган җирләрне (көнбатышка кадәр) аңа бирербез. Баш тарткан очракта, җәяне дә, укларны да кире кайтарып бир һәм безнең мондый җәядән еракка атуыбызны һәм җимергеч һөҗүм ясавыбызны әйт» [Путешествия, с. 127].

XIII гасыр ахыры Сурия авторы Әбел-Фараҗ бар Әбрәй хәбәр иткәнчә, солтан дип игълан ителгәннән соң, Тугрылбәкнең җәя һәм ук төшерелгән гербы хәлифә биргән тагын өч символ белән тулыландырыла [Gregory Abû'l Farac (Bar Hebraeus), t. 1, s. 305]. Керман сәлҗуклары хөкемдары Курт, абыйсы Алып-Арысланның вафатыннан соң, хөкемдар атрибуты булган патша кулчатырына сәлҗуклар династиясе символы сыйфатында җәя һәм ук урнаштырган [Тишин, с. 127].

Сәлҗук дәүләтләре солтаннары дипломатиясендә җәя һәм ук белән беррәттән *кистән* дә кулланылган. Рум сәлҗукларның сарай тарихчысы Мөхәммәд Равенди Тугрылбәкнең тамгасы пумала рәвешендә булган, дип яза [Материалы, т. 1, с. 353]. Фарсылар традициясендә кистән каһарманнар, ханнар, бәкләр коралы булып саналган. Газнәви дәүләте гаскәрләрендә ул корал буларак та, йола чараларында да актив кулланылган. Сарай сакчылары кыска сөңгеләр тагып йөргәннәр. Өстәвенә сөңге аларга сарайда биш ел хезмәт иткәннән соң гына бирелгән. XIII гасыр башында Дәһли солтаны, төрекмән кешесе Котбеддин Айбәк өчен төзелгән хәрби трактат авторы Фәхри Мөдәббир кистәннең куркусызлар коралы булуын ассызыклый. Кистәннең панцырь кигән дошманны аптыраШта калдыру өчен кул-

ланылган башка төрләре дә булган [Адаб ал-харб ва-ш-шуджаат, с. 353].

Кистән рум сәлҗукларында да популярлык казанган. Сәлҗукларның ыру башлыгы Дукак хәзәрләр патшасын, кистән белән сугып, атыннан егып төшергән [Тишин, с. 178–179]. Төрекмән сынчылары Сәлҗук дәүләтенең барлык солтаннарын кулларына җәя, ук һәм кистән тоттырып сурәтли. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, моның очраклы булмавы турында нәтиҗә ясарга мөмкин.

Ибн Әсир 1056 елда хәлифә кызы белән Чагрыбәкнең туенда Тугрылбәк вәзире Амидо әл-Мөлк Кундуриның кулында кистән булган дип яза [Амбарцумян]. Монда, һичшиксез, вәзир кистәнне хакимият символы буларак йөрткән. Ибн Әсир һәм Ибн Җәүзи карашынча, Малазгирт сугышы иң кызган вакытта Алып-Арыслан җәясен читкә ыргыта һәм кулына кистән ала. Алып-Арыслан алган яраларыннан һәлак булгач, аның янындагы постельничий (фарраж) үзенең кистәне белән бәреп, хыянәтчене аптыраштa калдыра [Тишин, с. 179–180]. Моннан күренгәнчә, солтан гына түгел, аның даирәсендәгеләр дә, хөкемдарны яклау һәм саклау өчен, җәя кебек ук, кистән белән дә коралланганнар.

Француз галиме К. Каэнның Сәлҗук дәүләте гербының вазифасы турындагы карашларын тәнкыйтьләгән төрек галиме М.А. Коймен бу мәсьәләне төрекләр тарихыннан аерып карарга ярамавын искәртә. Ул, Ф. Кёпрюль фикерләрен үстереп, солтаннар гербы семантикасының төрек тарихының борынгы чорларына барып тоташуын һәм җәянең хакимият символы булуын билгели [Köymen, 1949]. О. Туран сәлҗукларның ыру башлыгы Дукакның «Демир яйли» (тимер җәяле) дигән кушаматын Сәлҗук дәүләте гербындагы сурәт белән бәйли [Turan, 2010; Göksu, 2010].

К.Э. Босворт үзенең «Ислам энциклопедиясе»ндә чыккан мәкаләсендә Ф. Кепрюль һәм О. Туран китергән кистән Тугрылбәкнең гербы булган, дигән гипотезаны алга сөрә [Bosworth]. Британия музее сайтында Тугрылбәк заманында кистән һәм җәя рәсеме төшерелгән тәңкәләрне күрергә мөмкин [Dinars]. 1038 елны Тугрылбәкнең биленә ук кынысы, иңбашына җәя асып Нишапурга керүе турындагы мәгълүматлар җәянең хакимият символы булуын күрсәтә. Бар Эбрей тәхеттә утырган Тугрылбәк алдында зур җәя ятканын һәм солтанның, бер үк вакытта ике ук тотып, алар белән оста эш итүе турында яза [Тишин, с. 178]. Җәя, ягъни бәкләр һәм уклар, кабиләләр белән җитәкчелек итүче идарәче, дипломатия атрибутларын сакларга кирәк булганда, ук һәм җәядән файдаланган. Бәйхаки сүзләренчә, 1038 елда Нишапурда тәхеткә утырганда: «...Бөек Сәлҗук империясенең беренче солтаны Тугрылбәкнең җилкәсендә кереше киерелгән җәя, биленд дә өч ук булган» [Байхаки Абу-л-Фазл, с. 676].

Сәлҗук дәүләте солтаннары дипломатиясендә җәя белән ук илчесез, ягъни турыдан-туры хәбәрче функциясен үтәгәннәр. Сарай писерләренең Санҗар солтан Хазарасп кирмәнен камаганда, Харәзем

шаһы Атсызны буйсындыру өчен, ук белән хат җибәрүе шул хакта сөйли. Җувәйнинең «Дөнья хакиме тарихы» китабында 1147 елның ноябрендә Санҗар солтан Харәземгә өченче тапкыр яу чапканда сарай шагыйрьләре һәм писерләренең үткен сүзлелектә ярышуы турында мөһим мәгълүмат китерелә: «Әнвәри шул походка багышланган бер робагый иҗат иткән һәм аны Санҗар солтанга күрсәткән»:

И шаһым, бөтен дөнья байлыгы синеке,
Дәүләтебез, язмышларыбыз синеке.
Бүген Хазараспны буйсындыр, иртәгә,
Харәземнең меңнәрчә чапкыны синеке.

[Janbekow, с. 174–175; Atamälik Juweýni, с. 361–362]

Бу робагый солтанга бик ошаган. Шуңа күрә Санҗар солтан боерыгы белән ул кәгазьгә күчереп язылган һәм ук белән кирмәнгә җибәрелгән. Харәзем нөкәрләре бу хатны шунда ук Атсызга күрсәткәннәр. Ул вакытта Әнвәринең робагыена Атсыз янындагы шагыйрь Рәшидетдин Ватват болай дип җавап биргән:

Әгәр синең шахың Рөстәм кебек безгә килсә,
Ишәк ала алса, аңа – мактау һәм дан.

[Janbekow, с. 174–175; Atamälik Juweýni, с. 361–362]

Үз чиратында, Харәзем шаһы Атсыз бу җавапны ук белән Санҗар солтан гаскәренә тарафына җибәрә. Җавапны шунда ук Санҗар солтанга тапшыралар һәм аны шагыйрь Ватват язганлыгын әйтәләр. Бу тапкыр җавап Санҗар солтанны чыгырыннан чыгара. Ул хәтта ачуыннан, кулга төшерә алса, аны ботарлап ташларга ант итә [Resided in Wet wet, с. 174–175; Köymen, 2011, с. 347; Atamälik Juweyni, с. 361–362]. Ниһаять, Санҗар солтан Хазараспны басып ала. Ватват, солтаннан куркып, озак вакытлар качып ята. Ахыр килеп, Санҗар солтан канцеляриясе башлыгы Мөнтәҗибеддин бады ибн Әхмәд арадашлыгы һәм ярдәме белән үлемнән котыла [Janbekow, с.174–175; Atamälik Juweýni, с. 361–362].

Җәя һәм ук символикасы Бөек Сәлҗук империясенең дипломатия беркетмәсе һәм этикетында ныклы урын алган. Сәлҗукларда дипломатия беркетмәсе һәм этикетның системалаштырылган кагыйдәләре һәм гореф-гадәтләре эшләнгән. Алар Бөек Сәлҗук империясенең дәүләт идарәсе системасы белән бергә камилләшә барганнар.

XI гасырның 60 нчы елларында дәүләт канцеляриясендә гражданлык, суд һәм башка вазифаларның конкрет иерархиясе формалаша. Сарай этикеты кертелә, сарай хезмәткәрләре аны үтәргә тиеш була [Буллет, с. 97, 103]. Беренче сәлҗук хөкемдарлары гербында югары хакимиятне символлаштырган җәя һәм ук сурәтләре була. Ул указларга һәм башка рәсми хатларга куелган. Һәм һәр солтанның (яки мәликнең) үз гербы булган [Агаджанов, 1973, с. 12; The Cambridge History, с. 88, 257, прим. 1]. Иншаа-канцеляриядән чыккан документларга герб сурәте куелган.

Урта гасыр чыганаклары раслаганча, сәлҗуклар яу алдыннан, канкойгыч сугышларны булдырмас өчен, җәя һәм ук символикасын превентив дипломатия чарасы буларак файдаланганнар. Мәсәлән, Ибраһим Йынал үзенең гаскәре белән Нишапурга якынлашкач, 1038 елның 10 июнендә әлеге шәһәр хакименә үзенең илчеләрен җибәрүе – моның ачык мисалы. Сәлҗукларның илчеләре шәһәр халкына, әгәр бирелсәләр, үзләренә дә, мал-мөлкәтләренә дә тимәячәкләрен, каршылык күрсәтсәләр, күпсанлы гаскәр белән килүче Тугрылбәкнең аларны бөлгенлеккә төшерәчәген җиткергәннәр. Сәлҗуклар бу очракта, дипломатияне эшкә җигеп, шәһәрне сугышсыз һәм кан коюларсыз гына алмакчы булганнар. Газнәвиләр башбаштаклыгыннан йончыган Нишапур халкы сәлҗукларга буйсыну турында карар кабул иткән.

Ибраһим Йынал Тугрылбәкнең халыкка карата гадел мөнәсәбәттә булачагын гарантияләгән һәм шәһәрдә Тугрылбәк хөрмәтенә «Бөек Солтан» исеменә догалар укырга кушкан [Muhammet Gaýmaz Türkmen, с. 110]. Ун көннән соң Тугрылбәк үзенең 3 мең атлы гаскәре белән шәһәргә кергән. Сугышчыларның киеме генә түгел, атларның бөркәнчекләре дә тимер пластиналар белән тышланган булган. Бәйхаки мәгълүматларына караганда, Тугрылбәк Мәсуд тәхетенә утырган [Агаджанов, 1991, с. 50–51, 239; Бартольд, с. 368]. Аның өстендә Мәрвә ефәгеннән тегелгән соры чикмән, аякларында киез итек, башында юка тукымадан чалма булган. Ул җилкәсенә җәя асып, билбавына уклар таккан. Нишапурның барлык мәчетләрендә дә аның хөрмәтенә дога укый башлаганнар. Икенче көнне солтан чатырда шәһәрнең хөрмәтле кешеләрен кабул иткән. Ул аларның барысын да игътибар белән тыңлаган һәм киңәшләр биргән [Заходер, с. 141].

Сәлҗук дәүләтләре солтаннары дипломатиясендә зур урын алган җәя һәм ук, ук кынысы *(сагдак)* сурәтләре төрекмәннәрнең келәм сәнгатенә дә күчкән. Безнең Герой-Аркадагның «Тере легенда» дигән китабында болай диелә: «Дөрес, кайберәүләргә “сагдак” – “ук кынысы” сүзе белән җиткерелгән башка ассоциация ошый: җәянең нык итеп тартылган кереше һәм киңлек белән вакытны тишеп очкан уклар» [Berdimuhamedow, с. 324].

Шулай итеп, югарыда китерелгән конкрет мисалларда ук һәм җәянең, төрекмән халкының данлы җиңүләрен символлаштырган хәрби корал буларак, дәүләт символикасында, тышкы сәясәттә һәм дипломатиядә, изге төшенчәләр сыйфатында, изүгә каршы һәм сугышны булдырмау чарасы сыйфатында кулланылуын күрергә мөмкин.

Төрекмәнстан Министрлар Кабинетының киңәйтелгән утырышында кабул ителгән «Төрекмәнстан Тышкы эшләр министрлыгының Халыкара мөнәсәбәтләр институты эшен камилләштерү турында» безнең Герой-Аркадагның 2021 елның 9 июлендәге 2318 номерлы карары нигезендә институтта Яшь дипломатлар мәктәбе ачылды. Илебез мәктәпләре укучылары арасында талантлы яшьләрне ачыклау,

булачак дипломатларны урта мәктәптә укыганда ук әзерләү эшен координацияләү максатыннан, «Дөньяның яшь хәбәрчеләре» дип аталган интеллектуаль конкурсның 1 нче сайлап алу турының 8 уены үткәрелде, ярымфинал уеннарында катнашкан 16 укучы билгеләнде.

2022 елның 18 июнендә «Безнең Герой-Аркадагның бөек тәгълиматы: "Диалог – тынычлыкка гарантия"» темасына йомгаклау финал уеннары үткәрелде һәм җиңүчеләр билгеләнде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бу уеннарның төп эмблемасы итеп Угыз ханның ук һәм җәя сурәтләре алынды, чөнки җәя – дәүләтне, ә ук илчене аңлата [Корбангельдыев, с. 67].

Югарыда билгеләп үтелгәнчә, ата-бабаларыбызның изге символларыннан Угыз ханның ук һәм җәя сурәте тирән мәгънәгә ия һәм төрекмән дәүләтенең тынычлык урнаштыру эшчәнлеге һәм динамикалы дипломатиясе турында сөйли. Безнең яшьләр бу символны зур горурлык хисе белән йөртәләр һәм илчедән таләп ителгән дөреслек һәм куркусызлык гыйлемен, төрекмән дәүләтенең ашкынучан, төрле яклап уйланган һәм сыгылмалы сәясәте сабакларын тирәнтен үзләштерәләр.

**Әдәбият**

*Berdimuhamedow G.* Janly rowaýat. A.:TDNG. 2011. 324 c.

*Выступление* Президента Туркменистана Сердара Бердымухамедова на Консультативной встрече глав государств Центральной Азии // Нейтральный Туркменистан. 2022. 22 июля.

*Абуль-Гази-хан.* Родословное древо тюрков / пер. Г. Саблукова // Экспериментальный номер журнала «Ашгабат». 1994. № 7.

*Агаджанов С.Г.* Государство Сельджукидов и Средняя Азия в XI–XII вв. М.. 1991.

*Агаджанов С.Г.* Огузская проблема и задачи её изучения. Тюркологический сборник. 1973. М. 1975.

*Агаджанов С.Г.* Уникальная медаль с изображением сельджукидского султана Мухаммада Тогрул-бека // Известия АН ТССР. Серия общественных наук. 1964. № 4. С. 10–16.

*Адаб ал-харб ва-ш-шуджаат* (Правила ведения войны и мужество) / пер. Дж. Наджмутдиновой и С. Шохуморова. Душанбе. 1997.

*Alimcan M.* Selçuklu Veziri Amidülmülk Kündürî'nin Yükselişi ve Düşüşü // The Journal of Academic Social Science. 2014. № 29. 244 s. dipnot 33.

*Амбарцумян А.А.* Некоторые военные реалии по данным древнейшего фрагмента иранского эпоса («Айадгар и Зареран» – «Сказание о Зарере») // Оружие и военное дело в исторической и социальной перспективе. Материалы Международной конференции 2–5 сентября 1998. СПб. С.72.

*Atanyýazow S.* Türkmen diliniň sözköki (etimologik) sözlügi. A.: Türkmenistanyň milli medeniýet «Miras» merkezi. 2004.

*Aydın Taneri.* Büyük Selçuklu İmparatorlugu'nda Vezîrlik. TAD., C:V, sa. 8–9. Ankara 1967. S. 97–163.

*Байхаки Абу-л-Фазл.* История Масуда (1030–1041) / пер. с перс. А.К. Арендса. М., 1969.

*Бартольд В.В.* Сочинения. Т. I. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. М., 1963.

*Bosworth C.E.* Deny J., Siddiq M.Y. Tughra // Encyclopaedia of Islam. New Edition / Ed. by P. Bearman, Th. Bianquis, C.E. Bosworth, E. van Donzel and W.P. Heinrichs. Leiden, 2000. Vol. X. T – U. P. 595.

*Буллет Р.В.* Религиозно-политическая история Нишапура в XI в. Мусульманский мир. 950–1150. М., 1981.

*Cahen C.* La tuğrā seljukide // Journal Asiatique. 1943–1945. T. CCXXXIV. P. 167.

Dinars of Toghril Beg and Malik Shah. URL: http://www.britishmuseum.org/explore/highlights/highlight_objects/cm/d/dinars_toghril_beg,_malik_shah.aspx (мөрәҗәгать итү көне: 08.01.2015).

*Доватур А.И., Каллистов Д.П., Шишова И.А.* Народы нашей страны в «Истории» Геродота. Тексты. Перевод. Комментарий. М.. 1982. С. 103.

*Гордлевский Вл.* Государство Сельджукидов в Малой Азии. М.- Л.. 1941.

*Göksu E.* Ok ve Yayın Türk Devlet Geleneği ve Hakimiyet Anlayışındaki Yeri // Turkish Studies / Türkoloji Araştırmaları. 2010. Vol. 5/2. C. 986–1011.

*Göksu E.* Türkiye Selçuklularında Ordu: Gazi Üniversitesi Sosyal Bilimler Enstitüsü, Yayınlanmamış Doktora Tezi. Ankara. 2008.

*Gregory Abû'l Farac (Bar Hebraeus).* Abû'l Farac Tarihi / Süryancadan İngilizceye çev. E.A. Wallîs Budge; Türkçeye çev. Ö.R. Doğrul. 3. bk. Ankara, 1999. Cilt 1.

*Гундогдыев О.А.* Военно-социальная структура у туркмен в эпоху средневековья // Мирас. № 1. 2007.

*Гундогдыев О.А.* Культ оружия у туркмен // Мирас. 2003. № 3.

*Гундогдыев О.А.* Лук и стрела // Асхабад. 1999. 25 марта.

*Гундогдыев О.А.* Ударно-пробивное дистанционное оружие у туркмен (лук и стрелы) // Мирас. 2005. № 3.

*Гусейнов Р.А.* Современное состояние и ближайшие задачи изучения сельджукской проблемы. Тюркологический сборник. 1973. М., 1975.

*Заходер Б.Н.* Хорасан и образование государства сельджуков // Вопросы истории. 1945. № 5–6.

*Janbekow K.* Ötgür sözüň ussady // Ymam Fadyl Reşideddin Watwat. Resmi hatlar. Terjime eden we çapa taýýarlan Kakajan Janbekow. Aşgabat: Miras. 2004. C. 174–175.

*Karaýew B.* Dünýä nusgalyk ýol goýanlar. // Milli goşun. № 1. 2022.

Kaşgarly Mahmyt. Türki dilleriň diwany (Diwany lugatyt-türk). A.:TDNG. 2022.

*Кононов А.Д.* Родословняя туркмен. Сочинение Абу-л-Гази, хана Хивинского. С. 48–51.

*Köymen M.A.* [Yayımlar Arasında]: Journal Asiatique CCXXXIV (1943–1945). C. 479; CCXXXV (1946–1947). C. 203; CCXXXVI (1948). C. 335 // Ankara Üniversitesi Dil ve Tarih-Coğrafya Fakültesi Tarih Bölümü, Tarih Araştırmaları Dergisi. 1949. Cilt VII. Sayı 2. C. 503–504.

*Köymen M.B.* Büyük Selçuklu imparatorluğu tarihi. C. II, İkinci imparatorluk devri. TTK yay., Ankara. 2011.

*Кузьмина Е.Е.* Древнейшие скотоводы от Урала до Тянь-Шаня. Фрунзе. 1986.

*Курбангельдыев Дж.* Роль лука и стрелы в сельджукской дипломатии // Мирас (Наследие). 2022. № 4. С. 67.

*Lambton A.K.S.* The Internal Structure Of The Saljuq Empire // The *Cambridge* History of Iran, C:V. Cambridge 1968. C. 203–282.

Материалы по истории туркмен и Туркмении. М.-Л., 1939. Т. I. VII–XV вв. Арабские и персидские источники.

*Meryem Gürbüz.* Hârizmşahlar’da devlet teşkilâti, ekonomik ve kültürel hayat. İstanbul. 2005.

*Muhammet Gaýmaz Türkmen.* Taryhdaky yslam döwletleri. Aşgabat: Türkmenistanyň milli medeniýet «Miras» merkezi. 2006.

*Orazsähedow D.* «Lubabul-Elbab» tezkiresi IX–XII asyrlar türkmen edebiýatyny öwrenmegiň çeşmesi hökmünde. Filologiýa ylymlarynyň kandidaty alym derejesini almak üçin kandidatlyk dissertasiýasy. Aşgabat, 2017.

*Пилипко В.Н.*Старая Ниса. Здание с квадратным залом. М., 1996.

Путешествия в восточные страны Плано Карпини и Гильома де Рубрука. Алматы. 1993.

*Рашид ад-Дин Фазлаллах.* Огуз-наме / пер. с перс. Р.М. Шукюровой. М., 1991.

*Рашид ад-Дин.* Сборник летописей. Т. I, кн. I. М.-Л., 1952.

Reşideddin Watwat. Resmi hatlar. A. 2004.

*Садр ад-Дин Али ал-Хусайни.* Ахбар ад-даулат ас-сельджукийа / пер. З.М. Буниятова. М., 1980.

*The Cambridge* History of Iran. Vol.V. The Saljuq and Mongol Periods. Cambridge. 1968.

*Тишин В.В.* К вопросу о происхождении тугры сельджукских султанов // Transcaucasica / Транскавказика. Южный Кавказ: история, религия, общество. М.: МБА. 2016. Вып. 3 / сост. З.В. Кананчев.

*Turan O.* Selçuklular Tarihi ve İslâm-Türk Medeniyeti. 2. bk. İstanbul. 1969.

*Turan O.* Ok ve Yayın Türk Devlet Geleneği ve Hakimiyet Anlayışındaki Yeri // Turkish Studies / Türkoloji Araştırmaları. 2010. Vol. 5/2. C. 305–318.

*Turan Refik.* Selçuklu Tarihi El Kitabi. Grafik Yayinlari.

*Ходжаниязов Т.* Каталог монет государства Великих Сельджуков. Ашхабад. 1979. Табл. I, 2–4, 6–13, 15–18, 20 – 24, 26, 27, 36–38, 42, 49–51, 53–56, 58, 60–62, 66; табл. II, 79; табл. III, 140, 147, 148; табл. IV, 256, 257; табл. V, 283.

*Ýazyjy ogly Aly.* Seljuk türkmenleriniň taryhy. I j. Aşgabat: Türkmenistanyň milli medeniýet «Miras» merkezi. 2004.

عباس اقبال. وزارت در عهد سلاطین بزرگ سلجوقی. تهران. ۱۳۳۸. ص.: ۲۲-۳۲ Abbas İkbal, Vezâret der ahdi Selâtîn-i Büzurg-i Selcukî. Tahran 1338 . S. 22–32.

اقبال، عباس. وزارت در عهد سلاطین بزرگ سلجوقی. تهران. 1338. ص:18.

عطاملک جوینی، علاءالدین. تاریخ جهانگشای جوینی. به تصحیح محمد قزوینی. تهران. انتشارات هرمس، 1387. ص.: 361-362. *Atamälik Juweýni*, Alaeddin. Tarihe jahangoşaýe Juweýni. Tähran, Hermes neşirýaty. 1387. C. 361–362.

***Курбангельдыев Джумамурад Шамурад улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Төрекмәнстан тышкы эшләр министрлыгының Халыкара мөнәсәбәтләр институты ректоры*

УДК 398.8

*Э.М. Галимова*

# ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫН ӨЙРӘНҮ ЫСУЛЛАРЫ ЭВОЛЮЦИЯСЕ

В данной статье автор отмечает разные этапы формирования научной мысли в области изучения музыкального фольклора татар, а именно акцентирует внимание на используемые методы исследователей в вопросе изучения татарских народных песен, тем самым систематизируя научно-практические материалы, выстраивает линию эволюции в данной проблематике. Также в работе автора отражено усиление внимания в исследованиях учёных-этнографов в сторону этнокультурных и этнических таксонов, с выделением в этнографических группах «генетических» и «территориальных» типов.

**Ключевые слова:** татарские народные песни, музыкальный фольклор, казанские татары, волжские татары, этнографические группы.

In this article the author notes the different stages of the formation of scientific thought in the field of studying Tatar musical folklore namely focuses on the methods used by researchers in the study of Tatar folk songs thereby systematizing scientific and practical materials, builds a line of evolution in this area. The author's work also reflects the increased attention in the research of ethnographers towards ethnocultural and ethnic taxa with the allocation of "genetic" and "territorial" types in ethnographic groups.

Keywords: Tatar folk songs, musical folklore, Kazan Tatars, Volga Tatars, ethnographic groups.

Урта Идел һәм Урал Буе татарлары музыкаль фольклорының язма һәм ноталы транскрипциясе тарихы гасыр ярым вакыт аралыгын үз эченә ала. Фәнни әдәбиятта әлеге территориаль зонада яшәүче татарлар төрлечә атала: «Идел-Кама төбәге инородецлары», «Идел-Урал татарлары», «Урта Идел татарлары», «Идел-Кама татарлары» һ. б.

Шунысы бик мөһим, җыентыкларның басылып чыгуы 1877 елда Император Казан университеты каршында фәнни җәмгыять – Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте ачылуга бәйле. «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә археологик, антропологик, тарихи-этнографик хисаплар, очерклар белән бергә татар музыкаль этнографиясе буенча хезмәтләр дә актив рәвештә дөнья күрә башлый.

Әлеге хезмәтләрдә фәнни тикшеренүләр генә түгел, татар җырларының В.М. Мошков [Мошков, 1897], И.А. Козлов [Козлов, 1928] кебек рус музыкантлары тарафыннан эшләнгән ноталы үрнәкләре дә урын ала. Татар һәм башкорт музыкаль фольклорын өйрәнүгә А.Н. Римский-Корсаковның шәкерте С.Г. Рыбаков та сизелерлек өлеш кертә [Рыбаков, 1897]. 1913 елда профессор В.А. Богородицкий җитәкчелегендә эксперименталь фонетика кабинеты ачылганнан соң, һәм алга таба фәнни тикшеренү эшен тагын да киңәйтүне күздә

тотып, фонограф кулланыла башлый. Биредә җырларның ноталы җыентыгы әзерләнә һәм нәшер ителә [Берг, 1923]. Чит ил галимнәре Р. Лах һәм Г. Шюнеманның [Сайдашева, 2010 с. 12–148] фонографик язмалары да шунда басылып чыга.

Әйтергә кирәк, XX гасыр башында татар музыкантлары арасында да милли җырларны җыю эше белән кызыксыну көчәя: аноним авторның «Төрек-татар көйләре» җыентыгы [Төрек-татар көйләре, 1919], Мәскәү консерваториясен тәмамлаган флейтачы М.И. Солтанов [Султанов, 1916] һәм мәгърифәтче, фольклорчы С.Х. Габәши [Макаров, 2002] хезмәтләре.

XX гасырның икенче яртысында татар музыкаль фольклор үрнәкләрен җыю һәм өйрәнү өлкәсендә алга китеш күзәтелә. Әлеге эшчәнлек татар композиторлары А.С. Ключарев [Ключарев, 1986], М.А. Мозаффаров [Музаффаров, 1964], Җ.Х. Фәйзи [Фәйзи, 1971] исемнәре белән бәйле. Шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк: татар музыкаль фольклоры буенча алар әзерләгән җыентыклардагы материаллар күбесенчә казан татарларыныкы (үзәк регион) белән чикләнә.

XX гасырның икенче яртысыннан этнографларның хезмәтләрендә этнокультура һәм этник таксоннарны аерып чыгаруга игътибар арта [Этнокультурное..., 1991]. Аерым галимнәр этнографик төркемнәрне икегә – «генетик» һәм «территориаль» катламнарга бүлеп өйрәнергә тәкъдим итәләр [Кузеев, Моисеева, 1985, с. 98–100]. Нәтиҗәдә, этномузыкологлар да төрле татар этнографик төркемнәренең очраклы музыкаль фольклор язмаларын бастырудан туктап, максатчан эшли башлыйлар һәм төп игътибарны аерым этнотерриториаль ареалларга юнәлтәләр.

60–70 нче еллар чигендә бу эшчәнлек профессиональ этномузыкологлар Р.А. Исхакова-Вамба [Исхакова-Вамба, 1981], М.Н. Нигъмәтҗанов [Нигмедзянов, 1970; 1984; Нигъмәтҗанов, 1976], З.Н. Сәйдәшева [Сайдашева, Ярми, 1979] да кушылганнан соң, Идел-Урал татарларының этник һәм конфессиональ чикләре киңәебрәк китә. Алар төзегән җыентыкларга башка этнографик төркемнәргә караган фольклор материаллары да кертелә, аеруча Урта Иделдәге мөселман һәм керәшен татарларыныкы [Сайдашева, 2007, с. 173–176].

Татар фольклорын җыю һәм нотага төшерүдә татар фольклор этномузыкологы М.Н. Нигъмәтҗановның зур хезмәт куюын ассызыклап үтәргә кирәк. Ул бу өлкәдә утыз елга якын актив эшләп, 1970, 1976 һәм 1984 елларда татар халык җырларыннан торган өч җыентык бастырып чыгара. Аларда беренче тапкыр казан татарлары фольклорыннан тыш, Урта Идел татарлары (мишәр һәм керәшен татарлары) этнографик төркемнәренә караган материаллар да урын ала. Бу өч җыентыкның да нигезен экспедицияләр вакытында тавыш яза торган аппаратура ярдәмендә яздырып алынган материаллар тәшкил итә.

1970 елда нәшер ителгән җыентыкта төп урынны мишәр татарлары (Мордовия Республикасы, Пенза, Түбән Новгород өлкәләре) һәм керәшен татарлары (Татарстан Республикасының Мамадыш,

Алабуга, Питрәч, Балык Бистәсе районнары) компактлы яшәгән җирләрдә автор тарафыннан яздырып алынган аерым музыкаль фольклор үрнәкләре алып тора. Сирәк очрый торган музыкаль фольклор үрнәкләреннән Волгоград, Саратов, Әстерхан өлкәләрендә яшәүче татар этнофорларының язмалары да җыентыкта үз урынын тапкан. М.Н. Нигъмәтҗанов әлеге җыентыкның эчтәлеген күренекле татар фольклорчылары (Х.Х. Ярмөхәммәтов, Ф.И. Урманчеев, И.Н. Надиров), телчеләренең (М.З. Зәкиев, Н.Б. Борһанова, З.Р. Садыйкова) фонограмма архивларыннан мишәр һәм казан татарлары аерым фольклор үрнәкләренең ноталы транскрипцияләре белән, композиторлар (З.В. Хәбибуллин, И.Г. Шәмсетдинов, Җ.Х. Фәйзи) һәм музыка белгечләренең (Н.З. Мөштәриева) язмалары белән дә тулыландырган. Шулай ук ул анда Татарстан радиокомитетында профессиональ җырчылар Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Илһам Шакиров, Рәшит Ваһапов, Фәридә Кудашева, Таһир Якупов башкаруында яздырылган җырлар фоноархивыннан ноталы транскрипцияләрне дә керткән. Бу җыентыкларда берәр этнографик төркем (казан, мишәр, керәшен татарлары) яки алар эчендәге географик ареал фольклор үрнәкләрен тирәнтен өйрәнү максаты куелмый. Күрәсең, автор халык җырларын һәм инструменталь вариантта тәкъдим ителгән көйләрнең күбесен нотага төшерү бурычын куйган. Димәк, әлеге җыентыклар авторының төп максаты – музыкаль фольклор үрнәкләрен өйрәнүдән бигрәк, аларны популярлаштыру булган, дигән фикер туа. Нәтиҗәдә, «иҗтимагый-көнкүреш функциясе»ннән чыгып эш итү, төрле этнографик материалны бердәнбер классификациягә буйсындыру теләге уңышсызлыкка очрый, чөнки аны аерым этнографик яки этнотерриториаль төркемгә карата гына кулланып була [Нигмедзянов, 1970, с. 4]. Мондый системалаштыру жанрларны билгеләүдә шактый буталчыклык китереп чыгара. Өстәвенә авторның татарларның фәндә әлегә билгесез яңа этнографик катламнары музыкаль фольклорыннан хәбәрдар булмавы аңлашыла. Бу мәсьәләләр этномузыколог З.Н. Сәйдәшеваның әлеге җыентыкка багышланган рецензиясендә [Сайдашева, 1974, с. 8–14] яктыртыла.

Авторның икенче җыентыгында 1967–1972 елларда язып алынган музыкаль фольклор материаллары тупланган. Венгрия галимнәре Ласло Викар һәм Габор Берецки белән берлектә эшләгән экспедиция вакытында язып алынганнары да шунда кертелгән. Беренче җыентыктан аермалы буларак, Татарстан (Арча, Балтач, Кукмара, Мөслим, Минзәлә, Түбән Кама, Чаллы һ. б.) районнарында язып алынган материалларга киңрәк урын бирелгән. Җыентыктагы материалларны автор танылган совет фольклорчысы В.Е. Гусев классификациясенә нигезләнеп, *драма* (гаилә йолалары), *эпос* (бәет, дастан, мөнәҗәтләр), *лирика* (озын, салмак, кыска көйләр) төрләренә бүлә [Гусев, 1967].

Өченче җыентыкка материаллар сайлаганда М.Н. Нигъмәтҗанов шушы ук классификацияне нигез итеп ала. Әлеге басмага 1970 елларда Венгрия галимнәре белән берлектә, шулай ук 1977–1979 елларда

ТАССРның Арча, Балтач, Саба һәм Рязань өлкәсенең Касыйм районнарына оештырылган экспедиция материаллары кертелә.

Төрле елларда телчеләр Н.Б. Борһанова, З.Р. Садыйкова, музыка белгече Н.З. Мөштәриева тарафыннан Себердә, Киров, Пермь, Оренбург өлкәләрендә җыелган экспедиция язмалары әлеге җыентыкка кыйммәтле өстәмә була. Төзүче автор тәүге мәртәбә 1921 елда үзешчән музыкант С.В. Гаврилов тарафыннан язып алынган һәм үзе реставрацияләгән 10 керәшен татарлары җырын, шулай ук касыйм татарларының скрипкачы, фольклорчы Х. М. Гобәйдуллин (1935 елда вафат) теркәгән берничә җырын керткән. Беренче җыентыктагы кебек халык сәнгате интерпретаторлары Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Таһир Якупов һ. б. репертуарыннан ноталы җырларның транскрипцияләре дә урын алган. Шактый күләмле кереш сүздә бирелгән материалга музыкаль-стилистик анализ ясау омтылышы күзәтелә, «Татар музыкасы хакында тарихи мәгълүматлар» бүлеге дә игътибарга лаек.

Р.А. Исхакова-Вамба төзегән җыентык этнографик төркемнәргә бүленешкә нигезләнгән һәм өч бүлектән тора: 1) Казан татарлары җырлары; 2) мишәр татарлары җырлары; 3) керәшен татарлары җырлары. Әлеге басмага ике экспедиция дәвамында тупланган җырлар кертелгән. Беренчесе 1955 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фольклорчылары катнашында П. Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе тарафыннан (җырлар фонограф ярдәмендә язылган) оештырылган. Икенчесе И.Н. Надиров җитәкчелегендә ТАССРның Кайбыч һәм Подберезенский (хәзерге Апас) районнарында эшләгән. Касыйм татарларының 1934 елда Х.М. Гобәйдуллин тарафыннан язып алынган кайбер җырлары да шушы җыентыкта теркәлгән.

Р.А. Исхакова-Вамба икенче экспедициясен 1956 елда Татарстанның Кайбыч, Апас, Буа районнарына, шулай ук Мордовиянең Ләмбрә районына оештыра. Җырлар магнитофон тасмасына яздырыла. Экспедиция вакытында тупланган материалларны колачлаган җыентык «Казан татарлары халык җырларының көе» («Мелодика народных песен казанских татар») дип исемләнгән фәнни мәкалә белән ачыла. Җыентыкта өч бүлеккә таратылган материаллар төгәл бер системага салынмаган. Принципларга килгәндә, тарихи (революциягә кадәр язылганнары һәм совет чоры җырлары), жанр, тематика һ. б. принциплар кулланылган, теге яки бу этнографик төркемнең локаль үзенчәлекләре аерып бирелмәгән.

1970 еллар ахырында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының музыкаль фольклорны туплау өлкәсендәге хезмәте бәяләп бетергесез. Шулай ук шушы елларда язылган аналитик мәкаләләрне дә игътибарга алу зарур. Алга таба татар музыкаль фольклорны җыю эшенә, үз юнәлешен булдырып, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе дә кушыла. Бу өлкәдә Казан дәүләт консерваториясе профессоры, сәнгать фәннәре докторы З.Н. Сәйдәшева җитди эшчәнлек күрсәтә. 1972–1974 елларда

консерватория ректоры Н.Г. Җиһанов аны рус халык иҗаты курсын укытырга чакыра. З.Н. Сәйдәшева студентларны экспедицияләргә алып чыгып, музыкаль фольклор җыю һәм ноталы транскрипция язу эшенә тарта, практик дәресләр үткәрә. Бу эшкә ул елларда фольклор кабинетын җитәкләгән композитор Ш. Х. Шәрифуллин да кушыла. Шул рәвешле, Казан дәүләт консерваториясе студентларының музыкаль-этнографик практикасы башланып китә.

1989–2009 елларда Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә татар музыкасы кафедрасы эшли, 2003 елда этномузыкология кафедрасы ачыла. 1977 елдан бирле консерватория студентлары ел саен республикабыз районнарына чыгып, татар халкының музыкаль фольклорын җыю белән шөгыльләнәләр. Алай гына да түгел, музыка белгече, профессор З.Н. Сәйдәшева җитәкчелегендә җыелган материаллар кайбер студентларның диплом эшләренә нигез була (мәсәлән, А. Н. Кәримова, «Төмән өлкәсенең татар халык җырлары» («Татарские народные песни Тюменской области», 1982); Г.Х. Батюшова, «Ульян өлкәсе татарларының халык җырлары» («Народные песни татар Ульяновской области», 2000); Г. И. Трофимова, «Бакалы (Башкортстан) керәшеннәренең җыр мәдәнияты» («Песенная культура бакалинских кряшен (Башкортстан)»; 2003), Г. С. Зарипова, «Татарстанның Азнакай районы татарларының музыкаль мәдәнияте» («Музыкальная культура татар Азнакаевского района Татарстана», 2004); Л.Г. Садыйкова, «Әгерҗе районы җыр мәдәнияте» («Песенная культура Агрызского района», 2008) һ. б.).

Әлеге диплом эшләренең кайберләре диссертация дәрәҗәсенә үстерелеп, уңышлы якланды һәм фәнни әйләнешкә кертелде. Бу уңайдан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспирантлары музыка белгече Г.И. Трофимованың «Башкортстанның Бакалы районы керәшен татарларының җыр традициясе» («Песенная традиция татар-кряшен Бакалинского района Башкортостана», 2009) һәм композитор Э.М. Галимованың «Пермь татарларының традицион музыкаль мәдәнияте» («Традиционная музыкальная культура пермских татар», 2014) темаларына профессор З.Н. Сәйдәшева җитәкчелегендә якланган кандидатлык диссертацияләрен аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе алга таба да фольклор экспедициясе материалларыннан торган җыентыклар бастырып чыгаруны күздә тота. Әмма 2001 елда дөнья күргән «Нурлат районы халык җырлары» («Татарские песни Нурлатского района») җыентыгы белән бу эшкә нокта куела. Җыентыкка язган кереш тә З.Н. Сәйдәшева әлеге район авылларының җыр фольклорындагы үзенчәлекләргә игътибар итә. Биредә төрки гарузының традицион ритмнарына нигезләнгән борынгы *мөнәҗәт* жанрының кими баруы күзәтелә (1924–1925 елларда туган информантлардан нибары 15 көй язып алынган). Экспедиция нәтиҗәләреннән чыгып, бәет жанрының бик нык үзгәреш (трансформация) кичерүен билгеләп үтәргә мөмкин. Бу төбәктә бәетләрне җирле шагыйрәләр кайбер якташларының

фаҗигалы язмышларына багышлап язганнар, ләкин аларның нинди интонация белән, ничек башкарылачагы турында уйламаганнар. Алар аны бәет яки мөнәҗәт дип атаганнар һәм текстны уку белән генә чикләнгәннәр.

Этнофорлар репертуарында төп урынны җыр лирикасы алып тора. Җыентыкның кереш сүз авторы *озын көй, авыл көйләре, такмак* жанрларының бетә баруын билгеләп үтә. Бу экспедициядә әлеге жанрларның аерым үрнәкләре совет чорында үзешчән сәнгатьтә актив катнашкан өлкән буын вәкилләреннән язып алынган. Район яшьләре күбрәк Салават Фәтхетдинов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Айдар Галимов кебек популяр җырчылар репертуарындагы җырлар белән мавыга. Җыентыкны төзүче Р. Мифтахов, Т. Бадыйгин, З. Төхвәтуллина кебек җирле авторларны да атый. З.Н. Сәйдәшева яшьләр җырларына хас үзенчәлекне аерып чыгара: татар көйләре рус җырларының аерым элементлары, Көнбатыш Европа бию ритмнары, джаз музыкасы белән «сугарыла». «Массакүләм мәгълүмат чаралары актив рәвештә үскән чорда, төрле халыкларның музыкасын һәм стилен җиңел үзләштерү мөмкинлеге булганда, бу – котылгысыз күренеш» [Сайдашева, 2001, с. 15].

2002 елда З.Н. Сәйдәшева тарафыннан тагын бер җыентык әзерләнә. Әлеге басмада «Татар музыка сәнгате факультеты» студентлары тарафыннан 1998–1999 елларда Татарстан Республикасының Мамадыш районына оештырылган фольклор-этнографик практика вакытында җыелган материаллар кергән. Материаллар татар авылларында З.Н. Сәйдәшева, керәшен авылларында А.К. Шәрәфетдинов (фольклор музыкасы кабинеты мөдире) җитәкчелегендә җыела. Әмма бу җыентык район хакимиятенең матди ярдәме белән 2014 елда гына нәшер ителә.

Күренекле татар композиторы Ф.З. Яруллинның (1914–1943) тууына 100 ел тулу, композитор Яруллиннар нәселенең шушы төбәктән булуы – җыентыкны чыгарырга этәргеч була [Сайдашева, 2014]. Алдагы җыентыкта урын алган материалларга хас үзенчәлекләрне монысында да очратырга мөмкин. Керәшеннәрнең традицион фольклоры, З. Н. Сәйдәшева фикеренчә, гаилә тормышын (кунак итү, туйлар уздыру) чагылдырган җырлар белән генә чикләнә, ягъни аграр календарь белән бәйле җырлар юк. Бүгенге яшьләрнең җырларына да шул ук «чит тел» элементлары хас. Кереш сүз авторы әлеге катламда тагын бер үзенчәлеккә игътибар итә: биредә конфессияләрдән чыгып бүленү юк. Бу район яшьләре танылган татар җырчылары репертуарындгы җырларны да, җирле мөселман яки керәшен авылларында яшәгән авторларныкын да бик яратып башкара.

2005 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, этномузыколог Э.Р. Каюмованың «Яңа заман татар халык-җыр мәдәнияте: традицион фикерләү һәм жанр атрибуциясе проблемалары» дип исемләнгән китабы басылып чыга. Анда автор *авыл көе, так-*

*мак, кыска көй, салмак көй һәм түгәрәк уен көйләренең* күп функциялелеген һәм жанр-стиль трансформацияләрен тикшерә, шулай ук музыкаль-этнографик контекстны һәм җырларның традицияләрдә яшәү закончалыкларын бәян итә, татар җырының морфологиясенә ачыклык кертә. Методик яктан *авыл көе, такмак, кыска көй, салмак көй һәм түгәрәк уен көйләренең* әлеге яңа форматта анализлануы шулай ук зур кызыксыну тудыра.

Әйтергә кирәк, 1996 елда Казан дәүләт консерваториясе ректоры Р.К. Абдуллин фольклор кабинетын һәм яңа оештырылган этномузыкология кафедрасын, шулай ук аспирантларның диссертацияләренә җитәкчелек итүне музыка белгече, этномузыколог Е.М. Смирновага йөкли. Бу вакытта аспирант, хәзер инде этномузыколог, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе доценты Л.И. Сәрвәрованың экспедицияләре Урта Идел, мишәрләр компактлы яшәгән Мордовия, Пенза, Түбән Новгород өлкәләренә оештырыла. Е.М. Смирнованың икенче аспиранты Н.Г. Агдеева «Әстерхан өлкәсенең музыкаль фольклоры» дигән теманы өйрәнә. Казан дәүләт консерваториясе, нигездә, Урта Идел һәм Урал буе татарларының музыкаль фольклорын өйрәнүгә юнәлеш тота. Шуңа күрә Әстерхан төбәге белән бәйле фәнни эзләнүләр әллә ни кызыксыну уятырга тиеш түгел иде кебек. Өстәвенә Әстерхан консерваториясенең үзендә җирле музыкаль фольклорны өйрәнү эшенең үз юнәлеше һәм борынгы традицияләре булуы – билгеле факт.

Музыка белгечләре Л. И. Сәрвәрова һәм Е.М. Смирнова төзегән «Татар-мишәр җырлары» җыентыгына килгәндә, ул студентларның 2000–2003 еллардагы экспедицияләре материалларына нигезләнгән, ягъни аны Урта Идел төбәгендә тупланып яшәгән мишәрләр этнографик төркеме җырларының беренче басмасы дип атап була [Сарварова, Смирнова, 2016]. Җыентыкка Ульяновск, Пенза, Түбән Новгород өлкәләренең аерым районнарында, шулай ук Мордовиянең Темников районында язылган үрнәкләр кергән. Җыелган материал этнотерриториаль түгел, ә жанр принцибы нигезендә системага салынган: йола көйләре, бәетләр, мөнәҗәтләр, лирик җырлар, уен җырлары. Нәтиҗәдә, һәр аерым өлкәнең этномәдәни үзенчәлекләре ачылмаган.

Мишәр татарлары фольклорын әлеге авторлар ике стилистик катламның үзара бәйләнешендә карый: мишәр татарлары (төгәлрәк типик) һәм гомумтатар. Беренче төркемгә Л.И. Сәрвәрова һәм Е.М. Смирнова йола фольклорын, традициягә нигезләнгән лирик җырларны; икенчесенә көйләп уку жанрын һәм лирик җырларның борынгы катламын кертә.

Мишәр татарлары фольклорында көньяк (темников), төньякка күчү (темников-пенза) һәм төньяк (сергач) төркемнәре белән беррәттән мөстәкыйль этномәдәни *ләмбрә* (Мордовия) төркемен дә бүлеп чыгарырга була. Этнограф Д.М. Исхаков фикеренчә, ул икенчел төркем булып санала һәм үзенчәлекле мәдәни параметрларга ия [Исхаков, 2017, с. 32]. Шуңа күрә Л.Х. Җиһаншинаның һәм Л.И. Сәрвәрованың

2019 елда дөнья күргән «Ләмбрә мишәрләренең халык җырлары» («Народные песни лямбирских мишарей») җыентыгын Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе этномузыкология кафедрасының зур уңышы дип кабул итәргә кирәк. Шул ук елны Л.Х. Җиһаншина «Ләмбрә татар мишәрләренең музыкаль-поэтик традициясе: стиль үзенчәлеге мәсьәләләре» («Музыкально-поэтическая традиция лямбирских татар-мишарей: вопросы стилевой специфики») (фәнни җитәкчесе – Казан дәүләт консерваториясе доценты Л.И. Сәрвәрова) дигән темага диссертация яклый. Җыентык материаллары түбәндәге эзлеклелеккә нигезләнгән: туй җырлары; солдатка озату җырлары; уен җырлары; бәетләр; лирик җырлар. Мишәрләрнең башка этномәдәни төбәкләрдә юкка чыккан кайбер локаль традицияләрен ачыклау әлеге җыентыкның һичшиксез өстенлеге булып тора.

Танылган этномузыка белгече, сәнгать фәннәре кандидаты, Россия сәнгать тарихы институтының фольклор секторы өлкән фәнни хезмәткәре Наилә Юнис кызы Әлмиева әзерләгән «Керәшен татар җырлары» басмасының ике чыгарылышы да зур игътибарга лаек. Басманың 2007 елда дөнья күргән беренче чыгарылышы Питрәч районы керәшен татарларының музыкаль фольклор үрнәкләрен үз эченә алса, 2012 елда басылган икенче чыгарылышта Мәлки керәшеннәренең традицион музыкаль мәдәнияте тулаем ачыла. Ике басмада да музыкаль материал локаль-географик принцип буенча бирелә, ул локаль җыр традициясен этномузыкаль done бербөтен итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Башкача әйткәндә, барлык халыкларда һәр җирле традиция әлеге локаль төркем яшәгән торак пунктларда яздырылган стиль формалаштыручы жанрлар аша бирелә. Материалның торак пунктларга туры китереп урнаштырылуы да әһәмиятле: башта барлык жанрларның үрнәкләре, бер авылда яздырып алынганнары, аннары инде икенче авылда яздырылганнары бирелгән һ. б.

Күп еллар этномузыкология өлкәсендә эшләгән И.Ш. Кадыйровның «Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы» (2021) дип исемләнгән басмасында себер татарларының 1967–1973 елларда Төмән, Томск, Омск, Новосибирск өлкәләрендә яздырып алынган йола җырларына хас үзенчәлекләр ачыла. Җыентыкның исеме үк аның этнотерриториаль ареал бүленешен истә тотып башкарылган фәнни тикшеренү булуына ишарәли.

Этномузыколог Г.И. Трофимованың «Башкортстанның Бакалы районы керәшен татарларының җыр традициясе» («Песенная традиция татар-кряшен Бакалинского района Башкортостана», 2009) һәм композитор, этномузыколог Э. М. Галимованың «Пермь татарларының традицион музыкаль мәдәнияте» («Традиционная музыкальная культура пермских татар», 2014) темаларына якланган диссертацияләрендә төп принцип буларак кулланылган этномәдәни районлаштыру (районирование) турында басым ясап әйтергә кирәк. Чөнки, әлеге диссертация авторлары татарларның моңарчы этномузыкологлар тарафыннан өйрәнелмәгән территориаль төркемнәрен сайлаганнар, һәм

аларда музыкаль үзенчәлекләр анализлану белән беррәттән фольклорның шигъри ягына да игътибар ителгән. Әлеге диссертацияләрнең җитәкчесе профессор З.Н. Сәйдәшева Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында аспирантура үткән (1967–1970), соңыннан кече фәнни хезмәткәр (1970–1977) булган вакытта ук халык җырының шигырь һәм җыр төзелешен музыкантлар яки телчеләр тырышлыгы белән генә өйрәнеп булмавын аңлый. XIX гасырда ук А.Н.Серов та «Русская народная музыка как предмет науки» китабында шул хакта яза. Чыннан да, фольклор җыры синтетик жанр, анда көй һәм текст үзен бердәй дәрәҗәдә күрсәтә. Текстсыз көйне генә һәм, киресенчә, музыкаль белемсез сүзле текстны гына өйрәнеп, халыкның дөньяга карашлары системасы турында мәгълүмат алу мөмкин түгел.

Халык музыкаль иҗат тәҗрибәсенең бу яклары, сәнгать фәннәре докторы, профессор, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры В.Р. Дулат-Алеев фикеренчә, милли мәдәният тарихы түгел, ә тарих теле булган «милли мәдәният тексты» («текст национальной культуры» яки ТНК) типларының берсенә карый [Дулат-Алеев, 1999, с. 59]. Теге яки бу фольклор әсәрендәге мәгълүматны аңлау өчен, өйрәнелә торган мәдәниятнең телен (ТНК) белергә, шулай ук лингвистика, этнография, социаль тарих, филология һ. б. кебек фәннәрдән хәбәрдар булу кирәк. Шуңа күрә музыкаль-стилистик үзенчәлекләрне тикшерүдән тыш, җыр текстларының шигъри эчтәлеген, сәнгать чараларын, шигъри формасын өйрәнүгә багышланган фәнни хезмәтләр этномузыкология өлкәсендә аерым кызыксыну уята.

**Әдәбият**

*Альмеева Н.Ю* Песни татар-кряшен. Вып. 1. Пестречинская (примешинская) группа / под общ. ред. И.И. Земцовского; сост. Н.Ю. Альмеева. СПб.; Казань: РИИИ, 2007. 307 с.

*Альмеева Н.Ю.* Песни татар-кряшен. Вып. 2. Молькеевская группа / под общ. ред. И.И. Земцовского. СПб.; Казань: РИИИ, 2012. 472 с.

*Берг М.И.* Восемь татарско-башкирских песен (мелодии, текст и перевод). Нотные транскр. М.И. Берг / Из Каб. эксперим. фонетики Казан. ун-та; под ред. В.А. Богородицкого. Казань, 1923. 23 с.

*Гусев В.Е.* Эстетика фольклора. Л.: Наука, 1967. 319 с.

*Дулат-Алеев В. Р.* Текст национальной культуры: Новоевропейская традиции в татарской музыке. Казань: Казан. гос. консерватория, 1999. 244 с.

*Зиганшина Л.Х.*, *Сарварова Л.И.* Народные песни лямбирских татармишарей / сост. и нот. транскр. Л.Х. Зиганшиной и Л.И. Сарваровой. Казань: Казанская гос. консерватория (академия) им. Н.Г. Жиганова, 2019. 341 с.

*Исхакова-Вамба Р.А.* Татарские народные песни. М., 1981. 190 с.

*Исхаков Д.М.* Этнографическая структура татар. Татары. М., Наука, 2017.

*Кадыров И.Ш.* Татарские свадебные песни: сибирский ареал. Казань, 2021. 188 с.

*Каюмова Э.Р.* Татарская народно-песенная культура нового времени времени: проблемы традиционного мышления и жанровой атрибуции. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2005. 213 с.

*Ключарев А.С.* Татар халык җырлары. Казан, 1986. 488 б.

*Козлов И.А.* Пятизвучные гаммы в татарской и башкирской музыке и их музыкально-теоретический анализ // ИОАИЭ. Казань, 1928. Т. 34. Вып. 1. С. 160–178.

*Кузеев Р.Г., Моисеева Н.Н.* Ареальные методы выделения этнографических групп на территории Башкирии XVII–XIX вв. // Ареальные исследования в языкознании и этнографии. Тез. V конф. на тему: Проблема атласной картографии. Уфа, 1985. 204 с.

*Макаров М.Г.* Милли моңнар. Төрки-татар көйләре. (С. Габәши язмалары буенча) / төз.-авт. Г.М. Макаров. Казан, 2002. 207 б.

*Мошков В.М.* Материалы для характеристики музыкального творчества инородцев Волго-Камского края // Известия общества археологии, истории и этнографии. Казань, 1897. Т. 14.

*Музафаров М., Виноградов Ю., Хайруллина З.* Татарские народные песни. М., 1964. 206 с.

*Нигмәтҗанов М.Н.* Татар халык җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 215 с.

*Нигмедзянов М.Н.* Татарские народные песни. М: Сов. комп., 1970. 82 с.

*Нигмедзянов М.Н.* Татарские народные песни. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 240 с.

*Рыбаков С.Г.* Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1897. VIII, 330 с., 1 л. карт. : нот.; 29.

*Сайдашева З.Н.* Издание, расширяющее кругозор // Татарская музыка: история и современность. Казань: Идел-Пресс, 1974. № 9. С. 8–14.

*Сайдашева З.Н., Ярми Х.Х.* Татарско-мишарские песни. Из коллекции фольклориста. М.: Советский композитор, 1979. 79 с.

*Сайдашева З.Н.* Татарские песни Нурлатского района / сост. и ред. нотн. транскр. З.Н. Сайдашева; Казан. гос. консерватория. Казань, 2001. 90 с.

*Сайдашева З.Н.* «Татарская музыкальная этнография». Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 223 с.

*Сайдашева З.Н., Шюнеман Г.* Песни казанских татар: Перевод // Из истории татарской музыкальной культуры / сост. В.Р. Дулат-Алеев: Казан. гос. консерватория. Казань, 2010. С.126–148.

*Сайдашева З.Н.* Песни родины Яруллиных (музыкальный фольклор Мамадышского района). Казань, 2014. 144 с.

*Сарварова Л.И.* Песни татар-мишарей / сост. и нот. транскр. Е.М. Смирновой, Л.И.Сарваровой; Каз. гос. консерватория. Казань, 2016. 486 с.

*Султанов М И.* Башкирские и татарские мотивы. Саратов, 1916. 260 с.

Төрек-татар көйләре. Оренбург мөселман музыка-драма җәмгыяте тарафынанн нотага алынган. Оренбург, 1919. 6 б. 3 бүлем.

*Фәйзи Җ.Х.* Халык җәүһәрләре. Казан, 1971. 288 б.

Этнокультурное районирование татар Среднего Поволжья (Опыт комплекс. исслед), [Сб.ст.] / АН СССР. Казан. науч. центр. Ин-т яз., лит и истории им. Г. Ибрагимова; [Редкол.: Р.К. Уразманова (отв. ред.). Д.М. Исхаков]. Казань: ИЯЛИ, 1991. 151 с.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры вазифаларын башкаручы*

УДК 730

***О.В. Калугина***

# РОССИЯНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ШӘҺӘР СКУЛЬПТУРАСЫ: ЖАНРЫН БИЛГЕЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

В статье проводится анализ практики бесконтрольного возведения в городском пространстве трёхмерных сооружений, объединённых под не вполне оправданным термином «городская скульптура». Использование этого определения смещает ценностные границы между традиционными городскими и садово-парковыми изваяниями и поделками уровня массовой культуры последних десятилетий. Ряд искусствоведов и художественных критиков пытаются поставить эти сферы творческой практики в один ряд

**Ключевые слова:** скульптура, жанры, поп-арт, монумент, массовая культура.

The article analyzes the practice of uncontrolled construction of three-dimensional structures in the urban space united under the not entirely justified term “urban sculpture”. The use of this definition shifts the value boundaries between traditional urban and landscape sculptures and handicrafts of the mass culture level of recent decades. A number of art historians and art critics are trying to put these areas of creative practice on a par.

**Keywords:** sculpture, genres, pop art, monument, mass culture.

Шәһәр скульптурасы төшенчәсе, күпчелек тикшеренүчеләр фикеренчә, Россиянең хәзерге заман сәнгате лексиконында чагыштырмача күптән түгел барлыкка килгән. Әмма чынлыкта әле 1932 елда ук «XVIII гасыр – XX гасыр башы мемориаль скульптурасының уникаль тупланмасын саклау максатыннан» [Государственный музей городской скульптуры...] Ленинград шәһәренең кайбер зиратларын (некропольләрен) музейлаштыру эше башлана. Һәм «1939 елның 4 июлендә Ленсовет Президиумы карары белән Ленинград Музей-Некрополе шәһәр һәйкәлләрен һәм мемориаль такталарны аның карамагына тапшыру сәбәпле Ленинград Шәһәр скульптурасы музее итеп үзгәртелә». Шул вакыттан башлап «шәһәр скульптурасы» термины [Государственный музей городской скульптуры...] музей терминологиясендә, димәк, сәнгать белеме терминологиясендә дә рәсми статус ала.

Шунысына да ачыклык кертеп китәргә кирәк, әле күптән түгел пластика әсәрләренең аерым бер һәм традицион төрләрен генә бу жанр һәйкәлләренә кертәләр иде. Барыннан да элек аларны, күрсәтелгән музейның оешу тарихын истә тотсак, төрле зур зиратлардагы кабер ташлары тәшкил иткән. Аннары аларга шәһәр монументларын да кушканнар – тарихи шәхесләргә һәм вакыйгаларга куелган һәйкәлләрне, шул исәптән мемориаль такталарны, шулай ук шәһәр мохитен тулаем бизәүче әсәрләрне дә. Алар арасына бакча-парк

скульптурасы гына, аерым алганда Җәйге бакчаны бизәгән сыннар кертелмәгән, чөнки ул үзе Дәүләт Рус музеена карый. Хәзерге вакытта, гомумевропа тәҗрибәсенә ияреп, Россиянең иң борынгы җәмәгать бакчасындагы бу скульптуралар копияләре белән алыштырылды, ә оригиналлары, сакланышларын тәэмин итү максатыннан, музей залларына күчерелде.

Шул ук вакытта әле бик күптән түгел, ә 1990 елларда, Россия шәһәр ландшафтына бөтенләй башка эчтәлекле әсәрләр актив үтеп керә башлады. Нәкъ менә алар, акылга сыймаслык мантыйкка ияреп, *шәһәр скульптурасы* дип аталалар да [Вилькицкая]. Дөресен әйткәндә, терминология өлкәсендә бүгенге билгесезлек шушы вакытта барлыкка килде дә инде. Закончалыклы рәвештә мондый сорау туа: әлеге скульптура ачык һава астындагы һәйкәлләрне үз эченә алган һәм күптән формалашкан жанрлардан нәрсәсе белән аерыла соң? Чыннан да, пластиканың бу типологик төренең урынын һәм функцияләрен характерлау бер дә җиңел түгел. Бер яктан, ул традицион максатларга хезмәт итә ала, әйтик, аерым зат яки вакыйганың истәлеген мәңгеләштерүгә. 2000 елда Александр Рукавишников тарафыннан ясалган һәм Цветной бульвардагы цирк бинасы (бөек артист ярты гасырдан артык шунда эшли) янында урнаштырылган Юрий Никулин һәйкәлен моңа мисал итеп китерергә мөмкин. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, әлеге һәйкәлгә, чыннан да, тикшеренүчеләр шәһәр скульптурасы жанрын тасвирлаганда телгә алына торган күп кенә сыйфатлар хас, аерым алганда, геройга юмористик караш һәм сәнгати чишелешкә хас демократизм: «Эта скульптура изображает разнообразные сюжеты, сцены, в том числе обыденной, повседневной, бытовой жизни города, представляет различные типажи горожан, часто апеллирует к чувству юмора» [Гефнер, с. 57–70]. Әлеге ике сыйфат бу әсәрне шәһәр монументының традицион образлы чишелешеннән шактый ерагайта.

Тулаем алганда, Юрий Никулинга куелган һәйкәл, бу яктан карaганда, искәрмә булып тора, чөнки аңарда бер каршылык та юк. Образны, шул исәптән традицион пьедесталны аңлатуда пафослылык булмау, ә юмористик подтекстның алга чыгуы геройны тәкъдим итү үзенчәлекләре белән билгеләнә. Әйе, юмористик жанр әле күптән түгел генә вак скульптура пластикасына гына хас иде, әмма бу очракта без Юрий Владимирович портреты белән генә түгел, ә бөтенләй үзгә жанр – рольдәге портрет белән эш итәбез. Никулин безнең алда бер үк вакытта клоун һәм Гайдай фильмнарындагы даими өчлекнең күренекле әгъзасы – Балбес ролендә ачыла. Артистның үзен образлы ачу характеры гына түгел, ә «Кавказская пленница» фильмында атаклы Никулин автомобиленең скульптур күчермәсен катнаштыру да һичшиксез шуңа ишарәли.

Әмма шәһәр скульптурасын булдыру тәҗрибәсендә мондый дөрес чишелешләр бик аз. Кыяр, галим мәче, чижик һәм сантехник һәйкәлләренең авторлары иҗат практикасының рөхсәт ителгән кы-

саларын чиксез киңәйттеләр. Без нәрсә белән эш итәбез соң? дигән сорау туа. Болар сәнгать әсәреме яки бу ниндидер сәнгати тәҗрибә үрнәкләреме? (Чөнки соңгы унъеллыкларда аларның спектры чиксез киңәйде.) Бу сорауга җавап бирү өчен, тирәнтен ышануыбызча, иң элек скульптураның сәнгать төре буларак үзенчәлекле характеристикаларына мөрәҗәгать итәргә кирәк, алар бәяләү критерийларын шактый ышанычлы итеп күзалларга мөмкинлек бирәчәк.

Пластика әсәрләре тамашачыга аның кинестетик тойгыларын активлаштыру аша йогынты ясый, ягъни кеше мускул моторикасын тоеп кичерергә, аңларга тиеш [Виппер, с. 45]. Үзенең гәүдәсен тоярга сәләтле кеше статуар геройның хәл-халәтен дә кичерергә сәләтле. Әмма безнең заманда потенциаль тамашачыларның бик азы гына мондый хисне татый ала. Заманабызның бөтен мәдәни вазгыяте, тексттан башлап компьютер мониторына кадәр, объектларның сызыкларын һәм чик-кысаларын кабул итүгә (плоскостное восприятие) юнәлдерелгән. Сурәт төзүнең ниндидер 3D-технологияләрен искә дә алырга кирәк түгел, чөнки алар үз тәнеңне тоеп аңлауда катнашкан төп нәрсәләрдән – гравитация һәм тактиль тойгылардан мәхрүм. Шул ук вакытта кинестетик хисләребезнең нәкъ менә шушы элементлары скульптурага хас тәэсир итү чараларының тагын бер мөһим катламын барлыкка китерә. Сынның тектоник оештырылуы һәм материал фактурасының тәэсирлелеге ышандыру көченә ия булырга тиеш. Болар – пластиканың тамашачыга традицион йогынты ясау чаралары.

Сынның образлы тәэсирлелеген билгеләүче тагын бер мөһим сыйфат – силуэт һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, аның гомуми композицион корылышы [Головин, с. 87–90]. Ачык һавада урнаштырыла торган скульптура өчен, дөресен әйткәндә, шул турыда сүз бара да, бу чыннан да бик мөһим характеристика. Ул әсәр тирәли әйләнеп чыгу мөмкинлеген күздә тота. Әлеге тәэсир итү чараларын оста файдаланган очракта, скульптор иҗат җимешенең мәгънәсен дөрес итеп тапшырырга, образлы корылышын тулысынча ачарга сәләтле.

Хәзер әлеге критерийларны «шәһәр скульптурасы» төшенчәсе астында берләштерелгән әсәрләргә карата кулланырга тырышып карарбыз. Сатып алучы һәм сатучы образы, ё хәрефе, эретелгән сыр һ. б. аша тәкъдим итү, ниндидер кинестетик тойгылар турында, әлбәттә, сүз бара алмый. Теге яки бу материалны куллануга бәйле рәвештә, тоеп беленә торган (тактиль) хисләр кайчак бөтенләй көтелмәгән дәрәҗәдә активлаша. Скульптураны ышкып туздыралар, бозалар, өстенә менәләр, аңа гардероб предметларын кидерәләр. Һәйкәлләргә карата мондый мөнәсәбәткә, гомумән, шаккатырга урын юк. XIX гасырның беренче яртысында ук һәйкәлләрне варварларча мөнәсәбәттән сакларга туры килгән. Ул вакытта ук рәшәткәләр һәм дежур постлар куелган, А.Н. Оленин язганча, «…если не будут охраняемы караулами и железною при том или чугунною решеткой в полроста, то могут много потерять от народа, не довольствующегося видеть памятники в некотором расстоянии, а проходящего поколупать»

[Оленин; Щедрова, с. 65–67]. Әмма боларның берсенең дә пластика әсәре белән аралашканда безнең эстетик хисне чын мәгънәсендә баета торган материалны кабул итү дәрәҗәсенә катнашы юк. Өстәвенә, ике гасыр дәвамында диярлек шәһәр һәйкәлләре белән аралашу культурасында бернинди алга китеш күзәтелми. Моның белән килешүе бик авыр.

Билгеле булганча, скульптураны тоеп аңлау дәрәҗәсе аны бер үк вакытта реаль табигый материал һәм җисманилеккә тиңләштерелгән күләм буларак тәкъдим итү дәрәҗәсенә турыдан-туры бәйле. Һәм бу, кагыйдә буларак, теләсә кайсы материал белән эшләгәндә автор техникасының төп контрапунктына әверелә. Тере кешенең үле материя аша бирелгән яшерен энергиясе (динамикасы) – мөгаен, чын скульптураларның иң сихри эффектыдыр [Калугина, с. 205–209]. Тамашачының заманча шәһәр скульптурасының традицион әсәрләрен кабул итүендә нәкъ менә шушы мизгел төшеп кала. Сыннар җиңел генә коела, арзанлы пластиктан яки ясалма таштан ясала. Тамашачы белән мондый багланыш бөтенләй искә алынмый. Дөрес, алар арасында искәрмәләр дә бар. Ягъни вакыт-вакыт бу массакүләм төс алган ялган сыннар арасында чыннан да талантлыларын очратырга мөмкин. Шулай да безне барыбер шәһәр киңлекләренең түбән сыйфатлы, арзанлы скульптуралар белән тула баруы борчый.

Шул рәвешле, традицион чын сәнгать әсәре булган шәһәр монументы белән бу сыннарны чагыштырырлык та түгел. Үзеннән-үзе шундый зарурлык туа: шәһәр скульптурасын ачык һавада урнашкан скульптураның нинди типологик төрләре белән чагыштырырга мөмкин? Безнең карашка, аны бакча-парк скульптурасы белән бер рәткә кую дөрес булыр. Нәкъ менә ул органик рәвештә киңлек белән кушыла, югары жанрга дәгъва итми һәм аны якыннан карап була. Әмма монда да дистанция шактый мөһим роль уйный. Беренчедән, бакча-парк скульптурасы, дөрес кулланганда, киңлекне бик яхшы оештыра. Мондый сыйфатларны шәһәр скульптурасы һәйкәлләрендә сирәк очратасың. Алар, кагыйдә буларак, киңлек-пластика акцентлары гына булмыйча, бәлки очраклы рәвештә ачылган объектлар сыйфатында үзләрен тәкъдим итә кебек. Без кинәт туңдырма сатучы юан хатынга, узган гасыр почтальонының галәмәт зур велосипедына яки коточкыч кыяфәтле кәҗәгә юлыгабыз. Алар киңлекне оештырмый, киресенчә – боза, җәяүлеләргә һәм транспортка комачаулый, уңай хис-кичерешләргә түгел, еш кына сарказмлы көлүгә сәбәп була.

Биредә бакча-парк скульптурасының, кагыйдә буларак, яхшы уйланылган һәм эстетик яктан югары оештырылган ансамбльнең бер өлеше булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Ә узган гасырларда ул үзенчәлекле символик функция үтәгән: үзе бизәп торган утарны ниндидер оҗмах бакчасы – изгеләрнең җаннары өчен сыену урыны белән чагыштырырга мөмкинлек биргән. Шәһәр скульптурасының күпчелек һәйкәлләрендә мондый уңай коннотацияләр юк диярлек [Гончаренко, с. 59].

Шуңа да карамастан, гади шәһәр тамашачысы «нигә бәйләнергә?!» дип, нигезле сорау бирә ала. Мәзәк җәнлекләр, демонтажланган Алёнушка шикелле монстр тибындагы сыннар тора бирсеннәр һәм кешеләрнең күңелен күрсеннәр! Әмма, безнең карашка, монда уйланырга урын бар. Бер яктан, без әлеге сыннарны таратуда узган гасырның икенче яртысы поп-артының соңарган репрезентациясен күрә алабыз, чөнки бу хәрәкәт осталары иҗатының нигезенә дә куллану предметларын сурәтләү принцибы салынган иде. Әмма поп-артның билгеле бер идеологик программасы була, ул тулаем алганда үз позициясен абстракт экспрессионизмга каршы куюга кайтып кала.

Репрезентация өлкәсен чиксез киңәйткән паблик арт хәрәкәтен поп-артның иң яңа реинкарнациясе дип санарга мөмкин. Әмма теге һәм бу очракта да проблемалы сораулар арта гына бара. Һичшиксез, безнең заманның шәһәр киңлекләрен тутырган массакүләм җитештерелә торган статуар комикслар шәһәр монументлары җәүһәрләрен кабул итү дәрәҗәсенең дә бик нык төшүенә китерә. Бу эклектик массада аларны аерып булмый башлый. Әлеге проблема, һичшиксез һәм барыннан да элек, базар мөнәсәбәтләренең иҗади эшчәнлек өлкәсенә дә үтеп керүен чагылдыра һәм әлеге эшләнмәләргә заказ бирүче фигурасы белән турыдан-туры бәйле. Теге яки бу дәрәҗәдә хакимият белән килешүгә ирешкән һәркем, үзенчә хәл итеп, сәнгатьлелек дәрәҗәсе түбән, зәвыксыз корылмалар торгыза ала. Мәсәлән, өлкән яшьтәге иренең ихтыяры белән төзелгән Майя Плисецкая һәйкәле Мәскәүнең нәкъ үзәгендәге киңлекне тәмам бозган.

Кызганыч ки, мондый мисаллар аз түгел. Мәскәүгә бронза комикслар һөҗүменнән тыш, тоташ некропольгә әверелү куркынычы да яный. Һәм закон нигезендә гәүдәләндерелгән эшлекленең вафатыннан соң ун еллык срокны саклау таләп ителсә дә, бу беркемне дә туктатмый. Әлеге проблема контекстында мондый сорау туа: ә бу очракта без нинди күренеш белән эш итәбез соң? Һичшиксез, безнең алда массачыл мәдәният тантана итә. Кеше эшчәнлегенең әлеге төренә хас үзенчәлекләрне Вадим Межуев болай билгели: «Не имея четко выраженной национальной окраски и не признавая для себя никаких национальных границ, эта продукция, в отличие от этнической и национальной культуры, может быть названа *массовой культурой*» [Межуев, с. 40].

Бу хәл хәзерге заман шәһәр кешесенә ничек зыян китерергә мөмкин? дигән сорауга җавап бирү җиңел түгел, гәрчә карала торган күренешнең агулы булуы шик тудырмый, бигрәк тә сәнгать белгече өчен. Әлеге эшләнмәләрнең күбесенең эстетик сыйфатлары җитди тәнкыйтьне күтәрә алмый. Аларның образлы чишелешендә бернинди кыйммәтле эчтәлек таба алмассыз. Ә бит сәнгатьнең тууы очраклы түгел: ул шәхеснең социаль-кыйммәтләр ориентациясе формалашуда, кыйммәтләр системасын киләчәк буыннарга тапшыруда универсаль коралга әверелде. Соңгысы эстетик яктан җәлеп итүчән образлар тудыру юлы белән инстинктив дәрәҗәдә гамәлгә ашырыла. Һәм бу

сыйфатларның берсе дә әлеге әсәрләргә хас түгел. Әгәр алар арасында чын талантлы әсәр барлыкка килә икән (ә билгеләмә буенча бу хәл артык еш күзәтелә алмый), «ширпотреб» дәрәҗәсенә йөз тоткан тамашачы аны күрмәячәк тә, аермаячак та. Бу яктан караганда, чын рәссамның тырышлыгы псевдосәнгать базарының массачыл продукциясе сазлыгында эреп югалачак.

Мәдәният фәлсәфәсен тикшерүче күренекле галим Вадим Михайлович Межуев массачыл мәдәниятнең кешеләрнең гади, элементар хис һәм кичерешләренә мөрәҗәгать итүен билгели: «Массовая культура – не для тех, кто хочет жить, чтоб “мыслить и страдать”. В ней ищут по большей части источник бездумного веселья, ласкающего глаз и слух зрелища, заполняющего досуг развлечения, удовлетворения поверхностного любопытства, а то и просто “ловли кайфа”, получения разного вида удовольствий. Достигается эта цель не столько словом (тем более печатным), сколько изображением и звуком, которые обладают несравненно большей силой эмоционального воздействия. Они-то и являются языком массовой культуры» [Межуев, с. 40].

Шулай итеп, тамашачы үзенә массачыл мәдәният артефактлары белән аралашуның җиңел юлларын ача, әмма тулаем алганда, чын рухи, ә аерым алганда, эстетик кыйммәтләрнең индивидуаль, тирән һәм төсләргә бай дөньясына юлны яба. Бу процесс аның яшерен куркынычын аңлаган кешедә сагаю һәм эчке протест тудырмаска мөмкинме? Әлбәттә, юк! Әлеге вазгыятьтән чыгу юлын иҗади симпозиумнар практикасын киңәйтүдә дә күрәбез, аларда таләпчән тамашачы катнаша, һәм иң элек яшь осталарның зәвыгы һәм иҗади тәҗрибәсе камилләшә. Әлбәттә, чын иҗатчыларның һәм сәнгать тәнкыйтьчеләренең гражданлык позициясен җитди активлаштыру сорала, ул түрәләрнең башбаштаклыгына да, законны тупас бозуга да, шәһәрләребез, ял зоналары, яңа парк ансамбльләре киңлегенә вәхшиләрчә мөнәсәбәткә дә киртә куярга мөмкин. Массачыл мәдәният дәрәҗәсендәге вак-төяк әсәрләр гражданин да, иҗади шәхес тә тәрбияли алмый, алар чын кеше индивидуальлеге чагылу дәрәҗәсен генә киметә, шуңа чик куярга кирәк тә. Бу программага мәдәни-агарту эше дә кертелергә тиеш, аны күңел ачу квестлары зонасыннан чыгарырга һәм үткән дәверләр һәм хәзерге заман сәнгать әсәрләренең чын әһәмиятен аңлауны камилләштерүгә юнәлтергә кирәк.

Йомгаклап, шуны билгеләп үтәсе килә: әлеге корылмаларның шәһәр киңлегендә яшәве һәм киләчәк язмышы, аларга техник хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен без кузгатмадык диярлек. Әмма бу үзе – махсус тикшеренү предметы, аны әле киләчәктә күтәрергә кирәк булачак.

Шушы өлкәдәге профессиональ экспертлар тырышлыгы белән шәһәр киңлеген эстетик оештыру эшендә сәясәтне үзгәртү мәсьәләсе көн тәртибенә куелырга тиеш, әмма формаль-стилистик һәм тарихи-сәнгати анализ бу фикерләрнең көчсезлеген ышанырлык итеп күрсәтә.

## Әдәбият

*Вилькицкая В.Г.* О роли городской скульптуры в архитектурно-пространственной среде Екатеринбурга XX–XXI вв. // Уральский государственный архитектурно-художественный университет. Библиотека УрГАХУ. URL: http://book.uraic.ru/project/conf/txt/005/archvuz14_pril/33/template_article-ar=K41-60-k46.htm (мөрәҗәгать итү көне: 20.03.2021).

*Вилькицкая В.Г.* О формировании архитектурно- художественной взаимосвязи скульптурных объектов и городского пространства // Архитектон. Известия вузов. № 2 (10), 2005. URL: http://archvuz.ru/2005_2/39 (мөрәҗәгать итү көне: 20.03.2021).

*Виппер Б.Р.* Введение в историческое изучение искусства. М., 1985.

*Гефнер О.В.* Городская скульптура в культурном ландшафте современного Новосибирска // Культурные ландшафты современного города. М, 2020. С. 57–70.

*Головин В.П.* От амулета до монумента: Книга об умении видеть и понимать скульптуру. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1999. 122, [1] с.: ил.

*Гончаренко Н.М.* Современная городская скульптура в России: памятник или развлечение? // Дом Бурганова. Пространство культуры. 2009. № 1. С. 59.

Государственный музей городской скульптуры Санкт-Петербурга. История музея. URL: https://gmgs.ru/museum_history (мөрәҗәгать итү көне: 15.05.2021).

*Калугина О.В.* Скульптор Анна Голубкина: Опыт комплексного исследования творческой судьбы. М., 2006. 248 с., ил.

*Межуев В.М.* Идея культуры: очерки по философии культуры. М.: Прогресс-Традиция, 2006. 408 с.

*Оленин А.Н.* Избранные труды по истории и деятельности Императорской Академии художеств / сост., вступ. ст. и прим. Н.С. Беляева; науч. ред. Г.В. Бахарева; БАН. СПб.: БАН, 2010.

*Щедрова О.В.* В.И. Демут-Малиновский и вопросы реставрации скульптуры в России первой половины XIX века // Проблемы развития отечественного искусства. СПб., С. 65–67.

***Калугина Ольга Вениаминовна,***
*сәнгать фәннәре докторы, Россия дәүләт гуманитар университетының кино һәм хәзерге заман сәнгате кафедрасы баш фәнни хезмәткәре (Мәскәү шәһәре)*

УДК 09.930

***Ф.Г. Фәйзуллина***

# ПЕНЗА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ АРХЕОГРАФИК ТАБЫШЛАР ТУРЫНДА

Комплексная экспедиция по изучению языковых особенностей, фольклора и культуры татар Пензенской области была организована Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ в 2022 г. В данной статье представлен обзор результатов экспедиции по археографии, которая проводилась с целью выявления и сбора памятников письменности.

**Ключевые слова:** татары Пензенской области, археография, экспедиция, памятники письменности.

A comprehensive expedition to study the linguistic features, folklore and culture of the Tatars of the Penza region was organized by the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in 2022. This article presents an overview of the results of the expedition on archeography which was carried out with the aim of identifying and collecting written monuments.

**Keywords:** Tatars of the Penza region, archeography, expedition, written monuments.

Татар халкы тарихында Пенза өлкәсе аерым урын алып тора. Татарлар Пенза өлкәсе территориясендәге иң борынгы халыклар рәтенә керә һәм нәкъ менә алар, X гасырдан башлап XVII гасырга кадәр, бу территориядә төп тарихи көч булган дияргә мөмкин [Зюзин; Саляев, с. 122–126].

Пенза өлкәсе татарларының тарихы бик бай һәм кызыклы. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган комплекслы экспедицияләрнең чираттагысы шушы өлкәдә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен, тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә багышланган иде. Әлеге өлкә элегрәк тә тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп иткән. 1958 елда Институт тарафыннан оештырылган фольклор җыю буенча фәнни экспедиция шушы өлкәнең татарлар яшәгән Белинский (Кутеевка авылы), Каменка (Кикин, Кабылкин, Мачали авыллары), Соснобор (Индерка авылы), Неверкин (Мазарлы авылы), Лопатин (Вершаут, Иске Карлыган авыллары), Кузнецк (Ялгаш авылы) кебек районнарына үткәрелгән була [Татар халык иҗаты, б. 320].

2022 елда экспедициябез Пенза өлкәсенең Каменка, Белинский, Пачелма, Вадинск һәм Спас районнарындагы 14 татар авылына оештырылды. Россия куенындагы Пенза өлкәсендә гомер кичерүче милләттәшләребез, татар дигән исемгә тугры калып, горур гына яшәп яталар. Алар, олысы да, кечесе дә, рәхәтләнеп, үзләренә хас татар телендә сөйләшәләр. Һәм шушы сыйфатлары белән үзләренә җәлеп итеп торалар.

Сәяхәтебез Каменка районының Кикин авылыннан башланды. 1690 елда, риваятьләр буенча, Арслан Акҗигитов тарафыннан нигез салынган әлеге авыл – тарихи «Алты авыл»ның иң зурысы («Алты авыл» – Пенза өлкәсенең алты татар авылын берләштергән атама). Үз эшләренең белгечләре булган – мәктәпнең Тарихи-туган якны өйрәнү музее директоры Равилә Билал кызы Девлекамова һәм татар теле укытучысы Равилә Фәрит кызы Баткаеваның Кикин һәм «Алты авыл» тарихы турындагы этрафлы чыгышлары, мәктәп кысаларына гына сыймыйча, урман уртасында искиткеч матур табигать кочагындагы милли герой Акҗигитов Арслан Палкай улы кабере янында да дәвам итте. Эзләнүләребезнең нәкъ шушы тарихи авылдан башланып китүе бездә алда барачак авылларга карата зур кызыксыну уятты.

Халык үзенең тарихы белән кызыксына, өйрәнә, мәгълүмат туплый. Ә тарихыбыз тирәнрәк ачылсын, мәдәни мирасыбыз баесын өчен, галимнәр һәрвакыт халык ярдәменә мөрәҗәгать итә.

Татар халкы элек-электән китапка хөрмәт белән караган. Аларның һәркайсы саклык белән генә кадерләп тотылган. Халкыбызның тарихын саклаган язма ядкәрләр буыннан буынга тапшырылып килгән. Шуңа күрә халык кулында сакланып калган әлеге рухи мирасны өйрәнү аеруча зур әһәмияткә ия. Комплексы экспедицияләрнең төп максатларыннан берсе дә – нәкъ менә борынгы басма китапларны, кулъязмаларны барлау, туплау.

Заманында дүрт мәчет булган Кикин авылы уртасында бүген дә заманча төзелгән (2009 елда) ике катлы зур «Айшә, Маһирә» үзәк мәчете нурлар чәчеп утыра. Имам Илдус хәзрәт Шамил улы Такташев сүзләренә караганда, авылда иске китапларны укучы кешеләр инде калмаган. Ләкин авыл халкы, электән үк гарәп язулы китапларга бик игътибарлы һәм хөрмәт белән караучы буларак, үзләре укый белмәгәнлектән, кулларында булган истәлекләрне мәчеткә саклауга тапшырганнар.

Күпсанлы Коръән китапларын исәпкә алмаганда, мәчеттә гарәп язуында 30 га якын төрле эчтәлектәге басма китаплар барлыгы ачыкланды. Аларның күпчелеген дини-дидактик басмалар тәшкил итә. «Мөхәммәдия», «Һәза китаб эт-тәҗвид» (Казан, 1876), «Һәфтияк шәриф» (Казан, 1889), «Алты бармак» (Казан, 1902), «Вакты сәхәр китабы» (Казан, 1908), «Әзкяр әс-салят» (Казан, 1917), «Бәдәвам» һ. б. шушы исемлектән. Алар арасында дөньяви белем бирә торганнары да очрады. Мәсәлән, Тыйб китабы, Физика китабы, Фикъһ китабы, «Балаларга кыйраәт», «Ана теле», «Гөл бакчасы» (шигырьләр китабы) һ. б. шундыйлардан. Кызганычка, күбесенең я башы, я ахыры юк, яки шундый китап булганлыгын дәлилли торган аерым битләре генә калган. Мәчеттәге әлеге байлыкның һәрбер битенә игътибарлы булып, кулдан кичереп чыгарга тырыштым. Авылдагы кешеләрнең гарәпчә язмаларга бик сакчыл караганлыклары күренеп тора. Араларында аерым битләрдә язылган мәет өстендә укыла торган «Балага ананың васыяте», 40 көнендә рухларга Коръән багышлау һәм шулай

ук аерым кулъязма догалар да очрады. Китаплар арасыннан килеп чыккан тагын бер кәгазь аеруча игътибарга лаек. Ул – 1896 елда булган никахлар язылган Метрикә кенәгәсенең аерым бите. Әлеге биттә, 3 нче сан белән, 28 февральдә Пенза губернасы Чембар өязенең Кикин авылының Хөсни Рәхмәтулла углының 24 яшьлек кызы Шәрифә белән шул ук өязнең Кабылкин авылының солдаты 25 яшьлек Шәрифҗан Мөхәммәдгали углының никахы һәм, 5 нче сан белән, 29 мартта Пенза губернасы Чембар өязе Кикин авылының Әхмәджан Габделхаликъ углының 20 яшьлек кызы Таһирә белән шул ук авылның солдаты 26 яшьлек Муса Мөхәммәдрәхим улының никахлары теркәлгән.

Авыл кешеләрендә (Конеева Гүзәл Исхак кызы, (1948 елгы) сакланган «Гарәп әлифбасы», «Дин нигезләре» (намаз тәртипләре), «Мәүгазә дәрел нәсыйхин» (вәгазьләр) китаплары тагын бер кат авыл халкының укымышлы һәм дингә омтылышы булганлыгына дәлил булып торалар. Биредә башкача булырга мөмкин дә түгел, чөнки Кикин – атаклы Бигиевләрне биргән авыл. Татар әдәбиятының күренекле вәкиле Заһир Бигиев (1870–1902), әтисе ахун булып билгеләнеп, гаиләсе белән Ростов-Донга күченергә җыенып йөргән вакытта Кикиндә дөньяга килгән. Авыл кешеләре сүзенә караганда, бүгенге көндә алар нигезендә шул нәселнең дәвамчылары яши.

«Алты авыл»ның иң кечкенәсе Тәләтен авылы (Каменка районы) безне бик тыйнак кына каршы алды. Авыл халкы белән аралашканда, авылда әби-бабаларыннан калган иске китапларны, язмаларны каберг\u0259 илтеп күмү кебек аяныч хәлләр дә булганлыгы турында ишетергә туры килде. Шулай да үзлегеннән гарәпчә өйрәнгән, заманында абыстай булган Рушания Сабирҗан кызы Такташева (1939 елгы) өендә «Кыйссаи Сәйфелмөлек» (Казан, 1807), «Ике үксез» (Казан, 1904), «Кырык вәзир кыйссасы» кебек басма китаплар һәм «Догаи мәрҗан», «Исме әгъзам» кебек догаларның аерым кәгазьгә язган күчермәләре, шулай ук мөнәҗәтләр язылган аерым битләр сакланып калган. Каты авырудан тернәкләнеп килүче Рушания апаның кызы Флёра Назгар кызы Тахтарова (1969 елгы) әбиләре Әбидә Әхмәтҗан кызы Иртугановадан (Кушкин әби) калган әлеге мирасның өйләрендә бик кадерләп саклануы турында сөйләде.

Пенза өлкәсендәге татар авыллары үзләре тәрбияләгән атаклы шәхесләр аша да билгеле. Һәр авыл үзенең күренекле нәсел вәкилләрен яхшы белә. Алдагы Мачали авылында (Каменка районы) без язучы, мөгаллим Муса Акьегетзадә (1864–1923), 1939–1941 елларда Институтыбызның директоры булып эшләгән Хәсән Габдрахман улы Шабанов (1901–1956) эзләре буйлап йөрдек. Мачалидә яшәүче Муса Лотфулла улы (1939 елгы) һәм Сания Абдул кызы (1948) Макуевларда 25 ел авылда мулла булып торган Лотфулла хәзрәттән калган (1902 елгы) «Алты бармак китабы»на (Казан, 1899), «Рисаләи фарзы гайн һәм дәгъвәт» (Казан, 1903), «Рисаләи Тәүхид» (Казан, 1904), «Бәдәвам» (Казан, 1906), Һ. Максудиның «Гакаид»ы (Казан, 1915), «Шәраит әл-иман» (Казан, 1917), «Догаи исме Әгъзам вә һәм башка

шәриф догалар» (Казан, 1917) кебек дини эчтәлекле китапларга, кульъязма «Манара бәете»нә юлыктык.

Авыл халкында саклanган «Кәлам шәриф тәфсире» (1899), «Кыйссел-әнбия», «Мохтәсар тарих ислам» (Рәшит Ибраһим улы Уразгильдеевта (1960 елгы), «Мөхәммәдия», «Мәүлид ән-нәби галәйһиссәлам» кулъязмасы (Фәридә Сабирҗан кызы Акҗигитовада), «Һәза догаи Мәрҗан» (Сафия Мөхәммәт кызы Погодинада (1934 елгы) кебек дини китаплар Мачали авылында электә нинди китаплар укылганлыкны раслаучы дәлилләр иде. Алар арасында «Гарәп теле дәреслеге», «Сарфы гарәби» (Казан, 1898), «Мөгаллиме нәху лисане әл-гарәб» (Казан, 1903) кебек чыганакларның да очравы халыкның гарәп телен өйрәнүгә омтылышы булуын күрсәтә.

Гарәп язуындагы кәгазьләргә халыкта изге итеп карау сизелеп тора. Аларның илаһи көченә ышанып, хәтта елаган баланың мендәр астына да гарәп язулы китап битләре тыга идек, дип сөйләделәр Мачалидә. Бу ышану, үз чиратында, китапларның таркалуына китергән.

«Алты авыл»ның чираттагысы Кабылкин (Каменка районы) авылы үзенең төзеклеге, зурлыгы белән аерылып тора. Авыл имамы Руслан Хәмзә улы Тинчурин сүзләренә караганда, авылда 1942 елда бик каты янгын булган. Шул вакытта бик күп китаплар янып беткән. Кайбер кешеләр үзләрендә калган иске китапларны саклау өчен мәчеткә тапшырганнар. Мәчеттә сакланган басма китаплар арасында да «Кәлам шәриф тәфсире» (1889), Һ. Максудиның «Шәригать исламиянең әхкям гамәлиясе»нән (С.-Петербург, 1899) башкалары «Мөхәммәдия», «Рисаләи Газизә», «Тәгълим әс-салят тәрҗемәсе», «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Нәвадир тәрҗемәсе» китапларыннан калган башы-ахыры булмаган тарихи истәлекләр генә иде. Араларында «Китабы Устуани» кебек янгын шаһитлары да очрады.

Рамил Камил улы (1979 елгы) белән Әлфия Заһидулла кызы (1978 елгы) Кудряковлар авылда бабалары – 1896 еллардан мулла булып торган Гыйниятулла хәзрәт, 1906 елдан мулла булган аның улы Ибраһим хәзрәттән калган иске китапларны, аларның кулы белән язылган һәр кәгазьне кадерләп саклаганнар. Әлеге язма ядкәрләр «Китабы Бакырган», «Тәгъбирнамәи йәнабигъ тәрҗемәсе» (С.-Петербург, 1896), «Рисалә әш-Шафия» (Казан, 1901), «Рәднамә» (Казан, 1908), Шәһид Гаунинның «Фән әт-тәҗвид»е (Казан, 1912), «Көйле иман» (мәктәп балаларына) (Казан, 1915) «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Мәвакыйф» кебек, нигездә, дини эчтәлектәге басма китаплардан гыйбарәт. Арада сакланган «Эш һәм белем» китабының аерым битләре аларның хуҗаларының дөньяви белемнәр белән кызыксынганлыклары турында сөйли. Кайда гына булсак та, иң мөһим табыш – кулъязмалар, әлбәттә. Кудряковларда да, борынгы чорларга караган булмаса да, кулъязма дәфтәр табылуга бик тә сөендек. Анда шулай ук мөнәҗәтләр, дини эчтәлектәге шигырьләр язылган.

Белинский районына керүче Кутеевка (Качкару) авылы да – «Алты авыл»ның берсе. Тарихта Төрек армиясе генералы булып

танылган Шакир пашаның туган авылы белән танышуым нәкъ менә Яваевлардан башланды [Мөбәрәкшина]. Фируша Абделкадыйр улы (1950 елгы) белән Сафия Әхмәтҗан кызы (1953 елгы) Яваевларда Мөхәммәдшакир Мөхәммәдшәриф улы Яваев нәселеннән булган Абделкадыйр мулладан калган иске китаплар барланды. Басма «Кәлам шәриф тәфсире» (Петербург, 1898), «Тәсһил әл-бәян фи тәфсир әл-Коръән» (Казан, 1910), Габдулла Мөхәммәдфәезнең «Мохтәсар гыйльме халь»е (Казан, 1908), «Шөрут әс-салят» (Казан, 1911), Һ. Максудиның «Тәһарәт (Гыйбадәте исламия мәҗмугасының икенче сыйныф шәкертләре өчен)» (Казан, 1911) китаплары арасында сакланган кульязма дәфтәр бигрәк тә игътибарны җәлеп итте. Анда язылган «Манара бәете», «Суга барган ана бәете» һ. б. шигырьләр безнең фондларыбызда урын алды.

Шушы авылда туып, бүгенге көндә Пенза шәһәрендә яшәүче, Шакир пашаның турыдан-туры нәсел дәвамчысы Тумеркина Фирдәүс Казыйм кызы (1961 елгы) белән танышу аеруча кызыклы булды. Ул, күп еллар буе мәгълүмат туплап, Шакир паша турында аерым китап та әзерләп бастырган («По следам Шакир-паши», 2021). Бик кызыксынучан Фирдәүс ханым әтисенең әнисе Мөхлисә әбидән (1898–1980) калган иске китапларны үзендә бик кадерләп саклый. Алар – «Кыйссасел-әнбия» (Казан, 1899), «Кырык хәдис» (Казан, 1889), «Һәза китаб дәкаикыль әхбар» (Казан, 1900), «Әнварел-гашыйкыйн» (Казан, 1904), «Кырык вәзир кыйссасы» (Казан, 1907), Гәрәй Арслановның «Табышмаклар»ы (Казан, 1910), «Тәгъбирнамә» (Казан, 1886, 1917) кебек басма китаплар. Шулай ук үләннәр белән дәвалау турындагы аерым кульязмалар да бар.

Халыкта сакланган «Рәднамә» (Казан, 1909), «Мәҗмәгъ әддәгъвәт», «Хизбел бәхер», «Дәкаикыль әхбар тәрҗемәсе», «Нәвадир тәрҗемәсе», (Багдалова Нажия Кәрибулла кызында (1956 елгы) кебек китапларның исемнәре генә дә бу төбәктәге татарларның дин-белемгә омтылышлары зур булуы турында сөйли.

Тарихи «Алты авыл»ның соңгысы Решетин авылы (Пачелма районы) иде. Авыл мәчетендә элеккеге имам Хансиверов Нязиф Исхак улыннан калган, шулай ук шушы авыл кешеләре Казиев Айнулла Мәүледбирде улы, Бариев Сәлимҗан Фәтхулла улы, Максутов Әхмәтҗан, хәзерге имамы Ирфан Әнвар улы Тепаевның әбисе Тепаева Факия Әхмәтҗан кызы тарафыннан тапшырылган шактый гына китаплар булуы ачыкланды.

Бирыедә ислам дөньясында билгеле булган «Мөхәммәдия», «Мең дә бер хәдис», «Ходай Тәгаләнең мең дә бер исемнәре хасиятләре берлән» (Казан, 1883), «Җәннәтел әсма» (С.-Петербург, 1903), «Китабе хәзрәт Йосыф галәйһиссәлам» (Казан, 1909), «Шөрут әс-салят тәрҗемәсе» (Казан, 1910), «Мөнбиһат тәрҗемәсе» (Казан, 1915) кебек дини китаплар белән бергә дөньяви белем бирә торганнары да бар. Мәсәлән, «Татарча уку» китабы халыкның әдәбиятка омтылышы турында сөйләсә, «Умарталар турында китап» авылда бал кортлары

белән кызыксынучылар булган дигән фикерләр уята. Татар халкының бөек шагыйре «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи асаре» китабы аеруча игътибарга лаек. Кызганычка, китапның башындагы һәм ахыргы берничә бите ертылган, бер карау белән генә китапның ничәнче елгы икәнен әйтеп булмый. Әлеге китап 1914 һәм 1918 елларда басылган. Китапта рәсемнәр булмауны исәпкә алып, аны 1918 елгы басма дип фаразларга мөмкин.

Китаплар барысы да басма. Шулай да әлеге материаллар арасында безнең өчен әһәмиятле булган кулъязмалар да очрады. Алар – васыятьнамә һәм ике дәфтәрдә язылган мөнәҗәтләр (берсен 2014 елның декабрендә авылдагы Нурҗиһан апа бүләк иткән).

Мәчеттә саклана торган китаплардан гына чыгып та, авыл халкы элек-электән бик дини булган дияргә мөмкин. Коръән китапларын исәпкә алмаганда, анда 30 дан артык төрле эчтәлектәге китап барланды. Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» (5 нөсхә), Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (2 нөсхә), «Тәфсире һәфтияк» (5 нөсхә) китапларының берничә нөсхәдә булулары электә аларның халык арасында еш укылганлыгы турында сөйли. «Ислам мәҗәлләсе» («Ислам җыентыгы», елы билгесез, 9–10 саннар) журналының битләре дә бу җирлектәге халыкның бик кызыксынучан һәм дин-белемгә омтылучан булганлыгын күрсәтә.

Авылда яшәүче Казеева Сания Әхмәтҗан кызы (1936 елда туган) әтисе Бариев Әхмәтҗан Фәтхулла улыннан калган «Әнварел-гашыйкыйн», «Тәрҗемәи мохтәсарел викая» китапларын кадерләп саклаган. Сания апаның сүзләренә караганда, әтисе бу китапларны бик яратып укыган һәм үзенең улларының берсенә Әнвәр, ягъни «Нурлы» дип, исем дә кушкан.

«Алты авыл» боҗрасыннан чыгып, Пенза өлкәсендәге татар авылларын барлауны дәвам иттек. Чираттагы Ятмис (Кочалейка, Каменка районы) авылында, нигездә, дини эчтәлекле «Мөхәммәдия», «Тәфсире һәфтияк» (1897), «Тәрҗемә әл-мәсаил вә җаваб әс-саил» (С.-Петербург, 1897), «Мохтәсар иман» (С.-Петербург, 1904) (имам хатип Хәмзә Юныс улы Еникеевта), «Мөхәммәдия» (Казан, 1903), «Рисаләтел сигез җәннәт», «Рисаләи Газизә», «Һәфтияк тәфсире», «Алты бармак», «Гакаид исламия» (Казан, 1899), «Фәзаилеш-шөһүр» (мәчеттә), «Мәҗмәгъ әд-дәгъвәт», «Тәкый гаҗәб» (Абүбикарова Разия Шакир кызында (1948 елгы), С. Бикбулатның «Дин дәресләре» (Казан, 1918), «Әнварел гашыйкыйн» (Еникеева Разыя Ибраһим кызында (1933 елгы) китаплары сакланганлыгы ачыкланды.

Пачелма районының Татаро-Никольское авылы без булган авыллар белән чагыштырганда күпкә кечкенә булса да, сакланып калган китаплар саны буенча бер дә алардан калышмый. Авылда яшәүче 150 ләп кешенең яртысыннан кимрәге генә татарлар икән. Мөнәвәрә Али кызы Маминада (1946 елгы) каенатасы Усман Йосыф улы (1916–1972) белән каенанасы Латыйфа Идиятулла кызыннан (1908–1973) калган кадерләп төрелгән төргәктән кайчандыр болар «Мөхәммәдия»,

«Әхлак рисаләсе», «Һәфтияк шәриф», «Китабел-лөбаб», «Рисаләи нурнамә» (Казан, 1901), «Кыйраәте җәдидә», «Бәдел-мәгариф», «Китаб мөстәтаб. Рәүнәкыль ислам», «Абдәст вә намаз рисаләсе» (Казан, 1899), «Сөбател-гаҗизин», «Татарча уку», «Тәзкия әт-табигать» китаплары булганлыгын дәлилли торган бик күпне күргән аерым басма китап битләре чыкты. Араларында «Әдәбле улмак»ка өйрәтә торган бер кулъязма да бар иде.

Мәрьям Зиннур кызы Мамина (1949 елгы) да авылда мулла булып торган каенатасы Гомәр хәзрәттән калган мирас белән белән таныштырды. «Корбан рисаләсе» (С.-Петербург, 1899), «Тәфсире һәфтияк» (Казан, 1900), «Гыйбадәте исламия»нең дүртенче җөзьэ (Казан, 1904), «Гасры сәгадәт», Г.Барудиның «Сөаль вә җаваплы бәдел мәгариф»е (Казан, 1908, 1911), «Китабы Устуани», «Китабы гыйльме халь» (тәһарәт кыйсьме, 3 нче җөзьэ) (Казан, 1915), Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, «Фәзаилеш-шөһүр», «Намаз нигезләре», «Кыйссасел-әнбия тәрҗемәсе», «Мөгаллимел-гыйбадәт», «Мөгаллиме әүвәл», «Мөгаллиме сани яки әлифбаи гарәби» (Казан, 1914), «Дөнья» (гомуми география дәресләре) (Казан, 1918), «Гокуд саляс», «Хәвас әсма Аллаһ әл-хөснә» (С.-Петербург, 1895), «Тәрҗемәтел әнисел җәлис», «Сөбател-гаҗизин» китапларын туплаган исемлек шактый зур булды. Ләкин аларның сакланыш дәрәҗәләре бик түбән иде.

Аралашкан кешеләремнең барысы да Мамин фамилияле булуы игътибарны җәлеп итте. Тарихи чыганакларга караганда, рус дәүләтенең татарларны чукындыруыннан качып, бу якларга Рязань өлкәсеннән татар морзалары килгәннәр. Татар Никольскоесы авылында татар кенәзләре Маминнар яшәгән. 1917 елда биредә 177 хуҗалыкның 127 сендә Маминнар торган. Шулай итеп, мондагы татарлар әле дә үзләренең кенәз-морза бабаларының тамырларын саклыйлар [Татар Никольскоесы].

Спас районына керүче Шалдавыч авылы мәчетендә «Коръән» китапларыннан тыш «Мөхәммәдия» (Казан, 1902), «Китабе сөлләмел голүм» (Казан, 1887), «Догаи мөстәҗаб» (Казан, 1913), «Җәмигъ әл-хөтеб» (Казан, 1910), «Мәҗалисеш шөһүр», «Һәфтияк шәриф», «Шәраит әл-иман» (Казан, 1903), «Бинаи ислам», «Хәләби тәрҗемәсе» китаплары барланды. Шундый кечкенә генә авылда да Рәйсә Нәҗип кызы Курамшина (1938 елгы), Заһидулла Каюм улы Юлгушев (1939 елгы) («Алты бармак», «Мөхәммәдия», «Китабел әнмүзәҗ», «Догаи исме Әгъзам вә һәм башка шәриф догалар» (Казан, 1909) кебек борынгы ядкәрләрне кадерләп саклаучы кешеләрнең булуы күңелгә рухи ләззәт бирә.

Пенза өлкәсендә алып барылган фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә гарәп хәрефендә татар һәм гарәп телләрендәге барлыгы 140 исемдәге басма китап теркәлде. Кызганычка, алар – нигездә, башы-ахыры булмаган китаплар.

Бүгенге көндә гарәп хәрефле кулъязма китап табу шактый авыр. Без йөргән татар авылларында да аларның булмавы гаҗәп түгел.

Әлеге төбәктә бик еш очраган Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»се, Насретдин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия»се («Пәйгамбәрләр тарихлары»), Әхмәт Биҗанның «Әнварел-гашыйкыйн» («Гашыйклар нуры»), Таҗетдин Ялчыгулның «Рисаләи-Газизә»се, «Бакырган китабы» кебек әдәби ядкәрләр күп еллар буена мәдрәсәләрдә дәреслекләр сыйфатында файдаланылып килгәннәр. Алар, әдәбилек белән бергә дини-дөньяви гыйлемне дә үзләренә сыйдырганнар. «Фән һәм әдәбият бергә кушылу, синтетик бөтен хасил итү аркасында ул китаплар гасырлар буена практик әһәмиятләрен югалтмаганнар, укучыларда эстетик зәвык белән беррәттән, аларга гыйльми информация дә биреп, аң үсешен тәрбияләү өчен дә хезмәт иткәннәр» [Яхин, б. 4]. Һәм халык арасында киң кулланылышта йөргәннәр. Һәр авылда бу китапларның очравы тагын бер кат аларның яратылып укылулары һәм бик популяр булганлыклары турында сөйли.

Әлбәттә, иске китапларга сакчыл карашлы кешеләрнең күп булуы – куанычлы хәл. Әби-бабайлардан калган рухи мирасны шулай кадерләп саклау үзенә күрә бер тәрбия чарасы да булып тора. Киләчәктә бу авылларда гарәп язулы китапларны укучылар булырына ышанасы килә.

Гомумән, хөрмәткә лаек халык яши Пенза өлкәсендә. Алар үзләренең бик гади, ачык йөзле һәм кунакчыл булулары белән күңелгә кереп калдылар.

### Әдәбият


*Зюзин Ф.М.* История татар Пензенского края. Т. 1. URL: https://clck.ru/3DKHjY (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

*Зюзин Ф.М.* История татар Пензенского края. Т. 1. URL: https://fictionbook.ru/author/fattih_muhomyatovich_zyuzin/istoriya_tatar_penzenskogo_kraya_tom_1/read_online.html?page=3 (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

*Мөбәрәкшина Зилә.* Төркиядәге татар генералы Шакир пашаның туганы: Имамның сүзеннән чыгып китап яздым. URL: https://tatar-inform.tatar/news/torkiyadage-tatar-generaly-sakir-pasanyn-tugany-imamnyn-suzennan-cygyp-kitap-yazdym-5860717 (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

*Саляев Е.И.* Татары в истории Пензенского края // Гуманитарные науки. 2007. № 4. С. 122–126.

Татар Никольскоесы. URL: https://clck.ru/3DKJBd (мөрәҗәгать итү көне: 25.08.2023).

Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 392 б.

*Яхин Ф.З.* Борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты: Югары уку йортлары һәм мәктәпләр өчен дәреслек-кулланма. Казан: Раннур. 2011. 188 б.



***Фәйзуллина Фәния Галимулла кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының текстология бүлеге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

*Л.И. Тябина*

## КЕМ УЛ КАМИЛ МОТЫЙГЫЙ?

В статье раскрываются факты сотрудничества татарского поэта Габдуллы Тукая и журналиста, издателя Камиля Мутыги (Тухватуллина) в городе Уральске по выпуску первых татарских периодических изданий. Описываются документы, имеющие отношение к К. Мутыги, которые хранятся в фондах Национального музея Республики Татарстан. На основе этих документов можно утверждать, что К. Мутыги официально был крестьянином Казанской губернии, Свияжского уезда, Кушманской волости, д. Малых Кайбиц. Анализируются стихотворения Г. Тукая, в которых поэт показывает жителей Уральска, в разные годы являвшихся попечителями медресе «Мутыйгия», Муртазу Губайдуллина и Валиуллу Хамидуллина. Они после закрытия газеты «Фикер» («Мысль»), журналов «әл-Гаср әл-җәдид» («Новый век») и «Уклар» («Стрелы») с 1907 года арендовали типографию у К. Мутыги.

**Ключевые слова**. Габдулла Тукай, Камиль Мутыги, татарская литература, татарская журналистика, город Уральск, попечители медресе «Мутыгия».

The article reveals the facts of cooperation between the Tatar poet Gabdulla Tukai and the journalist, publisher Kamil Mutyga (Tukhvatullin) in the city of Uralsk on the release of the first Tatar periodicals. The documents related to K. Mutygi, which are stored in the funds of the National Museum of the Republic of Tatarstan are described. Based on these documents it can be argued that K. Mutygi was officially a peasant of the Kazan province, Sviyazhsky district, Kushman volost, village. Small Kaybits. Analyzing the poems of G. Tukai, in which the poet shows the residents of Uralsk, who in different years were the trustees of the madrasah "Mutyigiya", Murtaza Gubaidullina and Valiulla Hamidullina. After the closure of the newspaper "Fiker" ("Thought"), the magazines "Algasrelid" ("New Century") and "Uklar" ("Arrows"), they rented a printing house from K. Mutyga since 1907.

**Keywords.** Gabdulla Tukai, Kamil Motygi, Tatar literature, Tatar journalism, Uralsk city, trustees of the Mutygia madrasah.

Камил Мотыйгый – күренекле дин әһеле, заманында Җаек шәһәрендә Кызыл мәчет имамы, «Мотыйгия» мәдрәсәсенә нигез салучы һәм мәдрәсәнең мөдәррисе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллинның (1840–1920) улы. Шулай ук ул ТАССРның беренче халык артисткасы, актриса, опера җырчысы Галия Кайбицкаяның (1905–1993) бертуган абыйсы да [Мөбәрәкшина З. Беренче профессиональ...].

Камил Төхфәтуллин 1883 елда Җаек шәһәрендә дөньяга килә. Башта «Мотыйгия» мәдрәсәсендә һәм рус сыйныфында белем ала, аннан соң Мисырда, Каһирә шәһәрендә, мөселман дөньясында иң борынгы, абруйлы ислам университетларының берсе – «әл-Әзһәр»дә укый. Аны тәмамлап, «Мотыйгия» мәдрәсәсендә мөгаллим була.

Г. Тукайның остазы, шагыйрьне шигърият юлына кертеп җибәрүче һәм күпкырлы эшчәнлегенә юнәлеш бирүчеләрнең берсе, журналистикага кызыксыну уятучы да ул. К. Мотыйгый һәм Г. Тукайны татар вакытлы матбугатының чишмә башында торучылар дип атау бер дә артык булмас. Алар татар телендәге өченче газета – «Фикер»не (беренчесе – «Нур», Петербургта 1905 елның сентябрендә; икенчесе – «Казан мөхбире», Казанда, шул елның октябрендә чыга башлый), татар телендә беренче әдәби журнал «әл-Гаср әл-җәдид» һәм татарча беренче сатирик журнал «Уклар»ны чыгара. Г. Тукай әсәрләре тәүге тапкыр шушы басмаларда дөнья күрә. Аларда К. Мотыйгый әсәрләре дә басыла. Аның беренче романы «Бәхетле Мәрьям» 1903 елда ук Санкт-Петербургта нәшер ителә, шунда ук бер пьесасы да чыга. Журналист, нашир һәм язучы гына түгел, татар эстрада башкаручысы, шигырьләрне көйгә салып җырлар иҗат итүче дә ул. Татар халкының «Ай, былбылым» җыры да аның исеме белән бәйле. Көнчыгыш аһәңле бу җырны иң беренче ул башкара, пластинкага яздыра, тиздән җыр бик популяр булып китә. Соңрак замандашы Н. Исәнбәт бу көйгә яңа сүзләр дә яза. Г. Тукайның билгеле шигыре – «Туган тел» дә К. Мотыйгый исеме белән бәйле. Музыка белгечләре бу шигырь «Сәлим бабай көе» дип аталган марш мелодиясенә башкарыла дип белдерәләр. Бу җыр (кайбер тикшерүчеләр аны бәет дип саный), К. Мотыйгый башкаруында XX гасыр башында яздырылып, пластинкаларда сакланып калган. Г. Тукай остазыннан ишеткән шул көйгә «Туган тел»не язган булырга мөмкин. Шулай итеп, К. Мотыйгый «Сәлим бабай»ны җырламаса, Тукай, бәлки, бу шигырьне язмаган да булыр иде, язса да башка мотивка язар иде дип фараз кылыйк... [Мөбәрәкшина З. Габдулла Тукай...].

Ул – Җаекта татар театр труппасы «Сәйяр»гә авыр көннәрендә ярдәм кулы сузучы, революция һәм Гражданнар сугышы елларында татар телендә газеталар чыгаручы, тәрҗемәче, драматург, концертлар куючы. Илле җиде еллык гомер, шуның кырык елга якыны халыкка хезмәт белән узган! Л. Хәмидуллин К. Мотыйгыйны «Күләгәдә калган шәхес» дип атый [Хәмидуллин]. Ф. Галимуллин «Талантлар арасында» повестенда Мотыйгулла хәзрәт гаиләсен, шул исәптән, Камилне дә образ буларак күз алдыбызга китерде. Тумышы белән Җаектан булып, хәзер Санкт-Петербургта яшәүче рәссам, архитектор, язучы Рөстәм Вафиевнең 2011 елда Җаекта чыккан «Господин издатель» исемле хезмәтендә К. Мотыйгый эшчәнлеге Россия мөселманнарының рухи тормышына бәйле рәвештә күрсәтелә, аның шул тормышка йогынтысы яктыртыла. Танылган җырчы, музыка белгече, сәнгать фәннәре кандитаты И. Газиев К. Мотыйгый тавышын халыкка кайтарды, Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда «Граммофон тәлинкәләре нәрсә сөйли?» дигән лекциясендә җырчының тавышын халкыбызга беренчеләрдән булып тыңлатты, мәкаләләрендә һәм диссертациясендә китерелгән мәгълүматлар белән таныштырды [Граммофон тәлинкәләре...].

К. Мотыйгый мирасына килгәндә, Татарстан Республикасы Милли музее фондларында саклана торган тупланмада аңа кагылышлы бик кыйммәтле һәм кадерле ядкәрләр саклана. Ул документларның берничәсе аеруча кызыклы. К. Мотыйгый-Төхфәтуллиннар тупланмалары Г. Тукай әдәби музееның яңа экспозициясен төзегәндә бер барланган иде инде. Әмма ул вакытта андагы бик тә кызыклы ике документка игътибар биреп җиткермәгәннәр.

Г. Тукай әдәби музеенда үткәрелгән «Халкым диеп янган йөрәк…» кичәсенә Камил Мотыйгыйның нәсел дәвамчылары һәм Кайбыч районыннан якташлары килгән иде. Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары Рәмис Хәялиев К. Мотыйгыйның Кече Кайбыч авылы крестьяны икәнен дәлилли торган документның ТР Милли музее фондларында саклануын искә алды. Әлеге документ К. Мотыйгый тупланмасында саклана [Копия договора между К. Тухватуллиным...].

«Тысяча девятсот седьмого года, февраля двадцать восьмого дня, мы ниже подписавшиеся: крестьянин Казанской губернии, Свияжского уезда, Кушманской волости, дер. Малых Кайбиц Мухамет Камиль Мутыгуллович Тухватуллин с одной стороны и Илецкий купец Муртаза Гайнуллович Губайдуллин и *(исеме күрсәтелмәгән. – Л. Т.)* крестьянин Казанской губернии Цивильского уезда Ново-ковалинской волости деревни Тугаевой с другой стороны заключили между собой настоящий договор в нижеследующем:



1) Мы Губайдуллин и Хамидуллин принимаем от Тухватуллина в аренду на два года в аренду с первого марта сего года по первое марта тысяча девятьсот девятого года принадлежащую ему “скоропечатию Прогресс” с платою по пятьсот рублей в год, а всего за два года тысячу рублей, плата эта производится за год вперед с обязательством продолжать в течетие этого срока изделия сле-

дующих периодических органов печати выходящих в Уральске: на русском языке ежедневной газеты “Уральский Дневник” и татарском языке: еженедельной газеты “Фикер”, ежемесячный журнал “аль-Гаср аль-джадид” и ежемесячного журнала “Уклар” (Стрелы).

2) Все типографское имущество передается в арендное пользование по особой оценочной инвентарной описи, подписываемой обеими сторонами, числится под ответственностью арендаторов за его сохранность страхуется от несчастных случаев за их счёт.

3) Всякие поступления денежных сумм по типографским и газетным расчётам, имевшим место по первое марта сего года должны поступать в пользу Тухватуллина.

4) Приём и уволнение служащих и рабочих с ними после первого марта сего года Губайдуллин и Хамидуллин производят совершенно самостоятельно.

Крестьянин Камиль Мутыгуллович Тухватуллин,
Муртаза Губайдуллин, Валиулла Хамидуллин.

Подлинный договор засвид. в подписках у меня нотариуса *(документта шулай. – Л. Т.)* Жаворонкова 28 февраля, по реестру за № 232. Я нижеподписавшийся удостоверяю верность этой копии с подлинником представленным мне Всеволоду Ивановичу Жаворонкову Уральскому нотариусу.

г. Уральск, февраля 28 дня 1907 года, по реестру 232

В.И. Жаворонков
(печать)»

Документтан күренгәнчә, К. Мотыйгый үзенең «Прогресс» типографиясен ике елга М. Гобәйдуллин һәм В. Хәмидуллинга түләү бәрабәренә вакытлыча файдалануга бирә. Килешүдә чыгышын «крестьянин Казанской губернии, Свияжского уезда, Кушманской волости, дер. Малых Кайбиц» дип күрсәтә.

К. Мотыйгый тупланмасында моны дәлилли торган тагын бер документ бар. Ул «Свидетельство-разрешение К. Мутыги издавать газету “Фикер” в г. Уральске» дип исемләнә [Свидетельство-разрешение К. Мутыги...].

«Свидѣтельство.

Настоящее свидѣтельство выдано отъ Военнаго Губернатора Уральской области крестьянину Казанской губерніи Свіяжскаго уѣзда Кушкинской волости деревни Малыхъ Кобицъ Мухаметъ-Камилю Мутыгулловичу Тухватуллину, въ удостовѣреніе того, что ему разрѣшается, под его редакторствомъ и личною отвѣтстенностью, издаватъ в гор. Уральскѣ въ собственной типографіи, находящейся въ зданіи Русско-Торговаго Промышленнаго Банка, на татарскомъ языкъ еженедѣльную политическо-литературно-общественную газету «Фекръ» (Мысль), подписная плата на которую три рубля въ годъ.



Что подписомъ съ приложенiемъ казенной печати удостовѣряется. Гербовый сборъ полученъ.

«4» января 1906 года.
Гор. Уральскъ.

Военный Губернаторъ,
Генералъ-Лейтенантъ
(подпись)

Печать Военного Губернатора Уральской области

Старшiй Совѣтникъ
(подпись)

И. д. Дѣлопроизводителя
(подпись)»

Шулай итеп, документлар буенча Камил Мотыйгый Кайбыч кешесе саналган.

«Таныклык»ка Урал өлкәсе хәрби губернаторы, генерал-лейтенант Николай Владимирович Родзянко кул куйган. Аның турында да мәгълүмат бар. Ул 1905 елның 16 маеннан 1908 елга кадәр Урал өлкәсе хәрби губернаторы вазифасын үти. Губернатор Николай Родзянко – III һәм IV чакырылыш Дәүләт думасы рәисе, сәяси эшлекле, 1917 елгы Февраль революциясе лидерларының берсе Михаил Владимирович Родзянконың абыйсы. Николай II нең тәхеттән ваз кичүе белән бәйле вакыйгалар барышында М. Родзянко Дәүләт думасы Вакытлы комитетын җитәкли. А. Гучков, П. Милюков, В. Шульгиннар әгъза булган, Россия тарихында эз калдырган бу Комитет элеккеге хакимиятне юкка чыгару максатын куя. Родзянко фамилиясе белән Камил Мотыйгый әле тагын бер очраша. 1917 елда язмыш аны да Петроградка китерә. Аның революция көннәрендәге эш-гамәлләре турында профессор Ф. Галимуллин, документларга нигезләнеп, болай ди: «Санкт-Петербургта Владимир Ленин җитәкчелегендәге хөкүмәт эшли, Ленин эшләгән бүлмәдә Камил Мотыйгый 1918 елда «Ярлы халык» дигән татарча газета чыгара башлый. Беренче саны 1918 елның 6 гыйнварында басыла (барысы 2 саны чыга). Нашире – Милләтләр эшләре комиссариаты, мөхәррире Камил Мотыйгый була». Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре аңлатуынча, газета битләрендә Совет хөкүмәтенең беренче декретлары, илдәге сәяси вазгыять турындагы мәкаләләр урын ала [Мөбәрәкшина З. Фоат

Галимуллин: Ленин эшләгән...]. Кызыклы язмалар арасында – большевикларның мөселманнарга Коръәннең Эрмитажда сакланган борынгы басмасын тапшыруы турындагы хәбәр дә бар. «Ярлы халык» газетасы чыгудан туктагач, укучыларга «Чулпан» газетасын җибәрә башлыйлар.

«Соңрак Камил Мотыйгый Мәскәүдә Тышкы эшләр министрлыгының Көнчыгыш телләре буенча хөкүмәт составында тәрҗемәче булып эшли. Аннан соң ул Җаекка кайта. «Яңа фикер» газетасын чыгара башлый. Кайда гына булуына карамастан, газета чыгара. Аның бу вакыттагы эшчәнлеген исәпкә алып, Казакъстан Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлыйлар», – дип белдерә Ф. Галимуллин. [Мөбәрәкшина З. Фоат Галимуллин: Ленин эшләгән...].

Камил Мотыйгый белән бәйле беренче документта телгә алынган Мортаза Гобәйдуллин исеме Г. Тукай иҗатында да берничә тапкыр очрый. Шагыйрьнең 1904 елда иң беренче язган шигырьләреннән берсе «Тугды, көн тугар кеби, бер сахибе һиммәт гани...» («Туды, көн кебек, бер игелек иясе бай…») дип башлана. Үзе исән чакта басылмаган, 1904 елда «әл-Гаср әл-җәдид» журналының ноябрь аенда чыккан 15 нче санында урнаштырылган. Беренче тапкыр Г. Тукайның 1975–1976 елларда нәшер ителгән дүрттомлыгындагы «Өйрәнчек шигырьләр» бүлегенә шуннан алынып кертелә. Шәкерт Тукаев «Мотыйгия» мәдрәсәсе бинасын салдырткан, аны азмы-күпме булса да матди яктан тәэмин итеп торган, аның баш, фәхри, шәрәфле назире (караучысы, попечителе) саналган Мортаза байның соңыннан мәдрәсәгә ярдәм итүдән баш тартуы турында яза. Шигырьдәге юллар шул турыда:

Моннан элек барсы да иске иде.
Мәдрәсә күңле белән әйтә иде;
Диде: «Соң ник мине сез бакмыйсыз?
Ник карамыйсыз да ник чистартмыйсыз?»
Елый иде: «Хуҗам-бай үлдеме? – дип. –
Әллә ул шартладымы, бөлдеме?» – дип.
Әйтә иде: «Мортаза бай! Мортаза бай!
Син нигә бигрәк саран булдың болай?
Нигә салдың син мине – карамагач,
Үз малың үз файдаңа ярамагач.
Мортаза бай! Син төзәтмәссең бугай –
Мин телимен Алладан икенче бай».

[Тукай Г. *** («Тугъды, көн тугар кеби…»)]

«Әл-Гаср әл-җәдид» журналында урнаштырылган «Мәҗлесе гыйльмия» дигән кереш сүзгә булачак шагыйрьнең «Мотыйгия» мәдрәсәсен төзекләндергәч беренче тапкыр уздырылган мәҗлестә сөйләгән, үзе тарафыннан «зәгыйфь кенә бәетләрем» дип бәя бирелгән шушы шигыре дә кергән. Кереш сүз «Бундан аңламак мөмкин ула белүр ки, хәмед улсын, мәдрәсәи «Мотыйгиядә» гүзәл әдиб вә

шагыйрьләр дә вар...», дигән сүзләр белән тәгәлләнә. Шәкерт Тукаев бу шигыре белән миллионер Мортаза Гобәйдуллинны намус белән эш итәргә чакыра, аны алыштырган яңа назир Вәлиулла Хәмидуллинга мәдхия укый.

Туды, көн туган кебек, бер игелек иясе бай;
Мактатырга мәҗбүр итте, ихтыярсыздан бугай.

Исме аның Вәлиулла, димәк, ул – изге кеше;
Мөхәммәд динен яклаучы, пәйгамбәрләр сөюче.

Бизәде мәдрәсәне ул асылташ кебек итеп;
Гүзәллеге оҗмахны искә төшерерлек итеп.

Мәктәп ашханәсен, юыну бүлмәсен яңартты;
Тырышлыгы белән кыен эшкә чарасын тапты.

Килде дә ямьсез, килбәтсез урыннарны төзәтте.
Тау кисәр эшлекле ул – тотынса, дөнья төзәтер.

Мәхдүм өчен дә бер бүлмәне гүя җәннәт итте.
Мәхдүм дә аны үзенә тору урыны итте.

[Тукай Г. *** («Тугъды, көн тугар кеби…»)]

Шәкерт Тукаев теләге кабул булып, мәдрәсәнең яңа, икенче назире булган Вәлиулла Хәмидуллинның эшләре турында ул менә ничек яза:

Күп тә үтмәде – теләк кабул булды,
Кабат ялваруга урын калмады:

Чыкты аңсыздан Хәмидуллин Вәли,
Нишләгәнен санап чыктым бит әле!

Ул илаһи осталыкка ия икән,
Тумыштан ук игелекле кеше икән.

Алла мондыйларның санын арттырсын,
Әйдә, яңа гасыр бәхетле булсын!

[Тукай Г. *** («Тугъды, көн тугар кеби…»)]

Яңа попечитель Вәлиулла Хәмидуллин «Копия договора между К. Тухватуллиным и М. Губайдуллиным о передаче в аренду «Скоропечатию Прогресс» дигән документта исеме күрсәтелмәгән «крестьянин Казанской губернии Цивильского уезда Ново-ковалинской волости деревни Тугаевой» булып чыга. Нотариус Жаворонков раслаган бу документта Вәлиулла Хәмидуллин фамилиясе ике тапкыр искә алына [Копия договора между К. Тухватуллиным...].

Г. Тукайның Җаекта 1905 елда язылган шигырьләренең берсе – «Бу көндә бер сарай ачды әһали» дип атала. Язылу һәм басылу тарихы шулай ук Мортаза Гобәйдуллин һәм Вәлиулла Хәмидуллин исемнәре белән бәйле. Эчтәлеге буенча шигырь Җаек шәһәрендә «Ка-

зан» кунакханәсе ачылуга багышлана. Кунакханәнең хуҗасы Мортаза бай Гобәйдуллин аны бик бай, зиннәтле, заманча итеп эшләтә.

Бу көндә кешеләр бер сарай ачтылар, –
Үзе гүзәл, тиңдәше аз, кадере югары.

Чәй һәм аш савытларының торышы гаҗәп:
Энҗеләр кебек тезелгәннәр.

Идәнендә – зифа паласлар;
Һәр ягы зиннәтле – өсләре дә, аслары да.

Һәр ягы көзгеләр белән бизәлгән;
Түшәмдә кандилләрдә шәмнәр балкый.

Кандилләренең шәмнәре айга охшый –
Бизәлүе «Йолдыз сарае»ныкына охшый.

[Тукай Г. *** («Бу көндә бер сарай ачты әһали…»)]

Шагыйрь тагын бер нәрсәгә игътибарны юнәлтә:

Өстәлендә төрле газеталар ята –
Һәрберсе безнең хәлебезгә бәйле.

Аның фикеренчә, бу урынны кунакханә генә түгел, клуб дип тә атарга була. Ул милләтнең үсеше, даны өчен хезмәт итәчәк, дип ышана шагыйрь.

Җиһанда охшашы аз бер клубтыр –
Җанга шатлык һәм күңелләргә нур.

Бер теләктәге кешеләр бер сүздә булып,
Мәйданга чыгып, зур осталык күрсәттеләр.

Тырышып, күп акчалар тотып һәм
Төрле-төрле чаралар күреп,

Ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә!
Милләтнең чире – керешмәүдер эшкә.

Дәвам итсен бу бакча, озак яшәсен,
Һәм шөһрәте телләрдә дастан булсын!

[Тукай Г. *** («Бу көндә бер сарай ачты әһали…»)]

Г. Кариев үзенең «Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы» дигән истәлекләрендә шагыйрь турында: «1906 елның ахырларында, октябрь числасында, мәдрәсәдән чыгып, «Казан» миһманханәсендә 10 айлар чамасы торып, 1907 сәнәнең ахырларында – көз көне Казанга килде» [Кариев, 2015, б. 89]. 1905 елда ачылган «Казан» миһманханәсе аңа кадәр «Коммерческий клуб» (халык телендә «Каружный клуб») була. «[…] без Габдулла әфәнде берлә, 7 нче нумиргамы, 15 сумга кердек. Бу вакыт Габдулла әфәнде “Фикер”дә хезмәт итә иде. […] Габдулла әфәнденең жалунйәсен, “Мөхәррирге”

шигырен язгач, Камил әфәнде 20 сум ясаган иде, һәм бер-ике ай 20 сумнан жалунйә алды» [Кариев, 2015, б. 94].

Димәк, иҗатын әле башлап кына җибәргән шагыйрь, журналист һәм публицист Г. Тукаев Җаекның иң кыйммәтле, зиннәтле кунакханәсендә яшәгән. Казанга Г. Тукай, мәдрәсәне ташлап чыккан мескен шәкерт булып түгел, ә үзенең һәм талантының бәясен тоя, чамалый гына түгел, ә белә торган, үзен гайрәтле, көчле баһадирлар Гали, Рөстәмнәргә тиңләгән, Пушкин, Лермонтовка таба үрләгән яшь шагыйрь булып кайткан.

Г. Тукайның «Матбага берлә уйнаган бер байга» шигыренең язылу тарихы да Мортаза Гобәйдуллинга барып тоташа. Бу турыда Г. Кариев үзенең шул ук «Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы» дигән истәлекләрендә яза. Ул «Фикер» газетасы һәм «әл-Гаср әл-җәдид» журналының Уральскиның күренекле мөселман сәүдәгәре Мортаза Гобәйдуллин кулына күчеп тә, аның гамәлләре аркасында тернәкләнеп китә алмавы, 1907 елның май азагында ябылуы, матбаганың да сатылуы мөнәсәбәте белән язылган. Әлбәттә, шулкадәр көч куелган басмаларның ябылуына Г. Тукайның ачуы кабарган, һәм ул шул ачуын бик усал шигыре аша турыдан-туры Мортаза Гобәйдуллинга юнәлдергән. Академик басмаларда шагыйрьнең әсәрләре хронология буенча урнаштырылган дип фикер йөртсәк, шигырь 1907 елда язылган һәм 1907 елда Казанда «Габдулла Тукай шигырьләре. «Шигырьләр көтепханәсе»ндән 4 нче дәфтәр» китабында басылып та чыккан.

Булды кондыз, аслы үзгәрде диеп мин күрсәм үз, –
Хәзрәтеңне белмәдем! – Дуңгыз икәнсең син һәнүз!

Матбага алгач, сине инсане галидер дисәм, –
Кайда галилек сиңа, хали икәнсең син һәнүз!

Тугры юлны тапты бу, тәүфыйк имеш, ярый, дисәм, –
Лотфе Хактан пакь икән, гари икәнсең син һәнүз!

Гыйльмә нашир булды бу, яхшы кеше булды, дисәм, –
Нәйләем ки, бик кабих, шахшы икәнсең син һәнүз!

Бу сәхи, бер бай кеше тәкмил итәр барын, дисәм, –
Бер хәсис, мәгърур икән, карун икәнсең син һәнүз.

Бу ганидер, милләтә ярдәм вә гаүнәйләр, дисәм, –
Иске Нәмруд, Самри, Фиргавен икәнсең син һәнүз!

«Белдем инде милләтең дәрден», – дисең, борчак атып, –
Файдасы юк бер хәрәм корсак икәнсең син һәнүз!

*

Туктале, бер көн килер дә, өйрәтер, әлбәт, ләхет, –
Милльёның ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!

Бу кадәр зур, галишан милләт белән ник уйнадың?.. –
Ахыры, син милләти каткан тирең дип уйладың!

Туктале, алдыңда, дуст, мәхшәр дә бардыр, суд та бар, –
Каһре Хак бар; тиз янар корсагың – анда ут та бар!

Анда хакимнәр дә алтыннарга һич алданмыйлар;
Анда адвокат та юктыр, – акчага ялланмыйлар.

И аягың коргыры! намусымызны таптадың;
Золмәтеңнең хөрмәтенә шәмсемезне каплады.

Син үзең сүнсәң сүнәрсең, бу кояш сүнмәс әле;
Ул мөкатдәс, залимең әмренә тиз күнмәс әле.

Ташла тиз! пычратма матбугатны, кит! бер якка кит!
И печән өстендә өргән һәм талашып яткан эт!

[Тукай Г. Матбага берлә уйнаган бер байга]

Габдулла Тукай энциклопедиясендә Мортаза Гобәйдуллин һәм Вәлиулла Хәмидуллин турында мәкаләләр бирелгән. Ләкин, кызганычка каршы, бу шәхесләрнең тормышы турында мәгълүмат бик аз. Мортаза Гобәйдуллин – Җаек миллионеры, Вәлиулла Хәмидуллин – мөхәррир, нашир, «Мотыйгия» мәдрәсесенең назире (попечителе), Җаек шәһәре мөселманнарының җәмгыяте хәйрия рәисе. Икесенең дә туган-үлгән еллары күрсәтелмәгән. Г. Тукайның М. Гобәйдуллин белән бәйле шигырьләре санап үтелгән. В. Хәмидуллин 1941 елның июнендә Г. Тукайның Җаектагы тормышы, «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укуы һәм К. Мотыйгый типографиясендә эшләве турындагы истәлекләрен 1939–1941 елларда Татарстан Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты директоры Хәсән Шабановка сөйли, әңгәмәнең машинкада басылган тексты хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондында саклана (9 ф., 4 тасв., 145 эш). Аларда Г. Тукайның Җаек чоры тормышы белән бәйле фактлар (мәдрәсәдә каравылчы булып эшләве, аннан соң 20 ләп баланы җәдитчә укытуы, фарсы, төрек, казакъ, рус телләрен яхшы белүе, рус классикларын татар теленә тәрҗемә итүе) китерелә. Истәлекләрендә В. Хәмидуллин фатирының чормасында Г. Тукай кульязмаларын саклавы турында да хәбәр итә.

Мортаза Гобәйдуллин һәм Вәлиулла Хәмидуллинны Г. Тукай «Фикер» газетасындагы язмаларында да еш телгә ала. «Җәмгыяте хәйрия» рәисе буларак В. Хәмидуллиннең эшчәнлеге газетаның «Шәһәр хәбәрләре» рубрикасында яктыртыла. Ә М. Гобәйдуллинга бәйле язма һәм очерклары сатирик эчтәлекле, сарказм белән сугарылган, шагыйрь аны телгә алып узганда гына да наданлыгын, тупаслыгын, әхлаксызлыгын ассызыклый. Ул –тискәре герой өлгесе. Г. Тукай Мортаза байның гаилә әгъзалары белән таныш була. Аның беренче, өйрәнчек шигырьләре шуларның тормышы-көнкүрмеше турында. Шагыйрьнең

сабакташы Шәриф Каюмов истәлекләре аша укучыга килеп ирешкән *** «Мөгаллим Нурый...» шигыренең язылу датасы, замандашлары хатирәләренә таянып, 1902 ел ахыры – 1903 ел башы дип санала. Г. Тукай үзе исән чакта басылмаган. 1956 елдан башлап академик басмаларда шул истәлектән алынган текст бирелә [Каюмов, 2015, б. 143–144]. Шагыйрьнең замандашлары, «Мотыйгия» мәдрәсәсендә белем алган Ш. Каюмов, Г. Ишмөхәммәтов, Н. Вәлиев һәм бу мәдрәсәдә дәрес биргән К. Мотыйгый истәлекләреннән күренгәнчә, мөгаллим Нурый яки Нуриәхмәт хәлфә Һидиятуллин – Мортаза Гобәйдуллинның кияве, педагогик эшчәнлеген 1886 елда Оренбург өлкәсендә башлый. 1898–1919 елларда «Мотыйгия»дә укыта. Мисырда белем алып, 1902 елда Җаекка кайткан. Әтисе Мотыйгулла хәзрәт урынына төрле дәресләр уздыра башлаган К. Мотыйгый мәдрәсәдәге «шактый үзгәрүләр» турында искә ала: «Мәдрәсәбезгә Оренбург вилиятеннән Нурахмәт исемле бер ысул җәдидә мөгаллиме килү сәбәпле, иске хәлфәләрдә укый торган барча кечкенә шәкертләр шул мөгаллимгә күчкәннәр иде. Шуның өчен иске хәлфәләр арасында байтак низаглар булып, мәдрәсәбездәге бик күп зур шәкертләр мәдрәсә идарәсенә вә хосусан бу эшкә мөсагәдә (ирек) бирүче әткәм Мотыйгулла хәзрәткә ачуланып, үзләренчә забастуфка ясап, мәдрәсәдән чыгып киткәннәр иде». Мәдрәсәнең почётлы караучысы һәм сәүдәгәр-миллионер Мортазаның кияве булганга Мотыйгулла хәзрәт аның өчен аерым шартлар булдырырга мәҗбүр буламы? Ул мөгаллим Нурига кечкенә шәкертләрне җыеп бирә. Бәлки, җәдитчә, яңача нәкъ менә башлангыч сыйныфтан укыта башлау зарур икәнен аңлагандыр?! Зур шәкертләр ни өчен забастовка ясаган? Алар да яңача, җәдитчә укыткан хәлфәдә гыйлем эстәргә теләгәнме? Истәлекләрләрдә Нуриәхмәт хәлфәнең мәдрәсә программасына дөньяви фәннәрне кертүе, дәресләрдә тактадан, географик карталардан файдалануы турында язылган [Каюмов, 2015, б. 143–144]. Ә Г. Тукай бу хәлфә турында: «Мөгаллим надан – Укымый калган; Укыта ялган», – дип яза. Ш. Каюмов истәлекләрендә Г. Тукайның аны ни өчен яратмавын аңлата: «Нури хәлфәне ул яратмый шул сәбәптән: Нури хәлфә бай кияве булуы, зур чалма урап хәзрәтләр, ишаннар мәҗлесеннән калмавы, ике хатын белән торуы, табигый авызын салдаттан калу өчен агу белән кыйшайтып һәрвакыт кеше мыскылларга торган уродлыгы, мәдрәсәдәге хәлфәләрдән, шәкертләрдән аерым йөрүе, аларга катнашмавы, үзен бик белемле булып йөрүеннән» [Каюмов, 2015, б. 143–144]. Г. Тукайның 1905 елга кадәр язган шигырьләре, Ш. Каюмовның СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалында саклана торган истәлекләреннән алынып, беренче тапкыр 1955–1956 елларда чыккан академик басманың «Искәрмәләр» өлешендә дөнья күрә. 1985 елгы биш томнан торган академик басмада әдәбият галиме, текстолог Рашат Гайнанов бу тупланманы «Кушымта»га «Тукайга нисбәт ителгән һәм өйрәнчек шигырьләр» итеп кертә [Тукай Г. *** («Мөгаллим Нурый…»)].

«Кем соң ул Нуриәхмәт хәлфә? Ни өчен беренче шигырьләреннән берсен Тукай аңа багышлаган?» – дигән сорауларга Рашат Гайнанов болай җавап бирә: «Надан, әхлаксыз, аумакай-монафикъ табигатьле, солдаттан калу өчен әллә нәрсәләр эчеп, үзен бозган, авызы кыйшаеп, күзе зәгыйфьләнеп калган абруйсыз бер зат. Мәдрәсә тормышының уртасында кайнаган уналты яшьлек Тукай киләчәктә иҗат ителәчәк сатирик әсәрләренә үзенә күрә бертөрле аккорд булган бу «өйрәнчек» шигырен менә шушындый шартлар эчендә язган» [Бәхтияров, 2015, б. 395–396]. Шулай итеп, бу әсәрнең тарихы шагыйрьнең Җаектагы тормышын, иҗатының чишмә башында торган вакыйгаларны, характеры һәм аның шәхес буларак формалашуына тәэсир иткән кешеләрне күз алдына китерергә ярдәм итә.

Мортаза Гобәйдуллинның улы Садыйк (1880–1929) белән бәйле вакыйгалар да Г. Тукай иҗатында урын тапкан. Академик алтытомлыкның «Өйрәнчек шигырьләр» бүлегендә бирелгән «Туйга бардым» шигыре шагыйрь үзе исән вакытта басылмаган. Ул академик дүрттомлыкның 1 нче томында, Ш. Каюмов истәлекләреннән алынып, «Искәрмәләр»нең кереш өлешендә урын алган. Язылу датасы күрсәтелмичә, «Тукайның 1905 елга чаклы ук язылган» шигырьләренең берсе дип күрсәтелгән.

Шәриф Каюмов үзенең «Г. Тукай турында минем истәлегем. 1903–1906 еллар» язмасында бу турыда: «Бервакыт Уральскиның атаклы бае Мортаза малаена никах укыту өчен Уфадан мөфти чакырып, туй мәҗлесенә хәлфәләр, шәкертләр, яшүсмер балалар барды. Тукай да бу мәҗлескә барды. Безнең мәдрәсә Мортаза бай карамагында булгангамы, барыбыз да бардык. Туй мәҗлесенә мичкәләп-мичкәләп кымыз китертелгән иде. Ул туйда Тукай хәлфәләр, шәкертләр янында булмыйча, итекчеләр, читекчеләр, итчеләр, тиречеләр, кибетчеләр табынына туры килде.

Тукай туй мәҗлесеннән соң түбәндәге шигырен җырлый иде:

Туйга бардым мин бүген: эчтем кымыз,
Кеше бик күп – бүлмәбез булды тыгыз,
Күп эчелгән – шартлый язды корсагым,
Һич үкенмим, андый туй булмас тагын.
Итчеләр, тиречеләр бик күп иде,
Ит исе, тире исе аңкый иде.
Таз Сабир, сучы Шакир, Күктәк Галим,
Чакырылган Мөрсәлим һәм Мөстәкыйм.
Бар да сөйли кайда нәрсә алганын,
Бу базарда күпме табыш калганын.
Шулкадәр туйдым тире, ит исенә,
Валлаһигазим, икенче бармамын», –

дип искә ала [Тукай Г. *** («Туйга бардым мин бүген, эчтем кымыз…»)].

Садыйк Гобәйдуллинның туе 1903 елда көз башында булган, шигырь туйдан соң, «кайнар эздән» иҗат ителгән, дип фараз кылып,

аның язылу вакытын ачыклый алабыз. Гобәйдуллиннар гаиләсендәге тәртипләр турында Г. Тукай бер елдан, 1904 елда яза. Татарстан Республикасы Милли музеенда К. Мотыйгый архивында 1904 елның 19 октябрендә язылган кульязма «әл-Гаср әл-җәдид»нең 12 номеры саклана. Журналда шундый юллар бар: «Бай углы Садыйк Гобәйдуллин яңа хатынын хәбестә саклайур, хәтта нә мәҗлесләргә алып чыксын, нә үзе мәҗлес җыйсын. Артык әсир төшерде вә кыйный да, имеш» [Бәхтияров, 2015, б. 395–396].

Шулай итеп, Г. Тукайның Җаек чорындагы замандашларын: язучы, нашир, җырчы К. Мотыйгый һәм Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин, «Мотыйгия» мәдрәсәсенең назире Вәлиулла Хәмидуллин, Г. Тукай әсәрләрендә сатира утына тотылган сәүдәгәр-миллионер Мортаза бай Гобәйдуллин, аның улы Садыйк һәм кияве Нуриәхмәт хәлфәләрне документлар, истәлекләр, мәкаләләр, шигырь һәм әдәби әсәрләр аша күз алдына китерү мөмкинлеге бар. Шагыйрьне шәхес буларак аңлау һәм күзаллау өчен аның даирәсен дә яхшы белү кирәк.

Г. Тукайның тормыш юлын һәм даирәсен яктырткан документларны өйрәнү дәвам итә, табылган материаллар шагыйрьнең иҗаты белән бәйле рәвештә музей тамашачысына тәкъдим ителә, төрле чаралар уздырганда яңа мәгълүмат сыйфатында кулланыла.

**Әдәбият**

*Бәхтияров В.* Тукай турында кайбер истәлекләр // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. Казан: Җыен, 2015. Б. 395–396.

Граммофон тәлинкәләре нәрсә сөйли? URL: https://shahrikazan.ru/news/m%D3%99d%D3%99niyat/grammofon-tlinklre-nrs-syli (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Кариев Г.* Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. Казан: Җыен, 2015. Б. 88–99.

*Каюмов Ш.* Г. Тукай турында минем истәлегем. 1903–1906 нчы еллар // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда. 1 т. Казан: Җыен, 2015. Б. 143–144.

Копия договора между К. Тухватуллиным и М. Губайдуллиным о передаче в аренду «Скоропечатию Прогрес» // Национальный музей Республики Татарстан. КП–23693-205.

*Мөбәрәкшина Зилә.* Беренче профессиональ татар җырчысы, язучы, нашир: Камил Мотыйгый турында кызыклы фактлар. URL: https://intertat.tatar/news/berence-professional-tatar-yrcysy-yazucy-nasir-kamil-motyigyi-turynda-kyzykly-faktlar-5858651/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Мөбәрәкшина Зилә.* Габдулла Тукай «Туган тел» шигырен Камил Мотыйгый җырлаган көйгә язган булырга мөмкин. URL: https://tatar-inform.tatar/news/gabdulla-tukai-tugan-tel-sigyren-kamil-motyigyi-yrlagan-koiga-yazgan-5869512 (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Мөбәрәкшина Зилә.* Фоат Галимуллин: Ленин эшләгән бүлмәдә Камил Мотыйгый татарча газета чыгарган URL: https://tatar-inform.tatar/news/foat-galimullin-lenin-eslagan-bulmada-kamil-motyigyi-tatarca-gazeta-cygargan-5869389 (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

Свидетельство-разрешение К. Мутыги издавать газету «Фикер» в г. Уральске // Национальный музей Республики Татарстан. КП–23693-123.

*Тукай Г.* *** («Тугъды, көн тугар кеби…»). URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/1904/tugdy-kon-tugar-kebi/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Тукай Г.* *** («Бу көндә бер сарай ачты әһали…»). URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/1905/bu-konde-ber-saraj-achty-ehali/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Тукай Г.* Матбага берлә уйнаган бер байга. URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/1907/matbaga-berle-ujnagan-ber-bajga/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Тукай Г.* *** («Мөгаллим Нурый…»). URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/tukajga-nisbet-itelgen-shigyrler-1901-1907/mogallim-nuryj/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

*Тукай Г.* *** («Туйга бардым мин бүген, эчтем кымыз…»). URL: http://gabdullatukay.ru/works/poem/tukajga-nisbet-itelgen-shigyrler-1901-1907/tujga-bardym-min-bugen-echtem-kymyz/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 9 ф. 4 тасв. 145 эш.

*Хәмидуллин Лирон.* Күләгәдә калган шәхес: Камил Мотыйгый. URL: http://gabdullatukay.ru/tukay-environment/environment/liron-hemidullin-kulegede-kalgan-shehes-kamil-motyjgyj/ (мөрәҗәгать итү көне: 15.08.2024).

***Тябина Лена Ивановна,***
*Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музее*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 35.073.532.2

***Р.Ә. Абзалина***

# ГАБДУЛЛА МӨХӘММӘТГАРИФ УЛЫ «МОТЫЙГИЯ» МӘДРӘСӘСЕНДӘ

В статье рассматривается вопрос об истории поступления в фонды Национального музея Республики Татарстан групповой фотографии шакирдов медресе «Мутыгия» в г. Уральске (нач. XX века), среди которых запечатлён татарский поэт Габдулла Тукай.

**Ключевые слова:** Национальный музей Республики Татарстан, медресе «Мутыгия», Габдулла Тукай, Нигмат Сафович Валеев.

The article considers the issue of the history of the receipt of group photographs of shakirds of the madrasah «Mutygia» in Uralsk at the beginning of the XX century into the funds of the National Museum of the Republic of Tatarstan among which the Tatar poet Gabdulla Tukai is depicted.

**Keywords:** National Museum of the Republic of Tatarstan, madrasah «Mutygia», Gabdulla Tukai, Nigmat Safovich Valeev.

Габдулла Тукайның XX гасыр ахырында гына фәнни даирәгә билгеле булып, күптән түгел шагыйрь тормышы һәм иҗатына багышланган альбом-җыентыкларда үз урынын алган фоторәсемнәренең берсе 1985 елда табылган иде.

Элегрәк, Г. Тукайның Яңа Кырлай авылында ачылачак музее өчен экспонатлар эзләп, туплап йөргән вакыт татар күңеленә матур итеп кереп урнашкан, шагыйрьнең кечкенә чакта сәкедә бәрәңге белән катык ашап утырган кыяфәттә ясалган рәсеменең авторы Хаҗиморат абый Исхак улы Казаковның (1914–1984): «Минем Тукайның шәкерт вакытыннан берәр сюжет эшләп карыйсым килә, аңа охшаган бер малай белмисеңме?» – дип сораганы истә.

Ниһаять, Г. Тукайның Казандагы әдәби музеен төзегәндә, махсус эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, Тукайның шәкерт вакытындагы чын фоторәсеме табылды. Ул Уральскида Мотыйгулла Төхфәтуллин мәдрәсәсендә укыган Нигъмәт Сафа улы Вәлиев (1898–1974) коллекциясе белән музейга керде. Анда Уральскида Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укыган бер төркем шәкертләр арасында Габдулла Тукай – беренче рәттә уңнан икенче тезләнеп утырганы. Фотоның артына музейга килеп эләккәнче үк «Г. Тукай I ряд справа 2) Г. Тукай» дип язып куелган, кабул итү акты икегә бүленеп, 353 һәм 353[а] номерлары белән 1984 елның 26 декабре һәм 1985 елның 25 июлендә теркәлгән.

Фоторәсем (музейда теркәлгән номеры 19698-101) белән бергә Нигъмәт Вәлиев Уральскида Мотыйгулла Төхфәтуллин мәдрәсәсендә аңа белем биргән остазы Нуриәхмәт Һадиуллин турында истәлекләрен дә язып тапшырган. Истәлек язмасы бик төзек телдә,

редакцияләмичә матбугатка бирерлек эзлеклелек белән язылганга күрә, укучылар игътибарына тулысынча тәкъдим итәргә булдык:

*«XX гасырның башында Уральск шәһәрендә ир балалар өчен 4 татар мәктәп-мәдрәсәсе бар иде.*

*Шулар арасында агач мәдрәсә дип йөртелгән, бер озынчарак ачык коридор белән тоташкан, ике бинадан торган мәдрәсәне әйтергә кирәк.*

*Мәдрәсәнең мәгънәви җитәкчесе үзенең прогрессив карашлары белән билгеле булган Мотыйгулла мулла Төхфәтуллин иде.*

*Бу ике бинаның урам ягына караганы чын мәгънәсе белән мәдрәсә булып, монда зур шәкертләр укыйлар һәм шунда торалар да иде. Билгеле булганча, бу мәдрәсәдә бөек шагыйрь Габдулла Тукай укыган булган. Агач мәдрәсәнең йортка караган, аскы каты таштан, өске каты агачтан салынган икенче бинасының өске каты (асты ашханә хезмәтен үтәгән) мәктәп булып торды.*

*Монда озак вакытлар укытучы булып Нури-Әхмәт Һидиатуллин дигән кеше эшләде. Шуңа күрә, бу мәктәп халык арасында, "Нурый хәлфә мәдрәсәсе" дип билгеле булды һәм зур шөһрәт казанды. Озак еллар буенча укытып, күпсанлы балаларга беренче белем биргән Н. Һидиатуллин турында берничә сүз әйтмәкче булабыз.*

*Нури-Әхмәт мөгаллим бу мәктәптә узган гасырның, булырга кирәк, 90 нчы елларының башыннан алып, 1919 елга, Уральск шәһәрендә совет власте урнашканга кадәр укытып килде. 1919 елның җәендә, Гражданнар сугышы вакытында, снаряд төшеп, агач мәдрәсәнең бер бинасы җимерелгән иде инде.*

*Н. Һидиатуллинның укытучы буларак халык арасындагы авторитеты турында сүз барганда, иң элек аның шәһәрдә беренче һәм ялгызы буларак, иске кадимчә укытуны ташлап, аңа караганда күп дәрәҗә нәтиҗәле һәм прогрессив булган яңа ысул (ысул-әл-җәдид) куллануын әйтергә кирәк.*

*Икенчедән, Нури-Әхмәт мөгаллимнең, тик Коръән һәм кайбер дини китаплар укыту белән канәгатьләнмичә, зур кыюлык белән, моңа кадәр бүтән мәдрәсәләрдә һич булмаган «дөнья» фәннәрен мәктәп программасына кертүе уңай күренеш булды. Без хисап (арифметика) һәм географиядән алып барылган дәресләрне әйтәбез. Географиядән (ул заманда җәгърафия дип йөртелә иде) балалар кулында бер дәреслек бар иде әле. Әлбәттә, бу нәрсәләр тирән итеп укытылмады, шулай да балалар башлангыч белемнәрне яхшы үзләштерү дәрәҗәсенә җитәләр иде. Мәсәлән, хисап дәресләрендә дүрт гамәлгә иң гади мисаллар һәм мәсьәләләр чишүгә өйрәтелә иде. Хисап дәресләре кара тактага яздырып эшләнә иде. География укытканда Нури-Әхмәт мөгаллимнең географик карта белән файдаланганын күрсәтеп үтәргә кирәк.*

*Бу карта мәктәпнең бер стенасына асып куелган иде.*

*Укучы балалар классларга (ул заманда сыйныф дип йөртелде) бүленгән, аларның саны 3 яки 4 булган булыр, күңелдә ачык калмаган.*

*Мәктәпнең эчке күренешендә дә татар мәдрәсәләренә хас булмаган үзгәрешләр бар иде – мәктәпнең уртасында ике яклы кара такта бастырып куелган, укучылар 6–7 кеше сыярлык озынлыкта ясалган тәбәнәк парталар артында утырып укыйлар, язалар. Парталар тәбәнәк булу сәбәпле, балаларга тезләнеп утырырга туры килә, шуңа күрә, парталар артына идәнгә киез һәм аның өстенә киндер җәелгән иде.*

*Мәктәптә сабаклар көненә ике тапкыр – иртә 8 дән 12 гә һәм көндез 3 дән 5 кә кадәр була, тик пәнҗешәмбе көннәрдә кичке сабак булмый иде. Пәнҗешәмбе көне, гомумән, башка көннәрдән аерылып торды. Бу көнне балалар укытучыга сәдака китерә һәм аны, сабак башланганчы кара такта янына куелган табуреткага утырган укытучының алдына барып тезләнеп тапшыралар иде. 70–80 баладан аена дүрт тапкыр шулай җыйналган тиеннәр, Нури-Әхмәт укытучының көненә 7–8 сәгатькә тигез булган хезмәте өчен төп хезмәт хакы булып торды. Бу процедура беткәч, бу көнне чиста итеп китаптан күчереп язу дәресе була торган иде. Монда инде язуның матурлыгына, дөреслегенә игътибар ителә иде. Шуңа күрә, моны без грамматика һәм каллиграфия дәресләре дип әйтсәк тә хата булмас. Балалар инде чиста дәфтәрләр алып килгәннәр, укытучы аларга каурый каләмнәр очлап бирә, шуннан соң инде тырышып-тырышып язу башлана иде. Язу бетү белән дәфтәрләр җыелып алынып, укытучы тарафыннан шунда ук тикшерелеп, билге куела иде. Нури-Әхмәт мөгаллим дәфтәрләрне кызыл кара белән төзәтте һәм үзенең имзасын «Н. Мөгаллим» дип куя иде. Начар язган өчен «начар» билгесе, югарырак булса – «яхшы», «бик яхшы», «тәхсин», «афәрин» һәм башка билгеләр кулланып килде.*

*Мәктәптә уку елы сентябрьдә башланып, майга кадәр сузыла иде. Н. Һидиатуллинның мәктәпне бетерүче балаларга сынау (ул заманда имтихан дип йөртелә иде) уздыруы хакында да әйтергә тиешле. Монда ачык сынаулар ул вакытта Уральск мәдрәсәсендә юк иде. Бу сынаулар һәркем өчен ачык булды. Сынауга Нури-Әхмәт мөгаллимнең чакыруы буенча булса кирәк, бер кадәр мулла-мәзиннәр, мәдрәсәгә материаль ярдәм итүче сәүдәгәрләр һәм балаларның аталары киләләр иде. Ике-өч көнгә сузылган бу сынаулардан соң һәр укучыга, путаллап басылган кәгазьгә язылган һәм сынауда булган мулла-мөәзиннәр имзасы куелган шәһадәтнамә бирелә иде.*

*Бер елны, 1909 ел булырга кирәк, сынаулар беткәч, язгы ташу вакытында киң җәелгән Чаган елгасы аркылы көймәләр белән су артындагы урманга ялга Нури-Әхмәт мөгаллимнең безне алып чыкканы һәм анда балаларның төрле уеннар уйнаганы хәтердә калган. Н. Һидиатуллинда укып чыккан балаларның күбесе, аның киңәше буенча, татарлар өчен ачылган башлангыч русча мәктәпкә кереп укыдылар. Бу мәктәпнең рәсми исеме «Русский класс при медресе г. Уральска» булып, хөкүмәт бюджетында иде. Монда озак вакыт Казан татар учительская школасын бетергән Әхмәтша Сираҗетдинов (ха-*

*лык арасында «учитель Ахметша» дип йөртелде) дигән кеше укытып килде. Аннан башка, Нури-Әхмәт мөгаллимнең берничә татар яшүсмерләренең, әле шул заманда инде, рус урта мәктәпләренә кереп укуларына сәбәпче булу фактлары да бар. Бу кешеләрнең кайберсе әле дә исән.*

*Н. Һидиатуллинның эше турында сүз барганда, аның нинди дәвердә укытучылык итүен күз алдына китерергә кирәк. Бу вакытлар, бер яктан, 1905 ел революциясеннән соң иҗтимагый тормыш күтәрелеше заманы, хосусан Уральск шәһәрен алганда, Камил Мотыйгый, Габдулла Тукайларның «шәһәр тарихында беренче буларак, сатирик, иҗтимагый «Уклар», «әл-Гаср әл-Җәдид» журналлары чыгарган еллары булса, икенче яктан, каты реакция еллары да иде. Бу дәвердә реакцион муллалар һәм сәүдәгәрләрнең төрлечә кысрыклау, янауларына карамастан, борыннан килгән кануннарны бозып, иске мәктәп тормышына, ул заманда объектив шартлар буенча мөмкин булган кадәр яңа эчтәлек кертү өчен зур батырлык кирәк булган булыр. Бу эштә, әлбәттә, Н. Һидиатуллин ялгыз булмаган, аның мәсләктәшләре, ярдәмчеләре булгандыр. Беренче буларак, шәһәрнең прогрессив кешеләреннән булган М. Төхфәтуллинның мәгънәви ярдәме булмый калмагандыр. Нури-Әхмәт укытучының, Уральскига килгәч тә, бүтән мәдрәсәләргә бармый, баштан ук агач мәдрәсәгә урнашуы очраклы хәл булмаска тиеш.*

*Балаларны парталар артына утыртып укыту, кара тактага яздыру, мәктәпкә география, арифметика шикелле «дөнья» фәннәре дәресләре кертү, татар теле грамматикасы элементларын төшендерү, географик карталар куллану, я булмаса балаларны шигырьләр җырларга өйрәтү («Безнең аталар йоклап яталар» дип башланган бер шигырьне өйрәнү һәм җырлау хәтердә калган), ачык сынаулар уздыру һәм башкалар – болар барысы да Н. Һидиатуллин керткән прогрессив эшләр булып калды.*

*Аның укучылары «Әткә-әнкәләребезнең» телен өйрәткән иң беренче укытучы – Н. Һидиатуллинның фидакяр эше халык арасында онытылмый саклана. Нури мөгаллимнең шәкерте, персональ пенсионер, 1898 елда туган Н. Валеев, Казань, 29, Заря, 26 кв. 7. Нигъмәт Вәлиев».*

Истәлекләреннән күренгәнчә, Н. Вәлиев «Мотыйгия» мәдрәсәсендә Тукайдан соң (Г. Тукай инде 1907 елда Казанга китә) укыган. Бу фоторәсем аңа мәдрәсәдә Габдулла Тукай белән бер үк вакытта укыган берәр дусты аркылы эләккән я Нуриәхмәт хәлфәдән алынган булырга мөмкин. Истәлек язмасы шакмаклы блокнотның (20×14 см) 11 битенә берәр яклап зәңгәр шарлы каләм белән язылган, музейның экспонатларын теркәп бара торган кенәгәгә кульязма – 19689-1, фотосы 19698-101 номерлары белән теркәлгән.

Бу җылы истәлекне язып калдырган Нигъмәт Сафа улы Вәлиев Җаек шәһәрендә туган. 1916 елны ул Казанга укырга килә, 1928 елда Казан университетының медицина факультетын тәмамлый. Бөек

Ватан сугышы башлануга (өченче көнне үк) мобилизацияләнә, хәрби госпитальләрдә яралылар дәвалый. Россия Федерациясенең атказанган табибы, Казан шәһәр советы депутаты.

Сугыш вакытында Сәламәтлек саклау Халык комиссариаты Мәскәүдән Казанга күчә. Эвакогоспитальдә ассистент, II рангтагы хәрби табиб Нигъмәт Вәлиевне Казанга хәрби госпитальләр оештыру эшенә алалар. Ул Казанда бер-бер артлы дүрт эвакогоспиталь ача. Лаеклы ялга киткәнче, соңгы ачылган госпитальдә баш табиб булып кала.

Нигъмәт Сафа улы Вәлиев – күренекле табиб буларак үзе дә тарихта билгеле шәхес. Аның бу истәлекне татар мәгърифәте тарихында күренекле үз урыны булган «Мотыйгия» мәдрәсәсе, анда белем биргән хәлфә-остазлары, укытучылары турында әманәтне документаль рәвештә саклап, мирас йортына тапшыра алуын киләсе буыннар да югары бәяләр.

## Чыганакларлар


Кулъязма. Нигъмәт Вәлиев. Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсе турында истәлек. НМ РТ. 19698-1

Фоторәсем. Г. Тукай бер төркем шәкертләр арасында. НМ РТ. 19698-101.


## Әдәбият


*Ахметова Д.* Габдулла Тукай в фотографиях. Казань. Издательство АН РТ. 47 стр. Фото на 6 с.

*Лебедев А.* Интервью с главным хирургом Татарстана Михаилом Розенгартеном // Республика Татарстан. 14 октября. 2005. Онлайн. Все записи. Общество.

Тукайга сәяхәт. 2016 елның 24 октябре – 2017 елның 22 гыйнварында «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының «Манеж» күргәзмә залында оештырылган күргәзмәнең каталогы. Казан: Заман, 2016. 47 б. Фоторәсем б. 24.



***Абзалина Рәмзия Әсрареддин кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 908

***А.Н. Хәсәнова***

# ФАТЫЙМАИ-ФӘРИДӘ ВАҺАПОВА-НӘҮРУЗОВАНЫҢ «СИБИРИЯ» ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛГАН МӘКАЛӘЛӘРЕННӘН

Статья приурочена к 135-летию со дня рождения Фатимы-Фариды Вагаповой-Наурузовой и служит цели увековечения памяти о просветительнице, одной из первых татарских журналисток из числа женщин. Автором освещается ее биография, а также затрагиваются основные темы и вопросы, поднятые Фатимой-Фаридой Вагаповой-Наурузовой на страницах газеты «Сибирия» (издавалась в городе Томск с 18 февраля 1912 г. по 31 августа 1913 г. 3–4 раза в неделю на татарском языке). В газете она вела раздел «Мир женщин», где рассматривала такие актуальные вопросы, как положение женщин в семье и обществе, борьба женщин за образование, повышение качества обучения в женских школах, о важности изучения русского языка, и о необходимости обучения татарок в русских учебных заведениях, о воспитании детей и т.д.

**Ключевые слова:** Фатима-Фарида Вагапова-Наурузова, газета «Сибирия», просветительство, женский вопрос, обучение женщин, школы.

The article is dedicated to the 135th anniversary of Fatima-Farida Vagapova-Nauruzova’s birth and serves the purpose of perpetuating the memory of the educator, one of the first Tatar female journalists. The author covers her biography and also touches upon the main topics and issues raised by Fatima-Farida Vagapova-Nauruzova on the pages of the newspaper “Sibiriya”. In the newspaper she led the section “World of Women” where she considered such topical issues as the position of women in the family and society, the struggle of women for education, improving the quality of education in girls’ schools, the importance of studying the Russian language and the need to educate Tatar women in Russian educational institutions, raising children, etc.

**Keywords:** Fatima-Farida Vagapova-Nauruzova, newspaper “Sibiriya”, education, women’s issue, education of women, schools.

*XIX гасыр азагы – XX йөз башы татар милли мәгарифен үстерүгә көч куйган, хатын-кызларның бәйсезлеге өчен көрәшкән милләт хадимәләре арасында Фатыймаи-Фәридә Нәүрузова исеме аерым бер урын алып тора.*

*Фатыймаи-Фәридә Нәүрузова 1889 елның 25 февралендә Чистай шәһәрендә сәүдәгәр Мортаза Ваһапов гаиләсендә бердәнбер бала булып дөньяга килә. Бала чагыннан ук аң-белемгә омтылган кыз башлангыч белемне абыстайдан ала. Әтисе Мортаза, сәүдә эшләре белән Россиянең төрле почмакларында булган, Төркиягә барып, андагы тормышны үз күзе белән күргән кеше буларак, кызына дөньяви белем бирү юлларын эзли. Чистайда кызларга заманча белем бирә торган татар мәктәпләре әле булмау сәбәпле, гаилә 1892–1894 елларда*

*Төркиядә яши. Истанбулда Фатыймаи-Фәридә кызлар өчен ачылган төрек башлангыч мәктәбенә укырга йөри. Туган якларына кире әйләнеп кайткач та, кызына тирәнтен белем бирү теләге белән, әтисе Фатыймаи-Фәридәне 1895 елда Казанга укырга илтә. Ләкин ара ераклыгы, сагыну хисе аны кызын кире барып алырга мәҗбүр итә. Бу вакытта күршеләрендәге мәшһүр ишан Мөхәммәдзакир Камаловның улы Ибраһим үз сеңелләренә дәрес бирә башлый, Фатыймаи-Фәридә дә аларга кушыла. Истанбул, Каһирәдә белем алган алдынгы карашлы Ибраһим Камалов, 1901 елга кадәр, Мәккәи-Мәдинәгә укырга киткәнче, кызларга белем бирә. Аннан соң Фатыймаи-Фәридә Нәүрузова Казанда Галимҗан Баруди хатыны Маһруй абыстайның җәдит мәктәбендә бер ел укый. 1904 елда исә янәдән укуын Мәдинәдән кайткан Ибраһим әфәнде Камаловта дәвам итә – география, табигать белеме, арифметика, тарих фәннәрен өйрәнә. Төрек, гарәп, фарсы телләрен өйрәнү белән бергә, рус теле укытучысыннан дәресләр ала, әдәбият белән кызыксына. Мөгаллиме Ибраһим Камаловның бай китапханәсеннән файдалану, XX йөз башы алдынгы фикер ияләренең иҗатлары белән танышу, һичшиксез, Фатыймаи-Фәридәнең алдагы эшчәнлегенә зур этәргеч була. Нәкъ менә шушы вакыттан ул үзенең тормышын уку-укыту, татар хатын-кызларын аң-белемле итү, аларның хокуклары өчен көрәш юлына багышлый. Әлеге максатларга ирешүдә татар кызлары өчен махсус мәктәпләр ачу зарурлыгын, аларга алга таба үсү, һөнәр алу мөмкинлеген тудыруны тормышка ашыру аның яшәешенең төп мәгънәсенә әйләнә. Әле Чистайда яшәгәндә үк, 16 яшьлек Фатыймаи-Фәридә 1903–1904 елларда, үз йортларында башлангыч җәдит мәктәбе оештырып, кызларга дәресләр бирә башлый. Аның беренче шәкертләре арасында танылган шагыйрә Сания Гыйффәт, мөгаллимәләр Рабигаи-Надирә Садыйкова, Мәрхәбә Батыршина һәм яшьлек дусты Зәйтүнә Юльметова да бар.*

*1907 елда Ваһаповлар гаиләсе хәзерге Ютазы районы Кәрәкәшле авылына күченә. Бу авылда да, беренче эш итеп, Фатыймаи-Фәридә кызлар өчен мәктәп ачу эше белән йөри башлый. Үз акчасына мәктәп бинасын арендага алып, аны кирәкле әсбаплар белән баета, «Йолдыз» китапханәсе нәшер иткән дәреслекләрне яздырып алып, шул ук елның 17 сентябрендә 5 –6 кызны кабул итә һәм укыту эшенә керешә. Көндәлекләреннән күренгәнчә («Тормыш» газетасы, 1914 ел, 7, 9, 12, 16 март), инде февраль айларына укучыларының саны 15 кә җитә, ә ел ахырына 70 кә якынлаша. Кичләрен олырак яшьтәге ханымнарны, абыстайларны җыеп, аларны төрле китаплар белән таныштыра, укырга-язарга өйрәтә. Тора-бара инде бирегә күрше авыллардан да килеп укый башлыйлар.*

*Кәрәкәшледә бер ел торып, 1908 елда Фатыймаи-Фәридә Томскидан килгән Мөхәммәтвәгыйзь Нәүрузов исемле мөгаллимгә кияүгә чыга. Томскида да Фатыймаи-Фәридә мөгаллимлек эшен дәвам итә. Башта мәхәллә мәктәбендә эшләп ала, соңыннан 1909 елда башлангыч мәктәп мөгаллимәсе таныклыгына имтихан тотып,*

*шәһәр идарәсенең рәсми рөхсәте белән, җәдит кызлар мәктәбе ачуга ирешә. Бу мәктәп Томскида рәсми рәвештә ачылган беренче татар мәктәбе була.*

*Шушы чорда ул шәһәрнең иҗтимагый тормышында да актив катнаша башлый, тарих, балалар тәрбиясе, гаилә мәсьәләләре, хәйриячелек белән шөгыльләнгән күптөрле җәмгыятьләрнең әгъзасы булып тора.*

*Белемен күтәрү нияте белән Фатыймаи-Фәридә Нәүрузова рус кызлар гимназиясендә укый, университетка керергә әзерләнә. Шәһәрнең татар мохитендә генә кайнашмыйча, рус хатын-кызлары белән дә аралаша. Аларның тормышы, яшәү рәвеше белән танышып, татар хатын-кызларын да үз хокукларын яклый алырлык, үз бәхете өчен көрәшүчеләр булуларын күрергә тели, үз фикерләрен газета-журналларга язган мәкаләләрендә чагылдыра. Аның беренче каләм тибрәтүе 15–16 яшьләрендә үк башлана: «Әлгасрелҗәдид» журналында мәкаләләре дөнья күрә. Томскида аның публицистик эшчәнлеге киң колач ала. 1912 елның февраленнән алар, ире белән берлектә, сәяси, икътисади, әдәби, милли «Сибирия» газетасын чыгара башлыйлар. Әлеге газета битләрендә эчке һәм тышкы сәясәткә, икътисад һәм сәүдәгә, урта һәм югары белемгә, татар мәдәниятенә багышланган мәкаләләр басыла. Фатыймаи-Фәридә, газетаның беренче саныннан ук, «Хатын-кызлар дөньясы» исемле сәхифә оештырып җибәрә. Биредә татар хатын-кызларының хокуклары турында сөйләнелә, аянычлы хәлләре тасвирлана, аларны иҗтимагый тормышка тарту, кыз балалар мәктәпләрендә укытуның сыйфатын күтәрү, укучыларны тормышка яраклы итеп хәзерләү, һөнәрле булу, рус теле өйрәнүнең әһәмияте, рус мәктәпләрендә, гимназия һәм югары уку йортларында укуның хатын-кызлар өчен кирәклеге һ. б. мөһим мәсьәләләр яктыртыла. Бүлек материаллары, гадәттә, беренче яки икенче биттә басыла. Башта бу сәхифәнең бердәнбер авторы Фатыймаи-Фәридә ханым гына булса, соңрак редакциягә илнең төрле почмакларыннан хатлар, язмалар килә башлый, кайберләре газетада басылып та чыга. Мәсәлән, шул чорның мәшһүр хатын-кызлары – Маһруй Мозаффария, Фәхрелбанат Сөләймания, Багбостан Мөэминова кебек танылган мөгаллимәләрнең язмалары газета битләрендә дөнья күрә. Хатын-кыз проблемаларын яктырткан мәкаләләр башка бүлекләрдә дә урын ала бара. Шул рәвешле үзенең бөтен гомерен хатын-кыз мәсьәләсенә багышлаган Фатыймаи-Фәридә ханым «Сибирия» газетасын хәбәрдарлык, кыю фикер өчен мәйдан итә.*

*1913 елда Фатыймаи-Фәридә, салкын тидереп, туберкулёз белән авырый башлый. Башта Уфага, соңыннан әти-әнисе янына Кәрәкәшлегә кайта. Авыр булса да, эшен дәвам итәргә тырыша, 1913 елның 18 октябреннән Уфада «Сибирия»нең дәвамы буларак чыга башлаган «Тормыш» газетасына мәкаләләрен даими рәвештә җибәреп тора. Кызганычка каршы, зур планнар белән яшәгән Фатыймаи-Фәридә 1914 елның 16 февралендә 25 яшендә вафат була.*

*Фатыймаи-Фәридәнең соңгы үтенечен истә тотып, Ютазы районының Кәрәкәшле авылында 1915 елның 11 ноябрендә кызлар мәктәбенә нигез салына.*

*1917 елда уздырылган Бөтенроссия мөслимәләренең беренче съезды вакытында җыелган вәкилләр хөррият өчен көрәштә корбан булган каһарманнарны, мәшһүр татар кызларын – Зөһрә Акчурина-Гаспринская һәм Фатыймаи-Фәридә Нәүрузованы аягүрә басып искә алалар. Шушы съездда аларны «милләт аналары» дип атыйлар. Чыннан да, милләтнең киләчәген нәкъ менә хатын-кызларның мәгърифәтле булуында, алга таба үз халкына хезмәт итәрдәй балалар тәрбияли алуларында күргән Фатыймаи-Фәридә ханым да, татар халкы тарихында якты эз калдырган милләт хадимәсе, милләт анасы булып яши бирә.*

*Фәнни даирә игътибарына Фатыймаи-Фәридә Нәүрузованың «Сибирия» газетасының «Хатын-кызлар дөньясы» сәхифәсендә дөнья күргән дүрт мәкаләсе тәкъдим ителә.*

Безнең мөселман хатын-кызының тормышы, мәдәни халык карашында бик начар, бик авыр төсле булса да, үзләре, ягъни мөселман хатын-кызлары, үз тормышларыннан бик разыйлар, алар бер дә үзләренең тормышларының үзгәрүене теләмиләр. Һәм хакыйкатьтә һәркемнең тормышка карашы үзенчә булганга, алар карашында да тормыш шундый артык булырга ярамыйдыр. Бала кечкенә вакытында ук тормыш бары Алланың тәкъдире илә генә була диеп әйткән кешеләр арасында үскәнгә, бу игътикад[1] аның да канына сеңә. Үсеп җиткәч, ата-анасына бер сүз дә әйтми, алар биргән җиргә бара. Баргач та, ире илә мөмкин кадәр яхшы торырга, аның күңелен табарга тырыша. Әхлак ягыннан безнең мөселман хатын-кызын бик мактарга да ярыйдыр. Ул һәрвакыт иренең ризалыгын алу ниятендә булганга, аның һәрбер хезмәтне авырсынмый эшли, өйне җыя, ашны пешерә, киемне тегә, балаларны карый, ире исереп, эштән чыгып кайтканда да, ул бер сүз әйтми, авырсынмый, шул ирне тәрбияли, аның кайгысын күрсә, чын күңеле илә кайгыра, хаста булса, төн йокламый янында уздыра. Ире никадәр үзен җәбер итсә дә, күп вакытта яшерергә тырышадыр.

Әлхасыйль,[2] кулыннан килгән һәр эшне һич аямый эшлидер. Әлбәттә, баштан тәрбия күреп, идарәи бәйтия[3], бала тәрбиясе кеби эшләр хакында мәгълүматы булмаганга, үзенең эшендә кимчелек итсә дә итәдер. Ләкин ул кимчелекләр белеп эшләнмәгәнгә, ачуланудан бигрәк, гафу ителергә тиешдер.

Безнең Русиядәге ислам хатыннарының тормышы башка җирдәге мөселман хатын-кызларыннан күп аерымдыр.

[1] Игътикад – ышану.
[2] Әлхасыйль – кыскасы.
[3] Идарәи бәйтия – өй эшләре.

Безнең татар хатынының тормышта иренә тәэсире, сүзне кабул иттерүе төрле вакытта төрлечә буладыр. Кайвакытта кечкенә генә бер капризы илә иренең башын әйләндергән, үзенең теләгәнне эшләтә алган бер хатын, икенче вакытта бер бик мөһим нәрсә хакында да, иренә авыз ачып бер сүз дә әйтә алмыйдыр. Вә һәрнәрсәне иренең күзлеге аркылы караганга, ул үзенең фикерне эшләтәсе килми, ире ни итсә, шул эшне бик дөрес диеп ышанадыр. Вә аны шул фикереннән һичкем кайтара алмыйдыр.

«Авыл хатыннары мөстәсна[1] булганда», татар хатыны тормыштагы авырлыгы да күтәрмидер. Башка милләт хатын-кызлары ирләренә төрле яктан ярдәм иткәндә, безнекеләр ирләре китергәнне ашап кына яталар. Шуның өчен эштә бер дә катышлары булмаганга, ирләр хатыннарны бик түбән санап, һәрвакытта аларны кимсетә вә шактый гакыл иясе, яңаруны ярата торган ирләр дә «хатыннарның сачләре озын, гакыллары кыска» мәкалене тугры килгән саен әйтеп кенә торалар. Вә һәр тугрыда үзләрене камил хуҗа диеп белеп, хатыннарына теләгәнчә каты мөгамәләдә булалар. Вә бер эшләре турысында да хатыннарының фикеренә карамыйлар. Үзләре теләгәнчә кәефләрене кылалар. Малны табучы үзебез генә бит диеп, хатыннарының көн буе бер почмакны саклауларны искә дә алмыйлар. Хатыннар үзләре дә баштан яхшы тәрбия күрмәгәнгә, бала тәрбиясе, идарәи бәйтия кеби эшләрдә мәгълүматлары булмаганга, ихтыярсыз, ирләренең дудкаларына биергә мәҗбүр булалар. Бу җәһәт лә бичара татар хатын-кызларының тормышы коллар тормышына охшыйдыр. Бу күңелсез тормыштан кортылмак өчен гыйлем кирәкдер. Гыйлем һәр иләмсез нәрсәне матурландырадыр. Гыйлем инсанны дөньяда, ахирәттә сәгадәткә[2] өндидер.

*Фатыймаи-Фәридә*
*Сибирия. 1912. 25 февраль. № 2*

Заман алмашынып торганга, тормышның һәртөрле үзгәрешенә каршы тора алмаган инсан изелә вә югаладыр. Татар хатыннарының бернәрсәгә дә көчләре җитмәве, үзләренең фикерләрен ирләренә кабул иттерә алмауларының зарары бала тәрбиясендә бик ачык күренәдер. Бигрәк моннан зарар күрүчеләр – кызлардыр. Бичара кыз баланы озак вакытлар укытып, аның укыганы өчен күп акча түләргә авырсыналар. Кызлары унбер, унике яшькә җитү илә: «Аллага шөкер, кызым кул арасына кирәрлек булды. Эшкә бөгә башларга вакыт» диеп, кызларыннан өй хезмәтләрен иттерә башлыйлар. Бер яктан караганда, аналарының бу эшләре кызларын яшьтән үк өй эшләренә өйрәтер өчен булганга, мактарга яраса да, күп вакытта аналар үзләре өй эшен яхшы белмәгәнгә, кызларын да аена өч сум жалование ала торган хезмәтче җирендә йөртәләр. Вә бичараны гомер буена шул өчдүрт сумлык хезмәтче ясап калдыралар.

[1] Мөстәсна – чыгарма.
[2] Сәгадәткә – бәхеткә.

Бер кыз укый-яза белсә, «үзенә кирәкне белде инде» диеп, чәчәк кеби мәгъсум баланы вакытсыз укуыннан туктаталар. Ул кыз гомер буена шул сузып-сузып укудан, ярым-йорты язудан башкасын белмидер. Тарих, җәгъръфия, хисаб, тарих, табигый кеби дөньяда тора торган кешегә иң кирәк булган гыйлемләрне бар диеп тә белмиләр.

Бу көнгә кадәр безнең тормышыбыз һаман бер юл илә барганга, безнең аналарыбыз да башка милләт хатын-кызлары кеби, тормыштагы авырлыкның берсен дә күтәрми, тыныч кына, үз өйләрендә ирләре китергәнне ашап кына ятсалар да, ул вакытта бик бәхетле булып, бер кайгы да күрмәсәләр дә, бу тормышның актыгы бик куркынычлыдыр. Чөнки ирләрнең кәсепләре начарлана, ирләр һәрвакыт файда юклыктан, расход күплектән зарлана башлаганга, татар хатыннарына да үзләренең бу көндәге рольләрне алмаштырырга тугры киләчәктер. Кыскасы гына: татар хатыны бик саф, иренә итагатьле, чын күңеле илә иренә ярарга тырышып хезмәт итүче булса да, иренә ярдәмче, кайгылы вә авыр сәгатьләрендә юатучысы була алмыйдыр.

Тормышнын сәбәпләреннән хәбәре вә үз өенең тышындагы эшләрдән мәгълүматы булмаганга, Алла сакласын, ире үлсә яисә хаста булса, яшь балалары илә мохтаҗ булып каладыр.

Гомерне кара хезмәт илә үткәрергә, тамагыны да мең бәла илә туйдырырга мәҗбүр буладыр. Киләчәктә шундый бәхетсезлекләр язмасын өчен, бу көннән кызларыбызны чынлап тәрбия итәргә, аларны тормыш илә таныштырырга, киләчәктә милләт анасы, чын мөселман хатыны булырлык бер дәрәҗәгә китерергә тиештер.

Бу көннән үк шул тәрбияне бирү дин, дөнья җәһәтеннән фарыздыр. Тәрбияле аналарның сөекле балалары да тәрбияле, бәхетле булырлар. Шуның өчен дә «бәхет малда түгел, бәлки гыйлемдә, тәрбиядә»дер дигәннәр.

*Фатыймаи-Фәридә*
*Сибирия. 1912. 3 март. № 3*

Хатын-кызга бер дә права бирмәенчә, өйдә генә ябып яткырганда да, алар бик күп нәрсәне белергә мәҗбүрдерләр. Өйнең бөтен тәрбиясе: ашарга-эчәргә хәзерләү; кисү, тегү кеби эшләр хатыннарның иң беренче вазифалары булганга, шул һөнәрләр хакында махсус кагыйдәләрне белмәгән бер хатын ана исемене алырга, йортыны идарә кылырга лаек түгелдер. Безнең аналарымыз кызларны үз яннарында булыштырып, яшьтән үк югарыда сөйләнгән эшләрне гамәли рәвештә өйрәтсәләр дә, бу көнге хәлләренең үзгәрүе сәбәпле, аналарымыз өйрәткән эшләр илә генә кәнагатьләнерлек түгелдер.

Әүвәлдә майның кадагы 15, ит 5, он поты бер сум улган вакытта пешергән ашларны хәзер ул вакыттагы форма илә пешереп булмый. Иң беренче, кирәкле нәрсәләрнең бәһасе үзгәрү илә ашларымыз да үзгәрәдер. Әбиләребез, аналарыбызның өйрәткән юлы илә генә пешергәндә без бу көндә күп мәсарыфка[1] дучар булырга тиештер.

[1] Мәсарыфка – чыгымга.

Шуның кеби, тегү эшендә дә, әүвәлге күлмәкләребез артык сырлы булганга, аналарыбыз өйрәткәнчә тегеп кенә аладыр идек. Хәзер ул күлмәкләр ташланып, Яурупа модасы илә киенә башладык.

Хәлбуки, Яурупа модасы илә күлмәк тегәр өчен үзенә махсус тегү гыйлемене өйрәнергә кирәк, юкса, үзебез тегәбез диеп, белер-белмәс яурупача тегеп маташсак, материал әрәм итүдән башка эшкә ярамаячактыр. Шуның өчен, ихтыярсыз, киемнәребезне марҗага биреп, болай да тар булган икътисади хәлебезне тагы да тарайтырга мәҗбүр булабыз. Алай итмәс идек, безнең дә кеше төсле киенәсебез килә, үзебез тегә белмибез. Татардан тегүче юк.

Безнең аз-маз ачылган кызлар мәктәпләрендә кул һөнәре дия бәйләү, чигү кеби һөнәрләр өйрәтелсә дә, бу да әсаслы[1] түгелдер. Кисү, тегү кеби эшләребез дә өйрәтелмәгәнгә, мәктәпләребез бу ихтыяҗыбызны тутыра алмыйлар (Казанда Фатыйха ханым Аитова идарәсендәге мәктәптә кисү, тегү һөнәрләре өйрәтелсә дә, мондыйлар бик аздыр).

Хатын-кызны сәфаләттән[2] коткару өчен аларны һөнәргә өйрәтү бик тиештер. Ләкин без хәзер никадәр тырышсак та, үзебез мондый һөнәр мәктәпләрене максатыбызга муафикъ[3] итеп, тиз ача алалырбыз диеп уйлый алмыйм. Җәмгыятьләребез булса, ир балалары өчен дә әллә никадәр газапланганнан соң гына берәр мастерской ача алалар. Шуның өчен үзебез ачканчы яисә ачканны көтеп ятканчы, ватандашларыбыз руслар тарафыннан ачылган шундый мәктәпләргә кереп, үзебезнең белемебезне арттыру, икътисади хәлебезне яхшырту чарасына керешү бик тиештер. Мондый һөнәр мәктәпләре күп шәһәрләрдә була.

Безнең Томскида 1905 елда шәһәр идарәсе тарафыннан Себердә беренче мәртәбә мөкәммәл[4] һөнәр мәктәбе ачылмыштыр. Бу мәктәпкә бер класслы мәктәптә имтихан биргән, русча шәһадәтнамәсе булган кызларны кабул итәләр. Уку мөддәте[5] өч ел булып, кисү, тегү, бәйләү, чигү, рәсем кеби кул һөнәрләреннән башка, гомуми фәннәрдән рус теле, хисап, кәсер гади[6], кәсер әгъшари[7], физика, тарих, җәгърафия, счетоводство кеби мөһим булганнарны укыталар. Дин, милләт аермасына карамый, һәрбер 11 яшьтән ким булмаган бала кабул ителәдер. Хакы бары айга бер сум улып, рәсем өчен янә өч сум алынадыр.

Ибтидаи мәктәп бетерүенә шәһадәтнамәсе булмаса яисә бары һөнәр генә өйрәнергә теләсә, дүртенче курска курсистка исеме илә кабул ителеп, бер елда мөкәммәл рәвештә кисү, тегү һөнәрләре өйрәтеләдер. Боның хакы елга утыз сум. Унбиш сумны мәктәпкә кергәндә бирергә кирәк. Метрический сведениядән башка документ кирәкмидер.

---

[1] Әсаслы – нигезле.

[2] Сәфаләттән – түбәнлектән.

[3] Муафикъ – яраклы, туры килгән.

[4] Мөкәммәл – камил.

[5] Мөддәте – срогы.

[6] Кәсер гади – гади вакланма.

[7] Кәсер әгъшари – унарлы вакланма.

Бу мәктәп махсус фәкыйрь халыкка ярдәм булсын, алар тиешле һөнәрне өйрәнеп, башкаларга мохтаҗлыктан котылсыннар өчен тәэсис ителгәнгә[1], безнең мөселман кызларына бу мәктәптән файдалану бик тиешдер.

Безнең йорт анасы булырга теләгән кызларыбызга шул югарыда яздыкым һөнәрләрне өйрәнми һич мөмкин булмаганны, ихтыяҗ вакытында идән юучы, караучы булганчы, үзенең инәсе илә көн күрсә, тагын да яхшы булачактыр. «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми» – бабаларыбызның сүзедер.

*Фатыймаи-Фәридә*
*Сибирия. 1912. 19 август. № 26*

## Химаясезләр[2]

Тормышка өстән генә караганда һәркемнең шәхси низам[3] илә тәэмин ителгән кебек күренә. Фәкать тормышның эченәрәк кереп карасак, мәмләкәтнең нинди низамлы булуына карамыйча, әллә нинди хаксызлыклар, инсаннарның бер-берсе өстеннән җәбер вә золымнар итдекләрене күреп, гакылдан язар хәлгә киләсең. Әгәр тормышның эчене актара башласак, ирексез, инсаннар арасында тору урмандагы бүреләр арасында тору кебек, дип уйлыйсың. Әгәр син дә тешләреңне шыкырдатып, бугазыңнан буам дия каршы торсаң, синең илә һәркем яхшы. Инде аз гына йомшак булдыңмы, яки үз-үзеңне химаядән гаҗиз булырлык зәгыйфь булдыңмы, анда инде эш бетте. Сине бер кем дә кызганмый да, бу бит химаясез дими, хәленнән күпме килсә, шулай синнән файдаланып, синең бөтен вөҗүдең[4], хәятың вә истикъбалеңне[5] үзенең пычрак хәятенә корбан итәргә генә карый. Инсан хайваннарның тире вә итләре илә үзенең вөҗүдне ничек сакласа, үз туганы инсан берлә дә шулай ук үз вөҗүден вә хәятен файдаландырырга тырыша. Затән,[6] инсаннарның иң күп кыйсме[7] дә азрак бер сыйныфның рәхәте өчен дөньяда тора, җәфа күрә, кыенлык, төрле золым вә җәберләр күрәдер.

Мин монда, әлбәттә, аларның һәммәсе тугрысында язмыйча, бары аларның иң кызганыч хәлдә булганнары хакында гына бер-ике сүз әйтеп китмәкче булам. Ул кызганыч химаясезләр дә, табигый, без татарлар арасындагы асраулар. Бу бичаралар, хосусан, боларның яшьрәкләре, дөньяда иң химаясез мәзлумәләр дияргә лаеклыдырлар. Боларны беркем телгә алып кызганып сөйләми, болар хакында беркем язмый, боларны белгән, ишеткән бер кеше юк. Әмма бу мәзлумәләрнең хәлләренә якынрак килеп карасаң, исең китә. Егерменче

---

[1] Тәэсис ителгәнгә – төзелгәнгә.
[2] Химаясез – яклаучысыз.
[3] Низам – тәртип, кагыйдә.
[4] Вөҗүдең – барлыгың.
[5] Истикъбалеңне – киләчәгеңне.
[6] Затән – нигездә.
[7] Кыйсме – өлеше.

гасырда мәдәни бер мәмләкәттә андый инсаниятсезлекләр, андый җәбер вә золымнар булуына ышанасың килми, фәкать тормышта шундый хакыйкатьләргә очрыйсың, шундый куркыныч сценалар күрәсең ки, үзеңне әллә нинди коруне уля[1], коруне вөста[2] вакытларына кайтарып, коллар заманасында кебек хис итәсең.

Башка мәдәниятлерәк халыкларда бу кеби мәзлум вә мәзлумәләрнең химаясенә матбугат йитешәдер. Матбугатта һәрвакыт язалар, сөйлиләр, шуның илә яхшы ук зверь инсаннарны да бераз инсаниятчәрәк мөгамәлә итәргә мәҗбүр итәләр. Бездә исә ул да юк. Безнең матбугат андый мәзлумәләр хакында язу илә күп шөгыльләнми. Шуңарга күрә бездәгеләр бөтенләй химаясезләр.

Укучыларга минем бу сүзләремнең хаклыкны исбат юллы шушы химаясезләр хәленнән кечкенә генә картина гарыз итәмен. Ул мәзлумәләрнең хәлен яхшы ук ачык күрсәткән бу картина идарәгә килгән бер мәктүбтән истинбат ителәдер[3]. Ул бичараларның хәлен шушы алынган кадәресе дә бик ачык күрсәткәнгә, мәктүбе бөтенләй дәрҗ ителмичә[4], бик мөһим урыннарын гына аламын.

«Томскида бер чибәр генә интеллигент моннан берничә еллар мөкаддәм[5] эчке Русиядән 8–9 яшьләрендә бер кыз алып килгән иде. Үзләренең сүзләренә күрә дә һәм читтә әйтүләргә караганда да бу кыз ул әфәндегә бик якын, хәтта, бәгъзы риваятькә күрә, бертуган карендәш, имеш. Бу әфәнде ул кызны аннан Томскида укытырга диеп алып килгән. Фәкать ул бичара кыз Себергә укып, гыйлем алырга түгел, бәлки уголовный эш илә хөкем ителеп, каторгага килгән дияргә ярыйдыр. Ул бичара мәзлумәнең хәле каторжан хәленнән дә күп яман идекен аны менә шушы эшләрне эшләве бик ачык күрсәтә.

Ул һәр көн Том елгасыннан көянтә илә (җәе-кышы) 5–6 чиләк су китерә (кызның бәдәненә караганда, 7–8 яшьлек кызлар кадәр генә). Көянтә үзләрендә юк. Аны тирә-күршедән эзләп сорап ала. Кыш көнендә 25–30 градус суыкларда кич илә Том елгасына төшереп, керләр юа. Көндез төшермиләр. Кешедән оялалар. Болай да алар торган урамдагы рус җәмәгате бу кызның хәленә зар еглыйлар диярлек, бу мәзлумәне һәрвакыт кызганалар, анарга киченнән тыш эш эшләдеке өчен, һәрвакыт булышалар. Суын илтешәләр вә башка төрле ярдәмдә булыналар. Һәр көн өенең эчке катына утын ташый, аннан помой төшереп түгә. Базарга четверть шешә күтәреп төшәрәк, аннан сөт күтәреп кайта. Ул гына аз, анда әле абзасының кибеттән ләкәтә сатып йөргәнен бер почмакта туңып-катып көтеп торадыр. Әллә нигә бер мунчага бара, шунда да кич сәгать 9 да бер үзе барып, аннан кайткач, капка төбендә туңып, еглап, сәгатьләп, капка ачылганны көтеп торадыр. Әгәр кем булса, кызганып (марҗалардан кызганучылар күп

---

[1] Коруне уля – борынгы гасырлар.

[2] Коруне вөста – урта гасырлар.

[3] Истинбат – нәтиҗә чыгарыла.

[4] Дәрҗ ителмичә – теркәлмичә.

[5] Мөкаддәм – элек.

була), көянтә илә суын илтешсәләр яки башка бер эшенә булышсалар, өйгә кайткач, кызга интеллигент әфәнденең интеллигенткасы тарафыннан (нигә кешеләргә үзеңне кызганыч күрсәтәсең диеп) яхшы гына йодрык төшкәли, имеш. Шуның өчен бичара бала, еглап булса да, ярдәм иттермәскә тырышадыр.

Менә бу – бичараның өйнең тышында эшләгән эшләре. Ә өйнең эчендә эшләгән эшләрен бер Алла үзе генә белә инде. Аның көненә күпме йодрык йийгәннәрен[1]сөйләүчеләр дә бик күп. Шуның илә бәрабәр боның өсте-башы бик начар йөртелә. Бәгъзы бер рус вә мөселман ханымнары тарафыннан баланы кызганып, киемнәр бирсәләр дә, ул кызның үзенең сөйләвенә күрә, аңарга ул киемнәрне киярга бирмиләр, бәлки үз кызларына кидерәләр, имеш.

Кызның кулына каләм вә китап тотканы юк диярлек. Һәм булырга да мөмкин түгел. Ул һаман эштә. Бичара үзенең тираннары күрмәгәндә генә бик ышанычлы кешеләргә үзенең серен ача, имеш. Бер ханымның сөйләвенә күрә, кыз еглап, шушы сүзләрне сөйләгән: «Әй канатым булса! Өйгә очып кына кайтыр идем. Өйгә хат язганда мине бик яхшы укый, бик үсте инде, диеп язалар. Кая инде ул миңа укулар да, үсүләр!?» Кыз үзенең бик ышанычлы кешеләренә качып кына сөйләгән, әгәр минем зарланганымны ишетсәләр, мине орыша вә кыйныйлар, диеп әйтә, имеш».

Мәктүбнең шушы йиренә кадәр күчердем. Мәктүбтә әле тагын бик күп нәрсәләр бар, кызның күршеләрдән һәр көн күмер, су теләнүләре. Тапмый кайтса, йодрык ашаулары, тагын әллә нәрсәләре бар. Фәкать укучыларга андый бичараларның ни хәлдә булганнарын бераз күз алдына китерер өчен шул кадәресе дә йитәр диеп уйлыйм.

Менә бу зыялы бер әфәнденең үз туганына кылган мөгамәләсе, әгәр без инде зыялы булмаганнарның чит кеше балаларына кылган мөгамәләләрен алсак, картина тагын куркынычрак кына әйләнәдер. Шушындый бичаралар 8–9 яшеннән шулкадәр җәбер вә золым астыннан надан көенчә үскәч, дөньяда йодрык илә әмер итүдән башка бер нәрсә белмәгәч, ишетмәгәч, алардан нинди аналар йитешсен дә, ул аналардан нинди балалар тусын. Алардан нинди гаилә хасил булсын?! Ә бондыйлар бит күп.

Менә болар – тормышыбызның иң начар яклары булып, киләчәктәге буынга иң начар яктан тәэсир итә торган җәһәтләредер. Шуның өчен безгә бу бичараларны да бөтенләй илтифаттан чыгармыйча, боларның ярдәменә дә җитешкәләргә кирәк.

*Сибирия. 1913. 10 март. № 85*

*Текстны басмага әзерләде:*

***Хәсәнова Айгөл Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

[1] Йийгәннәрен – ашаганнарын, бу урында: кыен күргәнен.

УДК 371.214.41=512.145

*Ә.Р. Мотыйгуллина*

**ЗАМАНЧА «ӘЛИФБА»**
**(Туган тел (татар теле). Әлифба. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. – 128 б. китабына бәяләмә)**

В статье рассматривается опыт работы по разработке современного учебника «Әлифба» («Букварь») для изучающих татарский язык как родной. Рецензент обращает внимание на обобщённое изложение в книге ключевых сведений об обучении детей грамоте, о формировании у обучающихся навыков чтения и письма на родном (татарском) языке, логике изучаемого материала, использовании родного языка как средство общения, познания мира и усвоения культуры татарского народа, которые определяются как система учебно-практических задач.

**Ключевые слова**: алифба (букварь), обучение грамоте, современный учебник, навыки чтения и письма, средство общения, коммуникативная компетения.

The article examines the experience of developing a modern textbook «Alifba» for those studying Tatar as a native language. The reviewer draws attention to the generalized presentation in the book of key information about teaching children to read and write, about the formation of students' reading and writing skills in their native (Tatar) language, the logic of the material being studied, the use of the native language as a means of communication, knowledge of the world and assimilation of the culture of the Tatar people, which are defined as a system of educational and practical tasks.

**Keywords:** alifba, literacy training, modern textbook, reading and writing skills, means of communication, communicative competence.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен (татар телен туган тел буларак өйрәнүче 1 нче сыйныф укучылары өчен) «Туган тел (татар теле). Әлифба» дип исемләнгән дәреслек (Авторлары – М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов) дөнья күрде. Яңа буын әлифба урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында, Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп, Федераль белем бирү программасында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китереп эшләнгән. Әлеге дәреслек әлифбадан уку әсбабы, укытучы китабы, эш дәфтәре, әлифбаның электрон дәреслеге белән берлектә тулы уку-укыту методик

комплектын тәшкил итә. Гомумән, авторлар тарафыннан язылган 1–11 сыйныфлар өчен «Туган тел (татар теле)» дәреслекләре, тулы бер линия булып, Федераль исемлеккә кергән.

Әлифбаның эчтәлегенә килгәндә, тематик материал үзара бәйләнгән ике зур лексик темага («Мин», «Тирә-як, көнкүреш») берләштереп бирелгән: *Белем бәйрәме, танышу, мәктәп, дуслар, өй, Татарстан, Казан, Әлмәт шәһәрләре, дуслык, яраткан уеннар, туган як табигате һәм аның белән горурлану, туган илне ярату, саклау* һ. б. Тематик блок укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелгән, ягъни үзара хөрмәт һәм ышаныч атмосферасын саклау максатыннан, укучыны татар халкының әхлакый нормалары белән таныштыру, башка милләт вәкилләренең тормышы һәм мәдәнияте турында сөйләү күздә тотылган. Авторлар сөйләм калыбына нигезләп язу осталыгы булдыруны максат итеп куялар, көндәлек аралашуга бәйле сөйләм этикеты үрнәкләре белән һәрдаим таныштыралар.

Әлифбада татар алфавитындагы хәрефләр сөйләмдә кулланылыш ешлыкларына нигезләп тәкъдим ителгән: *а, л, м, ә, н, и, т, р, с, у, б, й, д, к, ү, ө, г, ы, е ([йы], [йә], [э]), ё, җ, ч, в, ң, о, х, һ, з, п, ф, ж, ш, ц, щ, ъ, ь, э* (татар-рус сүзләрендә), *ю, я*.

Мәсәлән, *Аа* хәрефенә тукталып үтик. Авторлар алдагы дәресләрдә аваз, сузык һәм тартык авазлар турында булган мәгълүматны бер калыпка салып тәкъдим итәләр. Һәр дәресне таблицага урнаштырылган татар алфавиты ярдәмендә башлыйлар һәм яңа өйрәнгән хәрефләр белән тулыландырып баралар. Беренче дәрестән алып *аваз, хәреф* төшенчәләрен аеру, [а] авазы һәм аның язудагы билгесе *а* хәрефе турында мәгълүмат бирү; [а] авазы татар сүзләренең беренче иҗегендә олаштырып, [о] авазына охшатып әйтелүенә игътибарны юнәлтү; *а* хәрефен кушып укырга, язарга өйрәтү; доктор Айболит ярдәмендә укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерүгә зур игътибар бирелә [Туган тел..., б. 14].

*Лл* (эль) хәрефен өйрәнә торган икенче дәрестә, темаара бәйләнеш сакланган: *а-а, ла-ла-ла, а-ла*. Авторлар тыңлап аңлауга ([л] авазының сүзнең кайсы урынында урнашуын ачыклауга), аваз белән хәрефне аерырга өйрәнүгә, хәрефләрне кушып укуга (*ал, ла, ла-ла, ал-ла*), телдән эшләүгә (ике рәсем ярдәмендә җөмлә төзеп әйтә белүгә), бер өйрәнелмәгән хәреф кергән сүзләрне рәсем ярдәмендә әйтеп бирүгә, эш дәфтәре белән эшләүгә, хәрефләрне кушу элементларын белүгә, *Лл* (эль) хәрефен язарга өйрәнүгә игътибарны юнәлтәләр [Туган тел..., б. 15–16]

Хәрефләр саны арта барган саен, әлеге әлифбада эш төрләре дә үзгәреп тора: хәрефләр белән бәйле бирелгән рәсемнәр һәм алар белән эш төрләре, сүзләрне иҗекләп укуга бәйле эш төрләре бирелә, текстларны тыңлау, сүзлек эше, сорауларга җавап бирү, төрле биремнәр, табышмакның җавапларын табу, башваткычлар чишү һ. б. урын ала. Шул ук вакытта авторлар 1 нче сыйныф укучыларына татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтергә өйрәнү, сузык авазларны

татар һәм рус телләрендә чагыштырып карау кебек төрле биремнәр дә тәкъдим итәләр:

1) *Ук – үк, кул – күл* сүзләрен бер-берегезгә әйтеп карагыз. *Уу* һәм *Үү* сузыкларын әйткәндә аерма бармы? [Туган тел..., б. 48]

2) *Оныт – онык, герой – орден, ылыс – кыр – сабын, тыл – сыр – посылка* сүзләрен бер-берегезгә әйтеп карагыз. Татар һәм рус телләрендә *Оо* сузыгын әйткәндә аерма бармы? [Туган тел..., б. 58]

3) *Савыт – авыл, ваза – вагон* сүзләрен бер-берегезгә әйтеп карагыз. Татар һәм рус телләрендә *Вв* тартыгын әйткәндә аерма бармы? [Туган тел..., б. 66].

Дөрестән дә, 1 нче сыйныфтан ук бала *в* хәрефенең әйтелешендәге аерманы (ирен-ирен [w] тартыгын һәм ирен-теш [в] тартыгын белдергәнне) тоемларга, сизәргә тиеш: *Вәсилә – Василий, савыт – завод*.

Авторлар бер тартык аваз белән генә аерылып торган сүзләрне уйларга, эзләргә өйрәтәләр: *көн – төн* (51 б.), *гөл – көл, суган – туган, тага – кага* (54 б.), *болын – колын* (72 б.) һ. б.

Дәреслектә тәкъдим ителгән күнегүләрдә әйтелешләре охшаш, ләкин язудагы билгеләре белән генә аерылып торган сүзләр дә бар. Мондый күнегүләр укучыларның сүз запасын арттыра гына: *җиләк – чиләк, җәй – чәй* (63 б.), *дала – тала* (43 б.), *тага – дага* (54 б.).

«Туган тел (татар теле). Әлифба» дәреслегендәге сүзләргә хәрефләр өстәп, яңа сүзләр ясарга кушылган күнегүләр дә бик отышлы: *ми – мин* (22 б.), *ук – тук* (45 б.), *авыл – давыл* (66 б.), *ак – вак* (66 б.), *аң – таң, иң – миң* (69 б.), *ур – Нур* (31 б.), *бала – балан* (33 б.) Алар арасында охшаш әйтелешле сүзләр уйлап табарга өйрәткән күнегүләр дә бар: *бай – бабай* (35 б.), *Раил – Раилә, Әмин – Әминә* (41 б.), *дус – Илдус* (42 б.), *көл – көлә, көй – көйлә* (51 б.), *Сылу – Айсылу* (57 б.) һ. б. Биредә укучы бер сузык аваз белән генә аерылып торган сүзләрне эзләргә, уйлап табарга өйрәнә: *кул – күл, курка – күркә* (47 б.) һ. б.

Дәреслек авторлары интонация белән эшләүгә, аеруча санау интонациясенә зур игътибар бирәләр: *Әти – Наил. Әни – Наилә.* (26 б.); *Рамил – татар. Тарас – рус.* (27 б.); *Бу – әби. Бу – бәби* (34 б.); *Исай – Нурлаттан, Миран – Сарманнан* (41 б.); *Камил, Камилә – дус, тату балалар.* (46 б.) *Мөнир, Тимур – дуслар.* (52 б.) һ. б. Укучылар сорау һәм өндәү билгеләре куелган җөмләләрне укырга өйрәнәләр: *Әминә нәни. Ә мин?* (22 б.) *Мин Татарстаннан. Ә син?* (30 б.) – *Сәлам, Динә! – Сәлам, Илдус!* (43 б.) һ. б. Дәреслектә сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны аерырга, сүзләрне иҗекләргә бүләргә өйрәнүгә кагылышлы мисаллар да җитәрлек: *ла – лә, ма – мә, та – тә, на – нә; ли – ми – ни, лу – му – ну; ә-нә, а-ла, ла-лә, ал-ма* һ. б.

Яңа буын татар әлифбасында кечкенә генә текстлар белән эш үзәккә алынган. Бу төр эшләр 1–4 нче сыйныфлар өчен туган тел (татар теле) дәреслекләрендә дә дәвам итә. Татар алфавитын тулысынча

өйрәнеп бетергәннән соң, уку, сөйләм телен баету өчен 6 дәрес бирелгән. Аларда төрле текстларны (әдәби әсәрләрдән өзекләр, шигырьләр, әкиятләр) уку, укыган текстның эчтәлегенә караган төрле биремнәр белән эшләү тәкъдим ителгән. Дәреслекне төсле рәсемнәр белән тулыландырылган татар алфавиты йомгаклый [Туган тел..., б. 100–101].

Коммуникатив компетенция формалаштыруны күздә тотып эшләнгән яңа буын «Туган тел (татар теле). Әлифба» китабы укучылар, укытучылар өчен генә түгел, әти-әниләр өчен дә гади, аңлаешлы булуы белән аерылып тора.

**Әдәбият**

Туган тел (татар теле). Әлифба. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. 128 б.

***Мотыйгуллина Әлфия Рухулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты доценты*

**2024 елның 1–2 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары Олег Хисамов Санкт-Петербургта узган «Всемирная сокровищница родных языков: оберегать и лелеять. Контекст, политика и практика сохранения языков коренных народов» II Халыкара конференциясе эшендә чыгыш ясады. Халыкара җирле халыклар телләре унъеллыгы кысаларында оештырылган әлеге форум эшендә Россия төбәкләреннән һәм 40 тан артык чит илдән килгән мәдәният, мәгариф, социаль, гуманитар һ. б. фәннәр өлкәсеннән экспертлар җыелган иде. А. Тимерхановның татар теле мисалында республикада туган телләрне саклау һәм өйрәнүгә караган академик кооперация тәҗрибәсен тәкъдим иткән доклады чараның пленар утырышында яңгырады. О. Хисамовның чыгышы татар телен саклауга мультидисциплинар караш, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплексلы экспедицияләре нәтиҗәләре һәм перспективаларына багышланды.

**2024 елның 2 июлендә** Казанда «Шомбай-fest» Халыкара курчак театры фестивале тәмамланды. Чара 2024 елның 25 июнендә старт алган иде. 2013 елда республиканың Мәдәният министрлыгы һәм «Әкият» татар дәүләт курчак театры инициативасы белән оештырылган әлеге фестиваль быел Казанда бишенче тапкыр узды. «Шомбай-fest» эшләгән елларда анда Россия Федерациясенең, шулай ук якын һәм ерак чит илләрнең 70 ләп курчак театры катнашкан. Быелгы фестивальдә Белоруссия, Азәрбайҗан һәм Россия театрлары чыгыш ясады.

**2024 елның 3 июлендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Гыйльми советының киңәйтелгән утырышында коллективка директор вазифасын башкару өчен яңа кандидатура – Халиков Илгиз Илдар улы тәкъдим ителде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Р.Н. Миңнеханов, хәзерге этапта фәнни җәмәгатьчелек алдында торган бурычларны билгеләп, Институт эшчәнлегенә кыскача тукталды, соңгы 18 елда Институтны җитәкләгән филология фәннәре докторы, профессор Ким Мөгаллим улы Миңнуллинга татар фәнен үстерүгә керткән өлеше, аның җитәкчелегендә коллектив ирешкән уңышлар өчен рәхмәт һәм алга таба да хезмәттәшлеккә, татар филологиясе өлкәсендә уртак эшкә ышаныч белдерде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты А.Ә. Тимерханов та К.М. Миңнуллинның галим һәм татар теле, әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендә әйдәп баручы фәнни-тикшеренү институты җитәкчесе буларак гуманитар фәнгә зур өлеш кертүен билгеләп үтте.

Халиков Илгиз Илдар улы – филология фәннәре кандидаты, моңа кадәр республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгында милли мәгариф идарәсен җитәкләгән, аңарчы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып эшләгән.

**2024 елның 3 июлендә** Татарстан Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының гыйльми советына

яңа директор тәкъдим ителде. Ул сәнгать белеме кандидаты, ТР атказанган сәнгать эшлеклесе, РФ һәм ТР Композиторлар берлеге әгъзасы, РФ һәм ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Галимова Эльмира Мөнир кызы. Яңа җитәкчене ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Нургали улы Миңнеханов тәкъдим итте.

Аңа кадәр бу вазифаны тарих фәннәре докторы, профессор, ТР ФА мөхбир әгъзасы, җәмәгать эшлеклесе Искәндәр Гыйләҗев башкарды. Ул Институтны 2015 елдан бирле җитәкләде.

**2024 елның 9 июлендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумының чираттагы утырышында «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе профессоры» исеменә лаек булган галимнәргә дипломнар тапшыру тантанасы узды. Пофессор таныклыгын алган 24 галим арасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре – директорның фән буенча урынбасары Хисамов Олег Ришат улы, халык иҗаты бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы һәм чагыштырма татар белеме лабораториясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Арзамазов Алексей Андреевич та бар. Хезмәттәшләребезне әлеге мөһим вакыйга белән котлыйбыз, алга таба да фәнни эшчәнлектә уңышлар, яңа казанышларга ирешүләрен телибез!

**2024 елның 15–17 июлендә** Көнбатыш Казакъстан өлкәсендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Тукай эзләре буенча» фәнни-мәдәни проектының бер өлеше булган «Тукай Җаекта» Халыкара арт-пленэры узды. Җаекта Г. Тукай исеме белән бәйле урыннар күп. Арт-пленэрда катнашучы Татарстан һәм Казакъстан рәссамнары алдында шагыйрь биографиясендәге әлеге сәхифәләрне чагылдырган әсәрләр иҗат итү бурычы тора. «Тукай эзләреннән» проекты, 2026 елга кадәр дәвам итеп, шагыйрьнең 140 еллыгы уңаеннан махсус күргәзмә һәм каталог бастырып чыгару белән тәмамланачак.

**2024 елның 23 июлендә** Чистай шәһәре Ислам үзәгендә Гаяз Исхакыйның вафатына 70 ел тулу уңаеннан «Яңарыш хәбәрчесе – заман һәм традицияләр» дип исемләнгән түгәрәк өстәл оештырылды. Чарада язучылар, галимнәр, журналистлар катнашты.

**2024 елның 16–18 август** көннәрендә Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында «Россиянең рухи бердәмлеге – дөньяга юллама» фестиваленең икенче өлеше оештырылды. Фестивальнең беренче өлеше июль азагында Зөядә үткән иде. Беренче көнне «Кара пулат» опера-легендасы күрсәтелде. Аның нигезенә Аксак Тимер сугышчылары яндырган унике кыз турындагы татар риваяте яткан. Опера өченче ел рәттән Кара пулат фонында – XIV гасыр Алтын Урда архитектурасының уникаль һәйкәле – ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объекты янында күрсәтелә.

Фестиваль кысасында уктан атып карарга, коймак пешерергә, прәннек һәм чүлмәк ясау серләренә төшенергә дә мөмкин иде. Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-

тыюлыгында исә «Гарәби каллиграфия күргәзмәсе» эшләде.

Икенче көнне Фестивальнең эшлекле программасы кысаларында «Этномәдәни мирасны саклау һәм үстерү: традиция, мода һәм дизайн» дип исемләнгән түгәрәк өстәл узды. Анда татар җәмгыятендә традицияләр, мода һәм дизайн белән бәйле мәсьәләләр каралды.

**2024 елның 19–30 августында** татарлар күпләп яшәгән Пермь крае авылларына Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Экспедиция составында халык иҗаты, лингвистика, халык һөнәрчелеге һәм кәсепләре, археография һәм эпиграфика буенча галимнәр эшләде. Белгечләр Пермь крае Октябрь шәһәр округының Ишим, Самар, Уразмәт (Яңабирде), Казак, Биктулка, Кече Биктулка (Абдулчук), Бикбай, Бачын, Янапай, Әри-Түз, Калтай, Әтнәгуҗа, Кашка, Яңа Иренбаш; Уинский муниципаль округының Чәйкә, Югары Сеп, Урта Сеп, Иштирәк, Барсай, Тәләс, Түбән Сеп; Чернушинский шәһәр округының Сулмаш, Әминкәй; Куяды муниципаль округының Маныш, Бадашка авылларында яшәүче милләттәшләребезнең халык авыз иҗатын, традицион музыка мәдәниятен, археографик мирасын, эпиграфик һәйкәлләрен, татар халык сәнгате үрнәкләрен өйрәнү белән шөгыльләнде.

**2024 елның 19–31 августында** Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы фәнни экспедициясе Бурятия Республикасында эшләде. Экспедиция эшендә төрле юнәлештәге галимнәр катнашты. Алар тарафыннан сакланып калган борынгы китаплар һәм кульязмаларны өйрәнү буенча эш алып барылды. Алар бередә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләре, матди һәм традицион мәдәнияте, рухи һәм язма мирасы, халык сәнгате белән танышып, алдагы тикшеренүләр өчен материал туплады.

**2024 елның 23–26 августында** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре Үзбәкстанның мәдәни мирасын өйрәнү, саклау һәм популярлаштыру буенча Бөтендөнья җәмгыятенең «Наследие великих предков – основа III ренессанса» дип исемләнгән VIII Халыкара Конгрессы эшендә катнаштылар. Бу чара Ташкент һәм Сәмәрканд шәһәрләрендә узды. Форумны Үзбәкстан Республикасы Министрлар кабинеты каршындагы Ислам цивилизациясе үзәге, ТӨРКСОЙ, IRCICA һәм «Әл-Фуркан» ислам фонды оештырган иде. Дөньяның 35 иленнән килгән өч йөздән артык галим, шулай ук Үзбәкстанның мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклау өлкәсендә эшләүче әйдәп баручы белгечләр катнашында узган әлеге конгресста Ташкентта төзелә торган Ислам цивилизациясе үзәге музее концепциясе турында фикер алыштылар.

**2024 елның 27 августында** Г. Камал исемендәге ТДАТ фойесында «Тукай Җаекта» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Анда 2024 елның 8–18 июлендә Көнбатыш Казакъстан өлкәсенең Җаек шәһәрендә узган Халыкара артпленэр вакытында төрле жанрларда һәм техникада иҗат ителгән 56 дан артык тасвирый сәнгать әсәре тәкъдим ителә. «Тукай эзләреннән» проекты Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать

институты тарафыннан ТР Мәдәният министрлыгы ярдәме белән гамәлгә ашырыла.

**2024 елның 1 сентябрендә** Казанда Россия Фәннәр академиясенең 300 еллыгына багышланган аллея ачу тантанасы узды. Чарада Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге директоры А.А. Калачев, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты А.А. Тимерханов һәм башкалар катнашты. РФА юбилее хөрмәтенә Химиклар культура йорты артындагы нарат-лыкта ылыслы агачлар утыртылды. Бәйрәм кысаларында тамашачыларга эффектлы тәҗрибәләр һәм Казан фәнни мәктәпләре турында фильм күрсәтелде.

**2024 елның 5 сентябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Азат Ахунов Габдулла Тукайның рус телле укучыга барып ирешмәгән әсәрләрен әдәби тәрҗемә итү конкурсында җиңүче дип табылды. Конкурс «Казан альманахы» әдәби журналы һәм Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан бөек татар шагыйре, әдәби тәнкыйтьче һәм публицист Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуга әзерлек кысаларында игълан ителгән иде.

**2024 елның 9–11 сентябрендә** «Казан Экспо-2024» ХКҮ мәйданчыгында Kazan Digital Week форумы оештырылды. Әлеге Халыкара форум инде бишенче тапкыр уздырыла (онлайн һәм офлайн форматта); бу вакыт эчендә ул үзен мөһим дәүләт карарларын эшләп чыгарганда эшлекле даирә белән элемтә каналы итеп күрсәтте. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Фәннәр академиясенең Kazan Digital Week-2024 форумында тәкъдим ителгән проектлары кысаларында үзенең «Мәгърифәт», топонимнар каталогы, сүзлекләр фонды кебек берничә электрон проектын да тәкъдим итте.

**2024 елның 16 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Россия Фәннәр академиясенә нигез салынуга 300 ел тулуга һәм Казан Император университеты ачылуга 220 ел тулуга багышланган Бөтенроссия фәнни конференциясе уздырылды. Әлеге чара Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Россия Фәннәр академиясе Гомуми тарих институты, Казан (Идел буе) федераль университеты, ТР Милли музее, «Елисавета-Сергиев мәгърифәтчелек җәмгыяте» шәфкатьлелек һәм хәйриячелек традицияләрен торгызуга ярдәм фонды тарафыннан оештырылды.

**2024 елның 16–23 сентябрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы фәнни экспедициясе Татарстанның Бөгелмә районында эшләде. Экспедицион төркем Татарстан Республикасы Бөгелмә районының унике торак пунктында (Бөгелмә ш., Татар Димескәе, Райлан, Суык Чишмә, Кодаш, Таллы Бүләк, Алга, Сугышлы, Иркен, Якты Ялан, Батыр авыллары, Карабаш бистәсе) тикшеренүләр уздырды. Алар шулай ук Бөгелмә шәһәренең Үзәк китапханәсе һәм Туган якны өйрәнү музее фондларында материал тупладылар.

Кыр тикшеренүләре барышында галимнәр татар халкының милли-мәдәни мирасын өйрәнделәр, аның

тел үзенчәлекләре, халык иҗаты, сәнгате, музыкасы, археографиясе буенча бай материал тупладылар.

**2024 елның 19–20 сентябрендә** Татарстанның Мөслим районында «Көнбатыш Урал буе татарлары: үткәне һәм хәзергесе» Бөтенроссия фәнни конференциясе уздырылды. Чараны оештыручылар – Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Башкортстанның татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы администрациясе.

**2024 елның 24 сентябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге галимнәре Чиләбе өлкәсе Троицк шәһәрендә эпиграфик экспедиция эшен башладылар. Ул октябрь башына кадәр дәвам итәчәк. Кыр-тикшеренү эшләре барышында шәһәрнең татар зиратында И.Г. Гомәров, В.М. Усманов, А.М. Ахунов тарафыннан XIX гасырга нисбәтле 250 дән артык гарәп язулы эпиграфик ядкәр исәпкә алынды һәм тасвирланды. Шулай ук Троицк шәһәре тирәсендәге татар авылларыннан Рәдүт, Варна зиратларындагы эпиграфик ядкәрләр дә тикшерелде. Әлеге экспедиция 2022–2023 елларда уздырылган кыр-тикшеренү эшләренең дәвамы булып тора.

**2024 елның 25 сентябрендә** Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мөселман мәдрәсәсе бинасында «Сөннәтче, бабачы – гореф-гадәтләрне, динебездә чисталыкны саклаучы» дип аталган фәнни-гамәли конференция узды. Чара түгәрәк өстәл рәвешендә оештырылды һәм дин белгечләрен, тарихчыларны, табиблар, шәкертләрне җыйды. Җыелыш мәдрәсә тарафыннан Россиядә Гаилә елы һәм Татарстан мөфтияте игълан иткән Гаилә һәм хәләл яшәү рәвеше елы кысаларында үткәрелде. Конференциянең пленар өлешендә күренекле дин белгечләре һәм җитәкчеләр чыгыш ясады, алар арасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла һәм башкалар бар иде. Утырыш әгъзалары татарларның рухи-әхлакый кыйммәтләрен торгызуга, гаиләне һәм нәселне саклау, үсеп килүче буында тарихи үзаңны ныгытуга зур өлеш керткән күренекле шәхесләрне өйрәнү буенча киләчәктә дә эшне дәвам итү зарурлыгы турында карар кабул итте.

**2024 елның 25–26 сентябрендә** «Ватанга югары хезмәт»: Россия провинциясенең тарихи-мәдәни тормышында персоналияләр» (Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Н.М. Вәлиевнең тууына 75 ел тулу уңаеннан) бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырылды. Конференция эшендә Россия Фәннәр академиясе, фәнни оешмалар һәм югары уку йортлары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фәнни-тикшеренү институтлары галимнәре, республикабыз музейлары һәм китапханәләре вәкилләре катнашты.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2024. № 3

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 27.09.2024. Басылды: 30.09.2024.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият һәм типография адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал Татарстан, Башкортстан Республикаларында, Самара, Ульяновск,
Оренбург, Әстерхан, Төмән өлкәләрендә бушлай таратыла



Сулдан уңга: Х.Х. Хәсәнов, Ф.Н. Гыйззәтуллин, В.Ф. Павлова, Х.Х. Ярмөхәммәтов, В.Н. Хангилдин, Г.Х. Хисмәтуллин. 1954 ел



Сулдан уңга: күренекле тюрколог, академик А.Н. Кононов, М.К. Мөхәррәмов, Д.Г. Тумашева, М.З. Зәкиев. 1974 ел



Я.Г. Абдуллин Ә. Еникинең 85 яшьлек юбилей чарасында. 1984 ел



Ә.Г. Кәримуллин һәм С.Х. Алишев. 1989 ел

## Р.Ә. Абзалинаның «Габдулла Мөхәммәтгариф улы “Мотыйгия” мәдрәсәсендә» мәкаләсенә



«Мотыйгия» мәдрәсәсе шәкертләре. XX гасыр башы. Г. Тукай алгы рәттә, уңнан икенче. *Татарстан Республикасы Милли музее. № 19698-101*





Нигъмәт Вәлиевнең остазы Нуриәхмәт Һадиуллин турында истәлеге. Беренче һәм соңгы битләре. *Татарстан Республикасы Милли музее.* № 19689-1

## Л.И. Тябинаның «Кем ул Камил Мотыйгый?» мәкаләсенә



Күренекле татар җырчысы К. Мотыйгый. XX гасыр башы. *ТР ММ. КП-123235/6*



К. Мотыйгый. Фотография. *ТР ММ.КППи-121948*



К. Мотыйгый. XX гасыр уртасы. Фотографиядән фотокопия. *ТР ММ. КП-23693/82*

## Дж.Ш. Курбангельдыевның «Сәлҗуклар дипломатиясендә җәя һәм ук символикасы» мәкаләсенә



Бәйсезлек монументы каршындагы Угыз хан скульптурасы



А. Мөхәммәдов. Мөхәммәд Тугрылбәк. 2005



А. Амангельдыев. Алып-Арыслан. 1997



И. Ишангулыев. Тугрылбәк. 2010



«Дөньяның яшь хәбәрчеләре» конкурсының финалы

## О.В. Калугинаның «Россиянең хәзерге заман шәһәр скульптурасы: жанрын билгеләү мәсьәләсе» мәкаләсенә



И. Рукавишников. Мәскәүдә Цветной бульвардагы цирк бинасы янында урнаштырылган Юрий Никулин һәйкәле



И. Башмаков. Казанда Бауман урамында урнаштырылган Казан Мәчесе һәйкәле



Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты коллективына яңа җитәкче тәкъдим итү



Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтына яңа директор тәкъдим итү

## Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре фәнни экспедицияләрдә



Пенза өлкәсе Каменка районы Кочалейка авылында



Чиләбе  өлкәсе Троицк шәһәрендә

Бөгелмә районында




## Яңа китап

